**МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РФ**
**БАШКИРСКИЙ ГОСУДАРСТВЕННЫЙ ПЕДАГОГИЧЕСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ им. М. Акмуллы**
**РОССИЙСКИЙ ИСЛАМСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ**
**ЦДУМ РОССИИ**

**Р. Амиров. И. Мансуров**

# ИСЛАМ В БАШКИРСКОЙ И ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЕ
**(Хрестоматия)**

Уфа – 2015

УДК 821.51.0
ББК 83.3 (5)
А 62

Амиров Р.К., Мансуров И.С. Ислам в башкирской и татарской литературе: хрестоматия. – Уфа: Изд-во БГПУ им. М. Акмуллы, 2015, – 168 с.

Хрестоматия представляет собой отобранные и расположенные в историко-хронологическом и логическом порядке выдержки из произведений, освещающие этапы принятия и распространения ислама на Урале и в Поволжье с X по XIX вв. Цель издания – содействие объективному осмыслению и усвоению этапов проникновения ислама и их отражение в искусстве слова. В период напряжённой борьбы между различными направлениями Ислама опора на объективные факты истории является главным аргументом в осмыслении роли и места ханафитского мазхаба в духовной истории татар и башкир.

Рецензент:
д.и.н., профессор Загидуллин Ильдус Ильдусович

© Издательство БГПУ, 2015.
© Амиров Р. К., Мансуров И. С. 2015.

## От составителей

Принятый в Волжской Булгарии в 622 году ислам вместе с православием является одной из самых влиятельных конфессий в стране.

Естественно, за более чем тысячелетний путь развития ислама на Урале и в Поволжье накоплено огромное количество публицистических, историко-художественных текстов. Ведь слово, тем более художественное, во все времена было и остаётся проводником идей, зеркалом духовной жизни народов. Не забудем, что поэтическое слово было в особой цене у Мухаммада, а сам Коран являет собой собрание стихотворных текстов-аятов.

Отнюдь не претендуя на полноту охвата масштабного материала об этапах проникновения и утверждения ислама в быту и сознании народов региона, в предлагаемой хрестоматии мы ограничили себя извлечениями из текстов X-XIX вв., в которых, на наш взгляд, эти процессы нашли наиболее яркое воплощение.

Вполне понимая ограниченность объёма хрестоматии, при отборе авторов и произведений мы исходили из того, чтобы, во-первых, они могли служить источником при изучении этапов развития ислама в регионе и, во-вторых, стали стимулом для привлечения новых текстов и дальнейших размышлений.

Понятно также, что сложности и перипетии, возникавшие на уровне государственной политики (а вера была её концентрированным выражением), отнюдь не были препятствием для контактов и взаимодействия народов на бытовом уровне, проникавших и в более высокие сферы. Характерен такой пример. В пору утверждения ислама довольно сильной была ориентация на Бухару, а затем Турцию, а к XIX веку популярным учебным заведением для поволжских мусульман, наряду с учебными заведениями Казани, Петербурга и Москвы, становится Парижская Сорбонна, где, как известно, было распространено католичество. Впрочем, составление хрестоматии произведений, в которых отражён этот новый период развития Ислама, получивший название джадидизма, – следующая ступень работы.

Поскольку ряд текстов был создан на языке поэтической, духовной и научной литературы своего времени — фарси и арабском, а многие из них, начиная с Кол Гали, на тюрки — татарском с примесью фарси и арабского, выдержки из них даны в переводах разных лет на татарский и башкирский языки.

## Шигабутдин Марджани
## (1818–1889)

Один из выдающихся представителей просвещения Шигабутдин сын Багаутдина Марджани оставил неизгладимый след в истории культуры, общественной мысли. «Основоположником прогрессивной мысли среди татар» назвал его выдающийся русский ученый-тюрколог В. Бартольд. Родился Ш. Марджани 16 января 1818 года в деревне Ябанчы, что в Заказанье, в семье муллы. Вскоре его отец становится имамом д. Ташкичу и открывает там большое медресе. Здесь юный Шигаб начинает постигать основы духовных знаний и вскоре, по исполнении 17-ти лет, становится помощником отца.

В 20 лет он отправляется в Бухару, а через 5 лет переходит в Самарканд, где в течение двух лет, как сказали бы сегодня, обучается по индивидуальной программе у городского судьи-казыя, а затем вновь возвращается в Бухару. В этих городах, помимо арабского и фарси, он осваивает логику, философию и историю, астрономию. Перед ним открывается мир аль-Фараби, аль-Бируни, Ибн-Сины, Ибн Халдуна и многих других выдающихся учёных-естествоиспытателей своего времени. А увлечённое чтение творений великих поэтов Востока — Саади, Фирдоуси, Хайяма, Навои — способствует широкому развитию гуманитарной мысли у пытливого юноши.

Так закладывается фундамент передовой научно-педагогической мысли, получивший широкое развитие после возвращения на родину. В 1849 году он назначен имамом первой мечети Казани и преподавателем — мударрисом медресе при мечети.

Он стремится изменить внутренние порядки в учебном заведении. Наряду с духовными знаниями он широко включает в уроки материалы естественных наук, знакомит шакирдов с достижениями гуманитарной и естественной мысли своего времени, привлекает работы таких русских востоковедов, как А. Казембек, В. Радлов, И. Готвальд и др.

Широко интересующийся поисками и достижениями гуманитарной мысли своего времени, Марджани смело вступал в дискуссию со сторонниками консервативной мысли. Так, одним из первых он обосновал допустимость для мусульман фотографирования (если фотокарточка не уподобляется иконе), установления на могилах близких людей надгробных плит с надписью. Более того, именно с Марджани получает начало традиция изучения надгробных плит как памятников истории.

Пойдя против расхожих консервативных суждений и мыслей, Марджани обосновал необходимость включения в программы медресе уроков русского языка. В более чем 30-ти своих произведениях, как совершенно справедливо писал Галимджан Ибрагимов, он защищает свободу личности, глубокую веру в будущее и в ум человека. С первой до последней строки они пронизаны мыслью о борьбе против рабства мысли, против омертвелых традиций, против наложенных на человека оков.

Творчество и личность Ш. Марджани оказали огромное влияние на современников и последующие поколения. Широко известно, например, что

многие начинания Х. Фаизханова являются итогом совместной деятельности двух выдающихся предшественников татарского просвещения — реформаторов Ислама. Без многогранной деятельности Ш. Марджани трудно представить творчество К. Насыри, Г. Тукая, Ф. Амирхана, М. Акмуллы, Н. Думави, Г. Чокрый, те грандиозные преобразования, которые претерпела общественная мысль, литература и искусство Урало-Поволжья на изломе XIX-XX веков. А его многотомный, многоплановый труд «Источники по истории Казани и Булгарии» не только положил начало опирающемуся на достоверные факты толкованию и изучению истории народов края в контексте их духовного развития, но и заложил жанрово-стилевые особенности исторического, поискового изображения происшедших событий.

Событием огромного историко-нравственного значения стал факт публикации многотомного труда Ш. Марджани в переводе на татарский язык. В этом труде, опирающемся на огромный фактический материал, доставшийся от предшественников и собранный у современников, Ш. Марджани по существу впервые восстанавливает и представляет своё мнение об истории народов Урало-Поволжья, повествует, как сказали бы сегодня, о полиэтничном государстве Поволжской Булгарии, рассказывает о проникновении ислама в этот регион и превращении его в государственную религию.

Важное место занимает в энциклопедическом труде Ш. Марджани изложение по существу впервые привлекаемых путевых очерков муктадира — секретаря посольства Ирака Ибн-Фадлана и его живые свидетельства о принятии ислама в Волжской Булгарии.

В результате открылись широкие возможности для изучения истории, этнографии, особенностей быта народов Урало-Поволжья и поиска истины в сопоставлении с публикациями разных лет.

## Литература

*Кудаш, С.* По следам юности. Уфа, 1964.

*Абдуллин, Я.* Татарская просветительская мысль. Казань, 1976.

*Миркасим Усманов.* Источники книги Ш. Марджани «Мустафа-аль-акбар фи аквали Казан вә Болгар» // «Очерки и истории Поволжья и Приуралья», Казань, 1969.

*Юсупов, М.* Шигабутдин Марджани как историк. Казань, 1981.

*Абдуллин, Я.Т., Хайруллин, А.И.* Вступительное слово к книге Шигабутдина Марджани. «Мустафа-аль-акбар фи аквали Казан вә Болгар». Казань, 1989.

*Ковалевский, А.П.* Чуваши и булгары по данным Ахмеда ибн-Фадлана. Чебоксары, 1954.

См. также: Путешествие Ибн-Фадлана на Итиль и принятие в Булгарии ислама / Перевод на русский язык. С. Шамси. Москва, Казань, 1992, с. 55-92.

*Крачковский, И.Ю.* Избранные сочинения. Т. 4, М-Л., 1957.

История башкирской литературы. Т. 1. Уфа, 2012, с. 36-37.

## Болгар иле һәм анда Исламның керүе турындагы фасыл

Мөселман тарихчы галимнәрнең төрле риваятьләренә һәм аларның күп сандагы китапларыннан алынган мәгълүматларга караганда, борынгы заманда «хәзәр» һәм «болгар» сүзләре бу мәмләкәттәге барлык халыкка исем булган. Соңрак заманда бу олы мөстәкыйль дәүләт икегә бүленеп, көньягындагы өлеше «Хәзәр» исемендә калып, төньяк өлеше «Болгар» исеме белән мәшһүр булган. Әбү Гали Дастә Хәзәрне: «Күл артындагы[1] киң ил, аның шәһәрләре — Болгар һәм Сәмәндар», — дип яза. Әбү Исхак әл-Истахри һәм Әбү Габдулла әл-Гарнатый: «Хәзәр теленә башка телләрнең катнашы юк», — дигәннән соң, «Болгар теле ул — хәзәр теле», — дип белдерәләр.

Шулай ук диңгез буенда, Хаҗитархан шәһәре тирәсендә яшәгән халыкны «түбән болгарлар» дип йөрткәннәр.

Болгар иле көньякка таба бик еракка, Хәзәр дим. гезе ярларына, Дагыстан чигенә, Кавказ таулары итәкләренә кадәр җәелгән.

Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини үзенең «Асярел-биляд» исемле китабында: «Болгар халкы исламны кабул иткәч, Хәзәр патшасы алар белән бик зур сугышлар алып барды», — дип яза. Имам Әбелхәсән әл-Мәсгуди исә: «Хәзәр патшалыгының башкаласы элек «Мәдинәтел-бабтан»[2] сигез көнлек ераклыктагы «Сәмәндар» шәһәре иде. Аны Сөләйман бине Рәбигател-Баһили яулап алганнан соң, Хәзәр патшасы Хаҗитархан шәһәренә күчкән», — дип яза. Икенче бер урында: «Хәзәр һәм Кыпчакка караган Нитыш диңгезен «Бәхре болгар» дип атыйлар; Болгар әмиренә «белеквар» дигән шикелле, Хәзәр хөкемдарына да «бик», «белек» диләр. «Хәзәрдән Дунайга бер таифә халык күчте», — дип әйтүләр һәм кыпчакны Болгар илендәге кабиләләрдән санау — болар барысы да Хәзәр белән Болгарның якынлыгын күрсәтеп тора. Уйлап карасак, Болгар мәмләкәте ул диңгез тирәләренә ия булмаса, диңгезне Болгарга карату һәм «Болгар — Хәзәр иле» дип санау; Болгар теле Хәзәр теле була торып та, «хәзәр теленә башка телләрнең катнашы юк» дию һәм фәкать исламга кергән өчен генә «Хәзәр патшасының чит мәмләкәт белән сугыш алып баруы» — акылга сыймый торган эш булып кала. Бәлки, Болгар хөкемдары Исламны кабул итеп, Ислам хәлифәсенә буйсынганнан соң Хәзәр патшасына баш ими башлагандыр. Аңа түли торган салымны туктаткандыр һәм Хәзәр патшасы аны яңадан үзенә буйсындыру өчен өстенә гаскәр җибәргәндер, шул сәбәпле Болгар «тышкы Болгар» дип аталган булыр. Әхмәд бине Фазланның: «Болгар патшасы Мокътәдир биллаһ хәлифәдән дошман патшаларның һөҗүмнәреннән саклану өчен үзенең шәһәренә кальга, ягъни курган салып бирүне сорады», — дигән сүзе дә югарыда әйтелгәннең дөреслегенә дәлил була ала. Болгар патшасының Багдадка илче җибәреп, үзенең ислам кабул итүен белдерүе, Хәзәр патшасыннан аерылып Ислам хәлифәсенә буйсынуын шартнамә белән беркетүе — көнчыгыш ягындагы күршеләре арасында шөһрәт казану өчен һәм Хәзәр патшасы аның өстенә яу белән килгәндә хәлифәгә таяну өчен булыр. Шуның соңында, Болгар патшасы, бер яктан, хәлифәнең мәгънәви ярдәме белән үзенең сәяси куәтен көчәйтеп, икенче яктан, исламга керү белән тормышларын һәм холыкларын төзәтеп, халкына гыйлем һәм мәгариф өйрәп, сәүдә һәм яхшы мөгамәлә белән матди хәлләрен яхшырткан. Гарәп гаскәрләре тарафыннан кат-кат җиңелгән хәзәрләр көннән-көн көчсезләнеп,

патшалыклары табигый рәвештә тузган. Халкы әкренләп Ислам дине кабул итеп, Болгар әмире тәэсире астында калган. Кабиләләренең, кешеләренең күбрәге шул тарафка тартылып, «борынгы Хәзәр дәүләте» һәм «хәзәр» дигән исем бөтенләй югалып, «Болгар» исемендә генә калган булган. Испания, Иран, Сүрия һәм Копт мәмләкәтләре мөселманнар тарафыннан яулап алынганнан соң, гарәп илләрендәге кебек, үзләренә Әндәлес, Гыйрак, Шам[3] һәм Мисыр исемнәрен алдылар. Шулай ук Болгар мәмләкәте халкының, аларга иярүче һәм аларга күрше булган мөселманнарның күпчелеге соңга таба татарлар тарафыннан җиңелгәч, һәммәсенә дз «татар» исеме бирелде, иске исемнәр беттеләр, югалдылар... Гомумән, хәзер Россия мәмләкәте эчендәге, әүвәлдә киң һәм төрле-төрле халыклы булган һәм «Сәкалибә иле», «сәкълаб халкы», аннан соң — «Дәште кыпчак иле», «кыпчак халкы», аннан соң — «Болгар иле», «болгар халкы», аннан соң — «татарлар» һәм «Татар мәмләкәте», «Жу-җи улусы», «Бату урдасы», «Бәррийятел Бәрәкәт», «Үзбәк иле» исемнәре белән танылган бу мәмләкәт кешеләрен, төс һәм кыяфәтләренә карап, гарәпләр «хәзәр» дип, мәмләкәтләрен дә «Хәзәр иле» дип атаганнар.

Мәмләкәт барлыкка килгән заманнарда Хәзәр патшасы Сәмәндарда һәм Ителдә булып, соңрак «Болгар» патшалыгы үсеп күтәрелеп чыккан. Икесе ике вакытта дан тотканлыктан, кайбер китапларда икесен кара-каршы куеп телгә алулар да булган. Ләкин хәзәр болгарлардан аерым, башка бер халык түгел.

Карагыз! Татарларның күтәрелеп чыгып, бу мәмләкәткә ясаган һөҗүмнәре соңында лан, кыпчак, рус, болгар һәм башка халыклар белән сугышулары турында күп китапларда әйтелгән. Әмма хакан яки Хәзәр патшасы һәм Хаҗитархан халкы белән булган аерым вакыйгалар турында бер сүз дә юк. Әгәр дә хәзәрләр болгарлар булмыйча, башка булсалар татарларның алар белән маҗаралары турында да сүз булырга кирәк иде. Дөресен хода белә.

Инде без Болгар һәм Хәзәр илләренә бер караш ташлап, бу илләрне мөселманнарның яулап алулары турындагы риваятьләрне һәм хәбәрләрне китерәбез.

Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими дигән кеше үзенең «Тәварихы Болгария»сендә болай дип яза: «һиҗри тарихның 9(631) елында Айдар хан бине Тукый хан Хут йолдызлыгында*, рамазан аеның тугызынчы көнендә тәхеткә утырып, Болгарда патша булды. Пәйгамбәребез, хода аңа рәхмәт кылсын, Габдеррахман бине Зөбәер, Тальха бине Госман һәм Зөбәер бине Җәгъдә дигән өч сәхабәне Болгарга җибәрде. Ул заманда Болгә иделе[4] Болгар астыннан ага иде. 396(1006) елларгача, ягъни Бараҗ хан заманынача булып үткән ханнар, барысы биш йөз егермеләп булып, бары да утка табынучылар иде».

Икенче бер җыентыкта[5] исә Тальха бине Госман урынына Ханзал бине Рәбигъ дигән кеше телгә алына. Мөхәммәд пәйгамбәрнең аңа таяк бирүе, Зөбәер бине Җәгъдәгә кара савыты һәм Габдеррахман бине Зөбәергә чалма бирүе, «Сездән кәрамәт[6] таләп итсәләр, ошбу өч нәрсә белән ходадан ярдәм теләрсез», — дип әйтүе язылa.

«Болар Болгарга килеп, табиб[7] сурәтендә йөреп, күп авыруларның савыгуына ярдәм иттеләр. Айдар, хан кызы Туйбикә паралич белән авырып, табиблар аны дәвалаудан гаҗиз иделәр. Вәзир патшага: «Шәһәребездә

гарәплләрдән өч табиб бар, дәвалауда тиңдәшсез осталар икән», — дип хәбәр бирде. Патша аларны үз янына чакыртып алдырды. Алар, патшаның ислам динен кабул итүен шарт итеп, кызны дәвалап терелттеләр. Хан һәм аның халкы мөселман булдылар һәм җамигъ мәчет салдылар. Хәзрәте Зөбәер бине Җәгъдә имам булып, югарыда телгә алынган таякка таянып хотбә укыды. Тарих һиҗри 12 (634) ел — куй елында, рамазан аеның 12сендә, 24нче хутта сәхабәләр халыкны мөселман кылдылар. Унике елдан соң ике сәхабә Мәдинәи менәүвәрәгә[8] кайтып китте, Ханзал исә Болгарда калып, хан кызы Туйбикәгә өйләнеп, Болгарда вафат булды, төрки телгә бик оста иде».

Хисаметдин Мөслимидә: «Айдар хан кызы — Туйбикәне алып, егерме биш ел Болгарда торып калып, шунда вафат булган һәм терки теленә бик оста булган кеше ул Зөбәер бине Җәгъдә иде», — дип языла.

Бу фәкыйрь әйтә: югарыда телгә алынган «Тәварихы Болгария» китабы һәм икенче җыентык һич тә ышанычлы әсәрләр түгел, һәр ике китап ачык ялган белән тулган. Болгар халкының Мөхәммәд пәйгамбәр заманында Ислам диненә керүенә борынгы һәм соңгы заман галимнәренең әсәрләрендә һичбер дәлил, күрсәтмә юк. Мондый олы бер вакыйга булса, хәдис һәм тарих китапларында бу турыда хәбәрләр сөйләнер иде. Шулай ук танылган сәхабәләр, мәсәлән, Хафиз ибне Мензә, Әбү Нәгыйм, Әбү Муса, Ибне Габделбәр, Ибне Дабаг, Гыйззетдин бине әл-Әсир һәм берадәре[9] Мәҗдетдин бине әл-Әсир, тагын башка шундый галимнәр китапларында да сәхабә булган барлык ир һәм хатын-кызларның исемнәрен телгә алып үтү вазифасы булса да, пәйгамбәрнең сәхабзләре арасында Зөбәер бине Җәгъдә, Тальха бине Госман исемле кешеләр булуы телгә алынмый... Ханзал билгесез, сәхабәдән фәкать бер шәхес — Ханзал бине Зарар бине әл-Хасыйн билгеле. Әмма Ханзалга билгеле Әбү Рәбгый Ханзал бине әр-Рәбигъ бине Сәйфи бине Рибах әт-Тәмими — язучы. Кайбер сүзләргә караганда, атасының исеме — Рабига, Бас-рада яшәгән. Хәзрәти Галидән аерылып калып, Мөгавия заманында Каркыйсада вафат булган. Габдеррахман бине әз-Зөбәер бине Зәед бине Өммиятел-Корзый сәхабә билгеледер. Углы Зөбәер бине Габдеррахман һәм хәзрәти Гайшәдән Горвәт бине әз-Зөбәер бине Гавам аның Рәфагател-Корзыйның аерылган хатынына өйләнү кыйссасын риваять иттеләр. «Мәгърифәтес-сәхабә»[10]дә башка мәмләкәткә сәфәр кылганы һәм гомерендә шуңа охшаш эше билгеле түгел Ошбу билгеле сәхабәләрдән башка, бу исемнәрдә булган сәхабә кеше телгә алынмый. Шулай ук һиҗри 12(634) елда рамазан ае Хутка түгел, бәлки Гакрәбкә* туры килгән. Бу шулай. Дөресен алла белә.

Гәрчә шәһре Болгарга бу рәвешле сәхабәләр килүнең нигезе булмаса да, бу мәмләкәт халкының Исламга бик иртә керүенә, аларны дингә өндәү өчең гарәп халкыннан табиб сурәтендә өндәүчеләр килгәнлегенә дәлил булырлык беркадәр риваятьләр бар. Гыйззетдин Әбел-Хәсән Гали бине әл-Әсир үзенең «Мәгърифәтес-сәхабә» китабында Гамир бине Әфса әл-Әсләми турында сөйләгәндә болай ди: «Гамир үз кабиләсеннән бер җәмагать белән пәйгамбәргә килде. Пәйгамбәр аның кулына төрки телендә бер хат язып бирде». Әбү Һөрәйрә ул хатта язган сүзләр турында телгә ала. Ләкин ул хатны риваять итеп сөйләүчеләр, гарәпчә сүзләр кулланганлыктан, аның эчтәлеген үзгәрткәннәр. Бу

үзгәртүләр нәтиҗәсендә хәтта хаталар бар. Шул сәбәптән без ул хатны монда китермәдек...

Бу риваятьтән аңлашылганча, Мөхәммәд пәйгамбәр янында төрки телен белүче кеше булган һәм ул бер халыкка төрки телендә хат язган. Ул хат, гарәпчә сөйләшүче Гамиргә һәм аның юлдашларына язылган булмаган, әлбәттә. Телләре төркичә булган башка бер халыкка ирештерү өчен язылган булган. Ул заманда гарәп, Шам илләрендә, Рум мәмләкәтләрендә төрки телендә сөйләшә торган халык юк иде. Кытайга чаклы бик күп мәмләкәтләр, күп тоткарлыклар, озын юллар булу сәбәпле, бу хатның аларга да язылмыйча, бәлки якындагы, бер-берсе белән аралашып йөргән Болгар һәм Хәзәр халкына язылган булуы ихтимал. Гарәп халкы ислам дине барлыкка килү белән бу мәмләкәткә аяк баса башлаган. Аларның бу өлкәдә көмеш ятмасы табып, зур бер елганы һәм мәгълүм бер өлкәне гарәп телендә «Нократ[11] елгасы» һәм ул өлкә халкын «Нократ, болгарлары» дип атаган булулары шуны күрсәтә. Бу өлкә һәм елга хәзер дә шул исем белән йөртелә. Моның шулай булуы гарәп халкының күптән бу ил белән аралашуын күрсәтә. Шуңа күрә дә Болгар халкы телендә бик күп гарәп сүзләре табыла. Хәтта хәзерге заманда да, бик күбесе онытылып, күбесе, үзгәртелеп, бозылып әйтелә торган булып калса да, бик ерак авылларда да гади халык телендә меңнән артык гарәп сүзләре йөри. Шаять алар алдагы бер бүлектә китерелер[12].

Аларга гарәп теле керүе сәүдә эше аркасында аралашу нәтиҗәсендә булмаска кирәк. Алай булса, фарсы теле дә шулай ук нык кереп урнашкан булыр иде. Дөрес, фарсы сүзләре дә кергән, ләкин алар бик аз.

Якут әл-Хәмәви үзенең «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китабында болай ди: «Хәзрәти Гомәр, хәлифәлегендә 19 ел һиҗридә (641) Әбү Муса әл-Әшгари Исфаһанны яулап алудан бушагач, Габдеррахман бине Рәбигател-Баһилине гаскәрнең алдына куеп, Сәракә бине Гомәрне Дәрбәнд тарафын яулап алу өчен җибәрде».

Гыйззетдин бине әл-Әсир үзенең «Китабел-кямил» әсәрендә түбәндәгечә яза: «Хәзрәти Гомәр Габдеррахман бине Рәбиганы Сәракә бине Гомәр урынында калдырып, аңа[13] төрек белән сугышырга әмер итте. Ул сугышка әзерләнгән вакытта шәһрияр[14]: «Нәрсә эшләргә уйлыйсың?» — дип сораган. Ул[15]: «Бәләнҗәр һәм төрекне яулап алмакчы булам», — дип җавап биргән. Шәһрияр: «Без аларның безне «Тимер капкайның[16] артында тынычлыкта калдыруларына да риза һәм канәгать булыр идек», — дигәч, Габдеррахман: «Без аларның йортларына кереп сугышмасак, канәгатьләнә алмыйбыз», — дигән. Ул Бәләнҗәрне яулап ала. Хәзәрләр дә, бу хәлне күреп: «Боларны үлемнән саклап торган фәрештәләр булмаса, безнең өстебезгә килергә батырчылык итә алмаслар иде», — дигәннәр. Мөселман гаскәре Бәләнҗәрдән ике йөз фәрсәх кадәр җиргә килеп җиткәч, бердәнбер кешеләре үтерелә.

Икенче мәртәбә — хәзрәти Госман хәлифәлегендә сугышканда хәзәр төрекләре урман эченә качалар. Аларның берсе ялгыш кына бер мөселманны атып үтергәч, «гарәпләр дә үләләр икән» дип батырланып, бик күбесе бергә җыелып, зур сугыш башлый, лар. Шул сугышта Габдеррахман шәһит була. Гаскәрнең байрагын энесе Сөләйман бине Рәбига алып [гаскәр белән] яланга чыгып, Җорҗанга [сугыш белән] баралар. Бу эш аларны[17] Габдеррахманның Гәүдәсен

алып кайтудан туктатмый, алар аның [гәүдәсенә табыну юлы] белән әле дә булса яңгыр телиләр».

Якут әл-Хәмәви болай ди: «Хәзәрләр шәһитләр күмелгән урында һәр кичтә зур яктылык — нур күрәләр икән. Икенче бер сүзгә караганда, аларны олылап күмәләр, әмирләрен табут белән гыйбадәтханәләренә куялар икән. Корылык һәм ачлык заманнарында аны алып чыгып, ачып, яңгыр теләүдә файдаланалар икән»[18]. Шул турыда Габдеррахман бине Җәманәт әл-Баһили үзенең бер шигырендә Котәйбә бине Мөслим белән икесе хакында болай ди: «Безнең өчен ике изге кабер бар: берсе — Бәләнҗәрдә, берсе — Кытайда. Сиңа кайсы кабер кирәк? Кытайда булганын сугыш белән алырга кирәк, ә бусын [ягъни Бәләнҗәрдәгесен] биредә яңгыр тамчылары сугара»[19].

Тәрҗемәче[20] фикеренчә, шул гасырларда ук хәзәр халкы гомумән исламны хөрмәт иткән һәм мөселманнарга яхшы мөнәсәбәттә булган, һиҗри 104(723) елда Сабит эн-Нәһрани исемле кеше Хәзәр иленә сугышып кереп, бик күбесен җиңгән. 107(726) елда Лан мәмләкәте яулап алынып, жизья[21] түләргә риза итеп солых ясаганнар. Аннан соң 111(730) елда хәлифә Җәррах бине Габдулла әл-Хәкәмине Әрмәнстан иленә вали итеп җибәрә. Шунда Тифлис өлкәсеннән Хәзәр иленә кереп, мәдинәтел-Бәйда, Дәрбәнд, Бәләнҗәр, Хизан шәһәрләрен яулап алалар. Соңыннан хәзәр төрекләре 112(731) елда Лан өлкәсендә бик күп булып җыелып, Җәррах бине Габдулла әл-Хәкәми бераз үзенең янында булган Шам гаскәре белән хәзерләргә каршы торып, бик каты сугыш була, Хәзәрләр бик күп булганлыктан, Җәррах бине Габдулла һәм янындагы фикердәшләре Әрдәбилдә, ә кайбер риваятьләргә караганда, Бәләнҗәрдә шәһит булалар. Бу вакыйгадан соң Хәзәрләр Ислам иленә кереп, Җәзирә иленә җитеп, Тәүсыйлыә якын киләләр. Хәлифә Сәгыйдь әл-Хөрши дигән кешене Әрмәнстан иленә вали итеп җибәрә. Ул Хәзәрләрне куып Баҗәрванга кадәр килеп җитә һәм хәзәрләр белән сугыша. Бер мәртәбә Баҗәрван өлкәсендә, бер мәртәбә Рәс елгасы буенда, Бер мәртәбә Бәйләкән елгасы буенда Хәзәрләрне җиңеп, бик күп ганимәт[22] алып, мөселман әсирләрне азат итә. Шуннан соң 112(731) елда Мөслимә бине Габделмаликне Әрмәнстанга вали итеп җибәрәләр. Ул икенче елында ук Хәзәр илен яулап ала. Берничә шәһәрләрен җимереп, яндырып, әсир алып, хакан углын үтерә, Бәләнҗәр таулары арасындагыхалыклар аңа буйсынсалар да, хаканның чиксез күп гаскәр туплаганын ишетеп, Дәрбәндкә кайта.

Мөслимә гаскәрендә Мәрван бине Мөхәммәд бине Мәрван исемле кеше булган. Ул кайтып, хәлифәнең үзенә кереп: «Җәррах һәлак булганлыктан, Исламга зур хурлык булды, кимчелек килде, Мөслимә Хәзәрнең бер читенә генә кереп басты һәм гаскәрнең күплегенә мәгъруур булды. Хәзәрләргә хәбәр салып, аларның әзерләнүләрен күреп торып, һич үч алмастан кайтып китеп дөрес эшләмәде. Шуның өчен минем йөрәгем әрнеп, бу серне әйтергә лаек кеше таба алмаганлыгымнан, үзем туры сезгә килдем. Әгәр миңа йөз егерме мең гаскәр белән барырга рөхсәт бирсәгез, мин алардан үчне алыр идем», — дигән.

Хәлифә аны Әрмәнстанга вали кылып, Шам һәм Гыйрак гаскәрләрен аңа куша. Шуннан соң Мәрван Лан халкы белән сугышу хәбәрен таратып, Хәзәр патшасы белән илчеләшеп, солых ясый. Ләкин үзенә килгән Хәзәр илчесен озак тотып, шул арада сугыш кирәк-ярагын әзерләп бетереп, солыхны кире кага һәм,

Хәзәр илчесен ерак юлдан кайтарып җибәреп, үзе якын юл белән Хәзәр өстенә килеп җитә. Илче кайтып хәбәрне сөйләгәч, Хәзәр патшасы бик куркуга төшеп, хәйран кала һәм халыкның өлкәннәре белән киңәш итә башлый. Алар: «Инде йортыңны ташлап илеңнең ерак читенә китмәсәң, ул сине отты, синең белән теләсә ни эшли ала»,— диләр. Ул бу сүзне тыңлап, иленең ерак читенә кача. Мәрван Хәзәргә тәмам кереп чумып, бик күп ганимәт малы һәм әсирләр алып кайта. Юлында туры килгән «Мәлик әс-Сәрир», «Туман», «Зәригәран», «Әрзы Хәзин», «Согдан», «Ләкәз» һәм башка мәмләкәтләр аркылы үтеп, аларны да буйсындырып кайта.

Тарихчыларның олысы — Әбел-Хәсән Гали бине Хөсәен әл-Мәсгуди болай дип яза: «Хәзәр мәмләкәтендә булган халык Хәзәр патшасына буйсына. Хәзәрнең башкаласы — «Мәдинәтел-баб»тан сигез көнлек ераклыкта урнашкан «Сәмәндар» шәһәре. Анда хәзерге вакытта хәзәрдән бер ыруг тора. Аны Сөләйман бине Рәбигател-Баһили яулап алганнан соң, Хәзәр патшасы Ител шәһәренә, ягъни Хаҗитарханга күчә. Ул шәһәрдә мөселман, яһүд, христиан һәм мәҗүсиләр бар. Патшасы һәм аның якыннары — Хәзәр яһүдләре нәселеннән, Һарун әр-Рәшит хәлифәлеге вакытында Рум кайсары Әрмирус яһүдләрне үз диненә керергә кысрыклаган. Алар аны кабул итмичә, кайсар мәмләкәтеннән чыгып китеп, Хәзәр мәмләкәтенә килгәннәр. Хәзәр патшасы үзе, якыннары белән, яһүдләр диненә кергән. Әмма аның күбрәк халкы, вәзире һәм гаскәре — мөселманнар, хәзерге вәзире — Әхмәд бине Күбә исемле кеше. Шуңа күрә, Ител мәмләкәтендә өстенлек — мөселманнарда. Анда җиде казый бар. Шуларның икесе — мөселман. Алар Ислам шәригате, Коръән хөкеме белән хөкем итәләр. Икесе — яһүди. Алар Тәүрат хөкеме белән хөкем итәләр. Икесе — христиан. Алары христиан хөкеме белән хөкем итәләр. Берсе — сәкалибә. Ул рус һәм башка җаһилият[23] халкыннан булып, җаһилиятчә, яки казый акылы белән хөкем итә. Аларга үзләре белмәгән бер зур вакыйга туры килсә, мөселман казыйлары алдына килеп, ислам хөкеменә буйсыналар. Ул мөселманнар, исламның әүвәлге заманында үз мәмләкәтләрендә ваба авыруы һәм ачлык булганлыктан, Харәзем ягыннан күчеп килеп, билгеле бер шартлар нигезендә Хәзәр мәмләкәтенә кергәннәр. Алар — куәтле, куркуны белми торган, батыр, халык, аларны «ларшия»* дип атыйлар. Ул мәмләкәттә булган мөселманнарның барысын да «ларшия» дип атыйлар. Хәзәр хаканы аларга таяна. Аларның шартлары шундый: 1. Ислам динен яшермичә, мәчет һәм мәдрәсәләр салу, азан әйтеп, җәмәгать белән җомга һәм гаед намазлары уку. Патша тора торган шәһәрдә аларның күпсанлы мәчетләре һәм Коръән өйрәнү өчен мәктәпләре бар. Җамигъ мәчетләренең манарасы патша сарае өстенә карап тора. 2. Патшаның вәзире «ларшия»дән булырга циеш, 3. Хәзәр патшасы мөселманнар белән сугышса, болар катнашмаячак, башка халык белән сугышканда болар да сугышачаклар. Мөселманнарда булган сугыш кирәк-яраклары боларда да бар. Ул шәһәрдәге мөселманнар белән христианнар берләшсәләр, патшаның һичбер көче-куәте калмый. Руслар һәм сәкалибәләр — патшаның коллары һәм гаскәрләре. Хәзәр мәмләкәтендә сәүдәгәрләр йөзә торган каек һәм көймәләре белән Бортас елгасында йөриләр. Ул елга тирәсендә — Хәзәр мәмләкәте эчендә төрек халыклары бар. Аларның шәһре Болгарга барып тоташкан гыймарәтләре[24] һәрвакыт сәүдәгәрләр белән тулы була».

Шәмсетдин әд-Димәшкый үзенең «Нөхбәтед-дәһер фи гаҗаиби-бәрри вәлбәхер»[25] исемле китабында: «Хорасаннан бер гаскәр килеп Хәзәр илен яулап алды да, алар исламга керделәр», — ди.

Гыйззетдин бине өл-Әсир болай ди: «Хәзәрләр 254(867) һиҗри елда исламга керәләр. Исламга керүләренең сәбәбе шул була: төректән булган бер халык белән сугышып, Харәзем халкыннан ярдәм сорыйлар. Харәземлеләр: «Сез — кяферләр, әгәр мөселман булсагыз, сезгә ярдәм бирербез, — диләр. Алар мөселман булалар, мәгәр патшалары үз динендә кала. Мөселманнар ярдәм биреп, дошманны куып качырганнан соң, патшалары да мөселман була».

Икенче бер риваятьтә: (аларны) «Мәэмүн хәлифә яулап алып, илләренә хуҗа була, һәм алар 190(805) елларда исламга керәләр. Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытында ислам диненә керәләр», — дигән сүз дә бар.

## Болгар исеме белән бәйле рәвештә китерелгән ачык һәм дөрес хәбәрләр фасылы

Ибне әл-Әсирнең «Әсәдел-габә фи мәгърифәтне сәхабә»[26] исемле китабында әйтүенчә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең Гамир бине Әфсага терки телендә хат язып тапшыруы, Габдеррахман бине Рәбигател-Баһилинең Дәрбәндне үтеп, Хәзәр иленә ике йөз фәрсәх чамасы кергәнлеге, Мәрван бине Мөхәммәднең Хәзәр иленең иң ерак чигенә кадәр барып җитүе, бу мәмләкәттәге барлык төрек халкының «хәзәр» дип аталуы турында үткән фасылда язылган иде.

Инде бу фасылда Болгар турында дөрес хәбәрләр, ачык риваятьләр китерелә.

Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини үзенең «Асярел-биляд»[27] исемле китабында болай ди: «Әбү Хәмид[28]нең хикәят кылуына караганда, бер изге кеше Болгарга килеп керә. Болгарның патшасы һәм аның хатыны яман авыру белән авырып, тереклектән өметләре өзелгән була. Бу изге кеше аларга: «Әгәр мин сезне дәваласам, сез минем динемә керерсезме?» — ди. Алар: «Керербез», — диләр. Шулай дигәч, ул аларны дәвалап сәламәтләндерә, алар Ислам диненә керәләр һәм алар белән шул мәмләкәт халкы да мөселман була. Бу хәбәрнь ишеткәч, Хәзәр патшасы зур гаскәр белән боларга һөҗүм итә. Изге кеше Болгар халкына: «Сез курыкмагыз, «аллаһы әкбәр, аллаһы әкбәр» дип әйтегез», — ди. Халык, ул кушканча эш итеп, Хәзәр патшасын чигенергә, качарга мәҗбүр итә. Хәзәр патшасы, җиңелеп, Болгар халкы белән солых ясый һәм: «Мин сезнең гаскәр эчендә күк атларга атланган зур-зур ирләр күрдем, алар минем гаскәремне кыралар иде»,— ди. Әлеге изге кеше: «Алар аллаһы тәгаләнең безгә ярдәм итәр өчен җибәрелгән гаскәре иде»,— дип җавап бирә, «Ул изге кешенең исеме «Беләр»[29] иде, аны гарәп-ләштереп «Болгар» дигәннәр»,— дип төшендереп бирде шәһре Болгар казые. Ул Болгар тарихын язган иде һәм һиҗри белән 450(1058) елларда яшәгән кеше иде.

163(779) һиҗридә Болгар патшасы Зөбәер хан, бик зур куәт белән Ител елгасы буеннан кузгалып һәм үзен бик эре тотып, юлдагы сәкълаб һәм башка бик күп халыкны ияртеп, атлы гаскәр белән Дунай елгасын боз өстеннән үтә. Шул мәмләкәтләрне талап һәм күп ганимәт малы алып, Кастантиниядән утыз чакрым

җирдә туктый. Кайсар бик куркып, тетрәп, калтырап, малларын һәм кыйммәтле нәрсәләрен кальгасы астына яшерә, башкаласы да чак кына котылып кала».

Ибне Дастә: «Бортас иле — Хәзәр белән Болгар арасында урнашкан. Хәзәрдән унбиш көнлек юлда, Хәзәр патшасына буйсына иде», — дип яза.

«Рисаләтел-интисаб»[30]та: Болгар халкы Мәэмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәләр заманында[31] исламга керде», — дип языла.

Икенче бер риваятьтә: «Мәэмүн хәлифә аларга Җөрҗания[32] аркылы һөҗүм итә, һәм бу сугыш һиҗрәттән 190(805) елда була. Мәэмүн хәлифәнең һөҗүме һәм ул илне яулап алуы атасы Һарун әр-Рәшит хәлифәлеге вакытында иде», — диелә.

Кайбер кабиләләрнең халыклары исламга керсәләр дә, хаканга салым түләү шарты белән урыннарында калдырылалар. Бераздан соң аларга төрек һөҗүм итә, Харәземдәге мөселман гаскәрләре төрекләрнең һөҗүмен туктата. Бу Васикъ биллаһ хәлифәлеге вакытына туры килә. Шуннан соң, 254(868) елда патшалары исламга кергән булса, бу тагын күпсанлы риваятьләр барлыкка китерә. «Болгар халкы мөселман булгач, Хәзәр патшасы алар өстенә һөҗүм итеп килде», — дигән сүзне дә шуңа кушсак, Болгар патшасының исламга керүе Хәзәр патшасының исламга керүеннән элек була, ягъни Рәшит яки Мәэмүн хәлифәлеге вакытында исламга керүләре исбат ителә. Хәзәр патшасы ул вакытта мөселман булмаган, әгәр мөселман булган булса, исламга кергән өчен генә ул Болгар халкына һөҗүм итмәс иде. Алмас ханның Багдадка илче җибәрүенең һәм аннан да илче килүенең исламга кергәннән соң байтак заман үткәч булуы бик ихтимал.

Әбел-Габбас Әхмәд бине Фазлан бине әл-Габбас бине Рәшид бине Хаммад әл-Багдади — Болгар иле, аның патшалары һәм халкының хәле турында ачык хәбәрләр белән китап язучы мөселман галимнәренең беренчесе. Аны Габбасия хәлифәләреннән әмирел-мөэминин әл-Мокътәдир биллаһ Әбел-Фазыл Җәгъфәр бине әл-Мөгътәзыйд хәлифә хәзрәтләре үзенең Сәһсән әр-Рәсиби һәм Бәдәр әл-Хәрәмиләрдән торган һәм Болгарга җибәрелгән илчеләренә кятиб[33] итеп билгеләгән булган. Яшьлегемдә аның китабының кайбер кисәкләрен күреп, берникадәр нәрсә язып алган идем. Анда Якут әл-Хәмәви һәм башкалар язганнан күп артык сүзләр бар иде. Кызганычка каршы, хәзер аны кайда куйганымны белмим. Ибне Фазлан рисаләсендә болай ди: «Сәкалибә патшасы Алмас бине Сәлки Белекварның әмирел-мөэминин хәлифә әл-Мокътәдир биллаһ хәзрәтләренә язган хаты килеп ирешә. Хатында ул хәлифәдән «иленең барлык шәһәрләрендә һәм төрле якларында торып ислам динен һәм шәригатен өйрәтерлек галимнәр; мәчет һәм мөнбәрләр ярдәмендә чит ил патшаларының явыз теләкләреннән сакланыр өчен шәһәренә кальгалар төзергә оста эшчеләр җибәрүне» сорый. Хәлифә хәзрәтләре аның бу теләкләрен кабул итеп, галимнәр һәм төрле өлкәдә эшли белүче осталар җибәрә. Дәүләт эше буенча вәкил — Бәдәр әл-Хөрәми, ә илче Сәһсән әр-Рәсиби була. Багдад хәлифәлегенең башкаласы булган Мәдинәтес-сәламнән[34] һиҗрәтнең 309(921) елында, сәфәр аеның унберенче көнендә Болгарга карап юл тоттык».

Хорасан һәм Харәзем аркылы килеп, юлда күргән һәм ишеткән вакыйгаларны язганнан соң, Ибне Фазлан болай дип дәвам итә: «Барырга дип ниятләп чыккан кешебезгә — Сәкалибә патшасына бер көнлек юл калганда, Сәкалибә патшасы безне каршы алырга үзенең хөкүмәтендәге дүрт патшаны һәм

туганнарын, балаларын чыгарган иде. Алар безне икмәк, ит, ат азыгы — тарылар белән каршы алып, үзләре дә безнең белән бергә йөрделәр. Шәһре Болгарга ике фәрсәх ара калганда, патша үзе чыгып безне каршы алды. Безгә күзе төшкәч, ходага шөкер итеп сәҗдә кылды. Җиңе эчендә тәңкәләр бар иде, безгә аны чәчте. Без анда 310(922) ел мөхәррәм аеның уникесендә, якшәмбе көн килеп җиттек. Харәземнең Җөрҗания шәһәреннән анда җиткәнче җитмеш көн вакыт үтте. Безгә чатырлар, киез өйләр утырттылар, без аларга кереп җайлаштык һәм чәршәмбе көнгәчә, ягъни хәлифәнең патшага язган хатын тыңлар өчен үз җирендә булган патшалары, мәшһүр кешеләре җыелып җиткәнче шунда тордык.

Пәнҗешәмбе көн төеннәребезне ачып, киемнәребезне чыгардык, җибәрелгән ияр белән атны иярләдек, Габбасия хәлифәлеге билгесе булган махсус кара киемне һәм чалманы патшага кидердек. Мин хәлифәнең Болгар патшасына язган хатын чыгарып укыдым. Патша, хөрмәт һәм олылау йөзеннән, аякка басып тыңлады. Моннан соң ул вакытта хәлифәнең вәзире булган Хәмид бине Габбасның хатын укыдым. Бу вакытта да патша аяк өстендә торды. Ул үзе зур гәүдәле, симез тәнле, авыр бер кеше иде. Аның якыннары безгә тәңкәләр чәчтеләр. Без үзебез алып килгән бүләкләрне өләштек. Аның хатынына да бүләк кием кидердек, ул иренең янында утырган иде, аларның гадәтләре шулай икән. Шуннан соң патша безне үзенең сараена чакырды. Аның уң ягында патшалар утырган иде, безгә үзенең сул ягында урын тәкъдим итте. Балалары — алдында утырганнар, ул үзе фәкать Рум дибаҗы[35] белән генә капланган бер тәхеткә утырган иде. Боерык бирүе белән үк табын хәзерләнде, алдына кәбаб[36] китерделәр. Патша аннан өч мәртәбә кисеп алып авыз иткәч, тагын бер кисәк кисеп алып, Сәһсән әр-Рәсибигә бирде, һәркемгә аерым ашъяулык килде. Рәсми гадәтләре шулай икән. Патша авыз итмичә торып һичбер кеше ашка кул сузмый, һәркайсыбыз бер савыттан ялгыз ашап, калганын тора торган җиребезгә алып кайттык. Ашап җуйганнан соң, патша эчемлек — бал сорап алды, аны «сөҗү» диләр, үзе дә эчте, без дә эчтек.

Без килүдән элек хотбәдә аңа дога кылганда: «Аллаһеммә әслих әл-мәликә Белеквар мәликә Болгар»,[37] — дип әйтәләр иде.

Мин: «Мәлик» дигән сүз — ходаның исемнәреннән берсе булып, чын «Мәлик» — фәкать бер хода. Аннан башканы «Мәлик» дип, бигрәк тә мөнбәрдә дога кылганда, атарга тиеш түгел. Менә синең хуҗаң әмирел-мөэминин Көнчыгыш һәм Көнбатыш шәһәрләрендәге мөнбәрләрдә: «Аллаһеммә әслих габдәкә вә хәлифәтәкә әл-Мокътәдирә биллаһи әмирел-мөэмининә»[38] дип әйтергә кушты»,— дидем.

«Инде миңа ничек әйтергә кирәк?» — диде. Мин: «Үз исемеңне һәм атаңның исемен телгә ал», — дидем.

Ул: «Минем атам кяфер иде[39], үземнең исемем дә кяфер хәлендә куелган, кяфер куйган исемне телгә алуны яратмыйм мин, хуҗам әмирел-мөэмининнең исеме ничек?» — дип сорады. Мин: «Аның исеме — Җәгъфәр», — дидем.

Ул: «Мин үземә шулай Җәгъфәр дип исем куйсам, дөрес булырмы?» — диде.

Мин: «Әйе, дөрес булыр», — дидем.

Ул: «Алайса, минем исемем Җәгъфәр, атамның исеме Габдулла булсын», — диде һәм хотбә укучыга шулай телгә алырга кушты.

Шуннан соң: «Аллаһеммә әслих габдәкә Җәгъфәр бине Габдулла әмире Болгари мәүла әмирел-мөэминин»[40],— дип телгә ала торган булдылар.

Аның шәһәрендә мин хисапсыз күп гаҗаибләр[41] күрдем. Бервакыт Багдадтан килгән бер тегүчене сөйләшеп утырырга дип үземнең торагыма алып кердем. Ясигъ намазына азан әйтелүен көтеп, без аның белән ярты сәгать чамасы сөйләшеп утырдык. Азан әйткәнне ишетеп тышка чыксак, таң атып, иртә намаз вакыты җиткәнен күрдек.

Мөәззиннән: «Кайсы намаз азанын әйттең?» — дип сорадым. «Иртә намаз азанын әйттем», — ди. «Ә ясигъ намазы кайда?» — дип сорадым. «Аны ахшам белән бергә укыйбыз»,— диде. «Кич кайда соң?» — дип сорадым. «Үзең күргәнчә, хәзер бераз озайды әле, югыйсә моннан да кыскарак иде, иртә намаз калмасын дип, бер ай чамасы кичләрен йокламадым», — диде.

Икенче кичәдә карасам да, йолдызлар күрмәдел. Анда-монда гына ун-унбишләп йолдыз күренә. Шәфәкъ кызыллыгы бөтенләй батмый, кич бик якты. Кешене Бер ук атымы җирдән танып була, аларны күрдем мин.

«Эт улаганнан еллар иркенчелек, бәрәкәтле һәм сәламәтчән була», — диделәр.

Аларда елан бик күп икән, хәтта бер агач ботагына уннан артык елан чорнала, ләкин алар еланны үтермиләр, чөнки елан аларга зарар итми.

Аларның бик әче яшел алмалары бар, аны кызлар ашап симерәләр.

Ул йортта чикләвек агачыннан күп агач юк, 40 мөрәббәгъ[42] фәрсәх чамасы урманнары шуның белән тулы. Анда мин тагын бер агач күрдем, ләкин нинди агач икәнен белмим, үзе бик биек, буенда яфрагы юк, башы хөрмә агачы башы шикелле, яфраклары башында җыелып тора. Ул агачның бер җиреннән тишеп, астына бер савыт куеп, суын алалар; балдан да тәмлерәк була, кеше күбрәк эчсә — исерә». Тәрҗемәче[43] фикеренчә, бу агач каен булмаска кирәк, чөнки каен булган тәкъдирдә, аны Ибне Фазлан белеп, «хәдәнҗ» дип аңлаткан булыр иде.

Тагын Ибне Фазлан болай ди: «Аларның күбрәк ашаган азыклары — тары һәм ат ите. Шулай ук аларда арпа белән бодай да күп. «Берәү иген иксә, уңышын үзе ала, патшалыкка бирелә торган хак юк, ләкин алар һәр йорттан патшага үгез тиресе бирәләр». Тәрҗемәче фикеренчә, бу үгез тиресе дигәннәре иләп эшләнгән һәм «болгари» дип йөртелә торган калын күн булырга кирәк.

«Әгәр патша берәр тарафка, берәр шәһәргә һөҗүм итеп, таларга гаскәр җибәрсә, гаскәр белән бергә аңа да өлеш була, — дип дәвам итә Ибне Фазлан.— Аларда балык маеннан башка май юк, аны зәйтүн мае урынына тоталар... Алар барысы да башларына бүрек кияләр. Патша үзе генә, ялгыз йөри. Әгәр ул базардан үтеп китсә, барлык халык урыныннан торып, башыннан бүреген алып култык астына кыстыра. Патша узып киткәч, алып кияләр. Патша янына кергән вакытта, олысы һәм кечесе булсын, хәтта үз балалары һәм туганнары да, патшаның күзе төшкән вакытта башларыннан бүрекләрен алып култык asларына кыстырып, башлары белән ишарә кылып утыралар. Патша утырырга кушканчы аягүрә торалар, һәркем утырганда тез чүгеп утыра. Бүрекне патша алдыннан чыгып китмичә күрсәтмиләр, чыккач кына башларына кияләр.

Аларда яшен яшьнәү бик күп була. Әгәр дә берәүнең йортын яшен сукса, янып беткәнче аңа якын бармыйлар, аны алланың ачуы төшкән җир диләр.

Әгәр аларда берәү гадәттән тыш данлы, мактаулы, бик тырыш һәм зур гыйлем иясе булса, моның хакы — раббебез аллаһе тәгаләгә корбан булу, дип, тотып муенына бау бәйләп, агачка асып куялар. Ул шунда үзе өзелеп төшкәнче асылынып тора».

Мөтәрҗим[44] фәкыйрь әйтә: хәзерге заманыбызда әйтелә торган, «күпне белсәң — асарлар, юаш булсаң — басарлар» дигән әйтем шуннан калган булырга тиеш. Шуңа охшаш икенче бер начар мәгънәдә кул» ланыла торган сүз бар: «ат азгыны юрга була, адәм азгыны мулла була». Гыйлем иясе кешедән көнләшеп, аны кечерәйтеп һәм аңарга нәфрәтләнеп карау гыйлем дәрәҗәсендә артта калуга сәбәп булган. Шуның өчен дә инде алардан хәзергә кадәр күренекле галим булган, гыйлемдә, фәндә язган хезмәтләре белән матур эз калдырган кеше күренми.

Ибне Фазлан тагын болай дип яза: «Алар юлда вакытта араларыннан берсе сугыш кораллары, ягъни мылтык, кылыч, сөңге кебек нәрсәләр белән сияргә утырса, үзләренең гадәтләре буенча, аның янында булган коралларын алалар. Әгәр ул коралларны үзе салып бер читкә куеп торса, аңа һич комачауламыйлар».

Тәрҗемәче фәкыйрь бу турыда болай дип әйтә: аларның бу эшләре батырлык һәм сугышчанлыкларыннан булырга кирәк. Алар сугыш коралын олылыйлар. Шуңа күрә каберләренә куелган ташларның кайберләрендә: «альшуари», ягъни, безнең телебезчә, «алышмак ире», «алдынгы сугышчы»; кайберләрендә: «юари», ягъни «сугышчы егет»; кайберләрендә: «әл-гаҗес», ягъни «дошманга каршы чыгучы» дип язылган.

«Аларның ирләре һәм хатыннары ялангач килеш бергә су коеналар, бер-берсеннән бер дә яшеренмиләр. Суга кергәндә хатыннар ирләрдән пәрдәләнсеннәр, яшересеннәр дип күпме тырышсам да, теләгемә ирешә алмадым, — ди Ибне Фазлан. — Аларда зина кылу бер дә юк, әгәр дә берәү зина кылса, синди кеше булуына карамастан, дүрт казык кагып, ике кул һәм ике аягын шүл казыкларга бәйләп, ир һәм хатынны муеныннан ботына кадәр балта белән ярып, һәрбер кисәген бер агачка асалар. Каракка да шундый ук җәзаны бирәләр».

Тарихчыларның өлкәне Әбел-Хәсән бине әл-Хөсәен бине Гали әл-Мәсгуди әл-Багдади[45] болай дип әйтә: «Болгар шәһәре Мантыш дәрьясы үзәнендә урнашкан. Мин алармы дөньяның җиденче Икълимендә дип беләм. Алар — төрек халкының бер төре. Алардан Харәзем шәһәренә, ә Хорасан һәм Харәзем җирләреннән һәм башка төрек далаларыннан үзләренә бертуктаусыз кәрван йөреп тора. Ошбу вакытыбыздагы, 332(942) елдагы Болгар патшасы — мөселман. Ул Мокътәдир биллаһ хәлифә вакытында, үзенең күргән теше сәбәпле мөселман була. Аның бер баласы хаҗ кылып, мәдинәтес-сәламгә — Багдадка килә, Мокътәдир хәлиф аңа олы һәм кечкенә галәмнәр[46] һәм кара киемнәр бирә. Аларның җамигъ мәчетләре бар. Ошбу патша илле меңләп атлы гаскәр белән Кастантиния шәһәренә һөҗүм игеп, алар аның тирә-ягын бик каты талыйлар, хәтта Рум иленә һәм Әндәлескә барып җитәләр. Борҗан, Җәлаләка җиренә һәм Франк мәмләкәтләренә кадәр баралар. Аларга ярдәмгә диңгез белән бер төркем халык килеп, патшаларының якын килүе турында хәбәр бирәләр...

Болгар сәрийяләренең[47] кайбер төркемнәре бәх-ре Рум[48] буйларына барып җитә.

Аларның бер төркеме Тарсус көймәләре белән Тарсуска килә.

Болгарлар — куркуны белми торган, куәтле, бик гайрәтле олы бер халык. Аларга күрше булган халыклар барысы да буйсынып, баш иеп торалар. Аларның бер атлы мөселман баһадиры бер йөз, ике йөз кяферга каршы торып сугыша[49]. Кастантиния халкы һәм шул тирәдәге башка халыклар да алардан бару тик нык һәм биек кальгалары булганга гына сакланып тора алалар.

Болгарда җәй көне тән бик кыска була». Янә әл-Мәсгуди әл-Багдади болай дип дәвам итә: «һиҗрәттән 300(912) елдан соң рус халкы, һәр көймәгә бишәр йөз кеше утырткан биш йөз көймә[50] белән, Хәзәр елгасына тоташкан Нитыш диңгезе тармагына керә. Ул урында Хәзәр патшасының шул җирне сакларга куйган гаскәре аларны диңгезгә җибәрмәгәч, Хәзәр патшасы белән килешү төзиләр. Кулга төшерәчәк ганимәтләренең яртысын Хәзәр патшасына бирү шарты белән, елга белән төшеп, Хәзәр диңгезенә керергә рөхсәт алалар. Диңгезнең аргы ягына үтеп, диңгез буйларында, ислам мәмләкәтләренең читендә урнашкан Җәел, Диләм, Табаристан, Әбскүн һәм Җөрҗан[51] өлкәләрен талап, яндырып, күп каннар түгеп, җимереп, әсирләр һәм ганимәт маллары алып кайтып китәләр. Хәзәр елгасы авызына килеп, патшага шарт кылган малларын биреп юлга чыгалар. Бу хәлне Ларшия кавеме һәм Хәзәр илендәге мөселманнар белеп алып, Хәзәр патшасына: «Бу россия-леләр мөселманнарны талап, каннар түгеп, хатыннарны, бала-чагаларны әсир иткәннәр, безне җибәр, без алардан мөселман кардәшләребезнең үчен алабыз», — дип әйтеп, сугышка хәзерләнәләр. Хәзәр патшасы аларны тоткарлый алмый. Ләкин ул аларның усал уйларын русларга белдерә. Мөселманнар русларны эзләп чыгып, су белән төшеп китәләр. Бер-берсенә каршы килеп күзгә-күз очрашкач, руслар көймәләреннән чыгып, каршы тезеләләр. Мөселманнар белән Идел шәһәреннән бераз христианнар да була. Мөселманнарның унбиш мең яхшы атлары һәм кораллары була. Өч көн бик каты сугышалар. Уюда мөселманнарга ярдәлл биреп, алар русларны бик яман кыралар. Русларның утыз мең кадәресе кешесе кайсы суга батып, кайсы һәлак булып, биш мең кадәресе көймә белән Бортас иле ягына килеп, көймәләрен калдырып коры җиргә чыгалар. Аларның кайсыларын бортаслар, кайсыларын Болгар мөселманнары үтерәләр. Шуннан соң руслар икенче мәртәбә мондый эшне эшләмиләр»[52].

Тәрҗемәче фәкыйрь бу хакта болай дип әйтә: «Болгар мөселманнары үтерәләр», — дип әйтү — аларның сугышка катнашмый калганнары, өйләрендә калганнары турында булыр. Чөнки бу мәмләкәтнең мөселманнары барысы да электә «ларшия» дип атала торган булганнар.

Бу хикәят Хәзәр мәмләкәтләрендә һәм Болгарда ислам таралып, мөселманнар куәтләнеп, Хәзәр хаканының сүзе үтми башлавын, мөселманнарны тыеп, үзенең солых белән бәйләнгән дуслары булган русларга ярдәм итә алмыйча, аларга бары хәбәр бирүдән башканы эшли алмаслык хәлгә килүен күрсәтә.

Мәсгуди үзенең «Мөрәүвиҗаз-зәһәб»[53] исемле китабының басма нөсхәсендә бу хикәятне сөйләгәндә «Болгар» дигән сүзне «Былгыр» дип, «л» хәрефе белән әйтә.

Әмма Якут әл-Хәмәви «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китабында бу сүзне Мәсгудидән «Быргыр» үрнәгендә күчерә. «Мәсгудинең «Быргыр» һәм «мәдинәтел-Быргыр» дигәне — ул мәшһүр Болгар. Бу сыйфатлар — һәммәсе дә Болгар сыйфаты, моны мин «бары икенче төрле әйтелеш» дип кенә уйлыйм. Ләкин «Мантыш үзәнендә» дигәне дөрес һәм муафыйк түгел. Минем уемча, Болгар шәһәре белән Мантыш[54] диңгезе арасы бик ерак», — ди.

Тәрҗемәче фәкыйрь фикеренчә дә Якут әл-Хәмәвинең бу сүзе дөрес. Ләкин Мәсгудинең язуында берәр ялгыш җөмлә калган булырга тиеш. Чөнки Мәсгуди үзе дә: «Болгар белән Кастантиния арасында ике айлык юл», — ди һәм Хәзәр диңгезе Мантыш диңгезенә һәм Кастантиниягә тоташкан дигән сүзне юкка чыгара. «Бу диңгезнең икенче бер диңгезгә тоташуы юк, аның кечкенә бер диңгез икәнен һәркем белә», — ди.

Шәмсетдин әд-Димәшкый болай дип яза: «Болгарлар бер мәмләкәт булып яшиләр. Алар — мөселманнар, Мокътәдир хәлифә вакытында мөселман булалар. Патшалары Мокътәдир хәлифәгә илче җибәреп, ислам кагыйдәләрен өйрәнү өчен галимнәр сорый, хәлифә аның үтенечен үти. Шуннан соң Болгардан бер җәмәгать хаҗ кылу теләге белән Багдадка килә, Анда аларга хайваннар һәм торыр урын белән ярдәм итәләр...»

Әбү Габдулла Мөхәммәд бине Габдеррәхим бине Сөләйман әл-Гарнатый Болгарга берничә мәртәбә килеп, Болгар казые белән берничә мәртәбә очраша. Ул үзенең «Төхфәтел-әлбаб»[55] исемле китабында болай дип яза: «Болгар — ике якка утырган. Бинaлары — агачтан һәм камыштан. Ул — Идел елгасы буена салынган. Мәчетләре — базарда. Суар шәһәре дә шул ук елга буенда. Аларның бинaлары — киез өйләр, иген җирләре бик киң, бик яхшы. Болгар һәм Хәзәрләрнең телләре бер, әмма бортас һәм рус теле — башка. Болгар — шәһәр исеме, анда җамигъ мәчет бар, халкы мөселман. Якында тагын бер шәһәр бар, «Суар» диләр. Анда да җамигъ мәчет бар, Ирләр ун мең чамасы исәпләнә...» Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: «Суар шәһәренең хәрабәсе Болгар шәһәренә бик якын. Шул тирә-як мөселманнары хәзер дә «Суар» дип сөйләшәләр, хәрабәсендә Иске Курсиха дигән бер рус авылы утыра.

Әл-Гарнатый тагын болай ди: «Бортас — бер кавемнең исеме, аларның җирләре киң. Ул җир дә, алар исеме белән аталып, «Бортас җире» дип йөртелә. Үзе — Хәзәргә чиктәш, араларында икенче халык юк. Идел буена җәелеп утырганнар. Алар үзләре мөселманнар, зур мәчетләре бар. Телләре — терки дә, хәзәр һәм Болгар теле дә түгел. Бортас — шәһәр һәм өлкә исеме. Аларда кызыл төстә, калын йонлы бик матур төлке бар, шул төлке тиресеннән «бортас туны» дип дан тоткан тун тегелә. Иделдән, ягъни Әстерхан шәһәреннән Болгарга коры юлдан бер айлык, судан менгәндә ике айлык, төшкәндә егерлле көнлек юл».

Әбү Хәмид әл-Әндәлеси болай ди: «Болгарлар, хәзерләр һәм бежтәкләрнең[56] киемнәре — озын күлмәк, ә русларның киеме — кыска. Башҗырд[57] халкы Болгарга буйсына.

Руслар өч төркемнән гыйбарәт, берсе — Болгарга якын, хөкемдарлары Киев шәһәрендә тора, ул — Болгардан зуррак».

Шәмсетдин әд-Димәшкый әйтә: «Бортас халкы Иделгә коя торган һәм үзләренең исеме белән «Бортас» дип атала торган су буена утырган. Өйләре

киездән һәм агачтан. Хәзәр белән аралары — 15 көнлек юл. Аларның үзләренә хас телләре бар.

Кыпчакларга килгәндә, алар Ширван һәм Дәрбәнд артындагы тауларда һәм Бәхре рус буендагы иңкүлекләрдә яшиләр. Аларның Сәрдык исемле шәһәрләре бар. Диңгез дә шул шәһәргә якын. Аннан азык-төлек китерәләр. Кирәк булган кием-салым һәм башкаларны сату, ир һәм кыз коллар, кондыз тиресе, әсирләр[58] сатып алу өчен аларга сәүдәгәрләр киләләр. Болардан бер төркемне аллаһе тәгалә Мисырда һәм Шамда яшәтә.

Шигырь: Бу халык әгәр үтерелсә — фәрештә була; ә сугышканда гыйфрит кебек сугыша[59].

Кыпчаклар барысы да төрек халыклары булып, алар «беркева», «туксаба», «исәба», «бәрәт», «әрәс», «тәбәрреж уты», «мәңгү углы», «ямәк» дип аталалар. Болар барысы да Харәземнән чыккан. Аларның «тыйг», «башкорт», «камәнгү», «бизангә», «бәҗна», «Карабәкле», «әз», «җөртан» дигән һәм башка бик күп исемдә вак кабиләләре бар».

Янә Шәмсетдин әд-Димәшкый «Мәҗмәгыль-әнсаб»[60]та болай дип яза: «Болгар — көнбатыш белән төньяк арасында, төньяк котыпка якынрак урнашкан. Аларның Суар һәм Болгар дигән ике шәһәре бар. Бу ике шәһәрнең арасы — ике көнлек юл. Суы-елгасы да бар. Елга буенда бик калын урман җәелгән. Халкы — барысы да мөселман, ләкин бертуктаусыз кяферләр белән сугышып торалар. Аларның урманнарында кеш, тиен, кондыз бик күп була».

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: монда Суар дип аталган шәһәр Сембер шәһәре [урынында] түгел микән. Чөнки хәзер дә Суар дип аталган шәһәр хәрабәсе шәһре Болгарга бик якын, аларның ике араларында андый су да юк.

«Раузатес-сафа[61] китабында: «Алар һәммәсе мөселман, хәнәфи мәзһәбендә», — дип язылган. Хәнәфи мәзһәбендә булган галимнәрдән фәтва сораулары һәм Болгар халкының тырышлыгы һәм өндәүләре белән исламга кергән башкортларның соңгы дәвердә дә хәнәфи мәзһәбендә булулары «Раузатес-сафа» сүзен куәтли.

«Фәрһәң»дә: «Болгар һәм Синфар дигән ике зур шәһәр бар»,— диелә.

«Рисаләтел-интисаб»та: «Болгар җире — ислам төрекләре иле. Алар Габбасия дәүләтендә Мәәмүн һәм Васикъ биллаһ хәлифәлек иткән вакытта мөселманлыкка керделәр һәм тагын әл-Каиме би-Әмриллаһ хәлифәлегендә утыз мең йорт мөселман булды», — диелә.

Якут әл-Хәмәви: «Хәләб шәһәрендә бер башкорт мелласын күрдем. Ул: «Борынгы заманда шәһре Болгардан җиде кеше килеп, бик тырышып өндәп, безне Ислам диненә керттеләр», — диде», — ди.

Кайбер тарих китапларында мондый мәгълүматлар язылган: «Бортас — Болгарга тоташ. Алар бер төз генә җирдә, Хәзәр диңгезенә коя торган «Ител» исемле бер елга буена утырганнар. Җирләре — тугайлык һәм бик куе урман, агачларының күбесе — каен агачы. Алар белән Болгар арасы — өч көнлек юл. Хайваннары, игеннәре бар. Патшаларына хайван бирәләр. Мөселманнар көймәсе килсә, малдан гошер[62] алалар. Киемнәре һәм каберләре мөселманнарныкына охшаган, Болгарлар аларга һөҗүм итеп торалар. Алар Хәзәр белән Болгар арасында урнашкан. Алар белән Хәзәр арасында унбиш көнлек юл. Алар Хәзәр

патшасына буйсыналар. Аларның ун меңләп атлы гаскәре бар. Гомуми башлыклары юк, ләкин һәрбер мәхәлләдә бер шәехләре бар, шуның алдына хөкемгә киләләр».

Тәрҗемәче фәкыйрь әйтә: Бу — исламга кергәнгә кадәрге хәлләре булырга тиеш. Югыйсә Болгар патшасы үзенә якын урында үзенә каршы булган бер халыкны тотмас иде. Алар шул ук вакытта, мөселманга ияреп, мөселманнар кебек үк гыйбадәт кылалар икән. Аларның мөселман булулары, зур мәчетләре булу турында Әбү Габдулла әл-Гарнатый һәм башкалар да сөйлиләр...

...375(985) елларда, бәлки аннан да элегрәк булуы ихтимал, христиан диненә кергәнче, Россия хөкемдары Владимир, диннәрнең берсен сайлап һәм шуңа керер алдыннан, шәһре Болгардан мөселман дине белгечләрен чакыртып алган. Болгар патшасы берничә дин белгечен әзерләп җибәргән. Алар Россия мәмләкәтенә барып, ислам дине кагыйдәләрен аңлатып йөргәннәр. Бу исә ул вакытта Болгарда Ислам диненең көчле булуына, ә халкының Ислам динен нык тотуына, аның кагыйдәләрен яхшы белүенә дәлил булып тора.

Якут әл-Хәмәви 626(1229) елда вафат булган. Ул, башкорт мелласыннан ишеткәне буенча, башкортларның ислам диненә керү сәбәпләрен түбәндәгечә аңлата: «Бик борынгы заманнарда Болгар халкыннан җиде кеше килеп, бабаларыбызны хак юлга күндергәннәр». Бу сүзгә нигезләнеп, аларның [болгарларның] ислам динен кабул итүләре бер, ике, өч гасыр элек кенә түгел, ә бик борынгы заманда булуын аермачык әйтеп була, Бу өч мисалның һәркайсы аларның [болгарларның] ислам динен кабул итүләренең тарихы билгеле булмавына дәлил булып тора. Болгар халкының ислам диненә Габбасия хәлифәлеге* һәм Һарун әр-Рәшид Мәэмүн гасырында гына түгел, ә бәлки аңа кадәр үк керүләренә дәлил булып тора. Әмма Болгар патшалыгы кешеләре ул вакытта әле һәммәсе дә ислам дкненә кермәгәннәр. Кергәннәренең мөселман булуларына бер гасыр тулып килгәндә, дәүләтләре рәсми рәвештә тулысынча Ислам динен кабул иткән. Динне башлап кабул итүчеләре Мокътәдир биллаһ хәлифә заманында ислам диненә кергәннәр.

## Болгарларның сугышлары турындагы фасыл

Болгар халкы батыр йөрәкле, баһадир, курку белмәс, сугышчан, диндар, изгелекле халык була. Шуңе да алар сугыш коралын олылыйлар, хөрмәт итәләр һәм бу сыйфатлары белән мактаналар да. Аларның кыскача хәлләре турында Византия һәм Рум халыкларына*, аларның патшаларына милади белән 500 нче ел ахырларында мәгълүм булу турында хәбәрләр бар. Алар турында шул тирәләргә ясаган һөҗүмнәреннән беләләр һәм аларны «һуннар», «утугырлар», «кутугырлар»** дип берничә исем белән атыйлар. Аларның юлларын кисү, һөҗүмнәрен туктату өчен император Анастасия озын һәм биек койма койдырса да, туктата алмый. Алар император Юстиниан гасырында тагын һөҗүм итәләр. Икенче елда янә икенче мәртәбә һөҗүм итсәләр дә, бу юлы үзләре җиңелүгә дучар булалар.

Болгар патшаларыннан «Зөбәер хан» дигән кеше Ител елгасы буеннан кузгалып, бик зур куәт белән йөреп, славяннарны һәм башка бик күп Таифәләрне

ияртеп, атлы гаскәрләре белән Дунай суын боз өстеннән үтеп, шул тарафларда булган мәмләкәтләрне талап, халкын үтереп, Кастантиниядән утыз чакрым ераклыктагы җиргә килеп туктый. Юстиниан кайсәр бик каты куркып, калтырап, тетрәп, малларын һәм кыйммәтле нәрсәләрен крепосте астына яшерә, башкаласы да чак кына котылып кала.

Моннан соң Ител елгасының көнчыгыш тарафыннан Бәян хан дигән бер кеше чыгып, Болгар халкын һәм башка шул мәмләкәттә яшәүче Таифәләрне үзенә буйсындыра. Аннары Болгар хөкемдары Карабат[63] диген кеше күтәрелеп, аның үзеннән соң өч углы кала. Беренчесе, ягъни олы углы Батбай үзенә буйсынучылар белән үз ватанында кала һәм бераз вакыт үткәч Хәзәр* хөкемдарына буйсына. Икенчесе — Котраг, Дон елгасының көнбатыш ягына үтеп, шул җирне үзенә ватан итә. Өченчесе — Асбаруг, күпчелек халкы һәм терлек-туары белән Днестр елгасыннан үтеп, кайбер славяннарны үзенә буйсындырып, Берҗан мәмләкәтендә** нигезләнә. Алар Дунай елгасының тирә-ягын талаганлыктан, Константин кайсар коры җирдә һәм диңгездә зур көчләр туплый, ләкин барыбер гаскәре җиңелеп кача. Болгарлылар җиңеп, кайсарга һәм Дунай буендагы башка мәмләкәтләргә салым салалар.

Шул заманда, 60(679) һиҗри елда, болардан бер төркем халык аерылып китеп, Дунай буенда нигезләнеп, «Кечек Болгар дәүләте» дигән мөстәкыйль бер хөкүмәт төзиләр. Рум халкы аларны «Кечек Болгар» дип атап, Ител елгасы буендагы борынгы «Зур Бол-гар»дан аерып йөртә. Кайбер тарихчылар Зур Болгарны — «Кара Болгар», кайсылары — «Ак Болгар» яки «Эчке Болгар» дип атыйлар. «Кара» дип исемләнүләре Габбасия хәлифәләренә ияреп, аларның тамгасы булган кара байрак һәм кара киемгә ихтыяр итүләренә бәйле. Мәдәниятле һәм гыйлем ияләре булганга «ак» дип, ә исламга кергәнгә яки хәлифәлек хөкемендә булганга «эчке» дип әйтелгән булыр.

Дунай болгарларының «Багар» исемле хөкемдарлары 184(800) елда Румнарга ияреп христианлык кабул итә һәм «Михаил» дип атала. Аларның Шәмгун исемле мәшһүр хөкемдарлары һиҗри 275(888) елдан 330(941) елга кадәр хөкемдарлык итә, «бундукия»*, «серб», «харват» һзм башка күршеләре белән берләшеп, хәтта гарәпләр белән дә солых ясап, кайсар белән сугышка әзерләнә. Дунай болгарлары христианлыкны кабул иткәч, Кайсар аларның ярдәме һәм булышлыгыннан файдаланырга уйлый, ләкин киресенчә килеп чыга...

Мәсгуди аның Россиянең Идел елгасы белән төшеп, Каспий диңгезе тарафларын басып, әсирләр һәм сугышта кулга төшкән дошман малларын алып кайтучы 250 меңлек гаскәрен болгарларның 15 мең кешелек гаскәре җиңүен, Әмир Җәгъфәр бине Габдулланың 332(943) елның азагында 50 меңнән артык атлы гаскәр белән Кастантиниягә каршы сугышып барганын яза. Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини ислам динен кабул иткәннән соң Хәзәр хаканы булырга ниятләсә дә, аны булдырмый калуларын хәбәр итә... Ибне Хаукаль, Ибне әл-Әсир һәм башкалар болай диләр: «358(968) елда Россия хөкемдары үз иле һәм күршеләре, кыпчактан бер төркем төрекләр ярдәме белән болгарларны җиңгәч, үзара солых ясыйлар, ул сугышта болгарларга бик зур таркаулык китерәләр. Алар таш суда йөзә башлаганга, колмак төпкә батканга кадәр солыхны сакларга тиеш булалар. 375(985) елда Россия хөкемдары Владимир Болгарга килеп, ныклы

нигездә чынлап солых ясый. Ислам динен яхшы дип танып, үзе ислам диненә керергә уйлый. Шуннан соң, Суздаль җирендә ачлык булганда, болгарлар россиялеләргә күп икмәк бирәләр. Берникадәр вакыттан соң солыхлары бозылып, 481(1088) елда болгарлар Россиядән Муром шәһәрен алалар. 559(1163) елда Андрей Иванович дигән Россия хөкемдары болгарлар өстенә килеп, аларны җиңә. Болгар әмирен куркытып качырып Һәал әләмнәрен алып, Ибраһим шәһәрен һәм башка берничә шәһәрне яндыра. Рус халкы, бу җиңүне искә төшереп, әле дә булса һәр елның август башында бәйрәм итә**. 567(1171) елда әлеге хөкемдар үзенең углын гаскәр башы итеп тагын болгарлар өстенә җибәрә. Бу юлы болгарлар естен чыгып, Россия гаскәрен тәмам җиңәләр, ә гаскәр башлыклары көчкә качып котыла. 579(1183) елда болгарлар Муром һәм Рязань шәһәренә һөҗүм итәләр. Моннан соң Россия хөкемдары, кыпчак төрекләре белән берләшеп, янә шәһре Болгарны чолгап ала, ләкин Россиянең олы хөкемдары Всеволод бине Егорның яшь энесе Изяславның яралануы сәбәпле җиңелеп, солых ясап кайтып китә. 582(1186) елда россиялеләр тагын Болгар мәмләкәтенә киләләр. 615(1218) елда болгарлар Устюг шәһәрен барып алалар. Бу вакыйгадан соң руслар Болгар мәмләкәтенә килеп, биек имәннән ике кат койма белән әйләндереп алынган, ә коймаларының уртасына канау казып эшләнгән Ашлы кальгасын яндырып, күп һәлакәт китерәләр.

Ибне әл-Әсир һәм Ибне Халдун болай ди: «Татарлар Дәрбәнд тарафыннан килеп чыгып, шул тирәдә яшәүче мөселманнарны, кяферләрне, бигрәк тә лан*, кыпчак һәм русларны үтереп, бик каты талап, яндырып, бөтенләй харап итү дәрәҗәсенә китерәләр. Болардан бушангач, 620(1223) елның ахырында Болгар мәмләкәтенә барырга уйлыйлар. Болгар халкы бу хәбәрне ишеткәч, алар юлында берничә җирдә яшеренеп, посып тору урыннары — бөктермәләр ясап, аларга каршы чыгалар. Татарлар килеп җитеп, посып тору урыннарын әзрәк үтү белән, болгарлар боларның артларыннан чыгалар һәм аларны һәрьяктан урап алып сугыш ачалар, татарларның күбесен үтереп бетерәләр. Бик азы гына качып котылып, Саксин ягына китәләр һәм Талкан дигән җирдә үзләренең патшалары — Чыңгыз ханга юлыгып, барлык маҗараларны сөйләп бирәләр. Бу вакыйгадан соң Дәште кыпчак** татарлардан бушап кала. Юллар тынычланып, сәүдәләр ачылып китә һәм элеккечә кәрваннар йөри башлый. Кыпчакларның һәм русларның да сәламәт калганнары илләренә кайта».

633(1235) елда, Бату хан гасырында, татарларның Субутай дигән гаскәр башлыгы белән зур көчләре Болгарга килә. Болгарлар аларга түбәнчелек һәм итагать күрсәтеп, татар мәмләкәтенең бер өлеше булырга һәм аңа салым түләп торырга риза булалар. Шулай итеп, татарлар аларны бөтенләй үз кулларына алалар, әмма дәүләтләрен бетермиләр. Болгарлар аларга яраклашып яшәп, акча сугуда һәм хөтбәләрдә аларны телгә алсалар да һәм салым түләсәләр дә, кайвакытта татарларның кыргыйлыклары һәм эчке дошманлык сәбәпле ике арада сугыш һәм бәрелешләр дә булып тора. Мәсәлән, Мәңгү Тимер хан бик зур гаскәр белән Болгарга һөҗүм итеп, аны җиңә һем солых төзеп кайта. Шул ук вакытта Россиядән Новгород халкы да Болгарга кат-кат һөҗүм итеп, аны талый. 761(1359) елда руслар Жукотин (Җүкәтау) шәһәренә керәләр*. Шуннан соңгы елда Россия хөкемдары Дмитрий бине Константин һәм башкаларның Болгар җирен

талаганнары ечен болгарлар Үзбәк ханга шикаять язып, рус хөкемдарларын җавапка тарталар**. Руслар, хан хозурына хөкемгә килеп, талаучыларны табып биреп кенә котылып калалар. 762(1360) елда Болгар әмире Фулат Тимер заманында болгарлар Нижний Новгород чигенә һөҗүм итсәләр дә, Мамай мирза ярдәме белән Суздаль хөкемдары Дмитрий бине Константинның углы Василий аларның һөҗүмнәрен туктата. 763(1361) елда Новгород халкы Болгар мәмләкәтен талый.

778(1376) елда Россия хөкемдары Дмитрий бине Иван, татар хөкүмәтеннән чыгу теләге белән, Болгарның бай җирләрен яулап алу өчен Суздаль гаскәре белән кушылып, Болгар мәмләкәтенә һөҗүм итә. Берникадәр авылларны, Казанның көймәләрен яндыра. Казан халкы, 5000 тәңкә акча биреп, Мәскәү тамгасын кабул итә. Болгар әмире Хәсән һәм аның туганы Мәхмүд түбәнчелек белән солых төзиләр. 785 (1383) елда Туктамыш ханның котыртуы белән болгарлар русларга һөҗүм итәләр, талыйлар һәм үтерәләр. 793(1391) елда Россия хөкемдары Василий бине Дмитрий Болгар мәмләкәтеннән Жукотин, Кирмәнчек һәм башка шәһәрләрне алып, үзенә «Болгарны яулап алучы» дигән исем тага. 835(1431) елда Василий бине Василийның гаскәр башлыгы Болгарга керә. Ләкин Болгарның Россия кулына бөтенләй кайчан керүе, кайсы заманда аның тәмам харап булуы безгә мәгълүм түгел. Гомумән, Тимер дәвере үткәнче дәүләтләре яши, мөстәкыйль патшалык силсилә[64]се дәвам итә. Гәрчә халык телендә: «Тимер Болгарга керде, шәһәрен җимерде, патшасын һәм дәүләтенең олыларын юк итте», — дигән сүзләр йөрсә дә, ышанычлы һәм дөресләнгән хәбәрләр түгел. Бәлки халык аны Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслими тарихыннан алып әйтә торгзндыр, ләкин ул китап игътибарга лаек. түгел.

Якут әл-Хәмәви үзенең «Мөгъҗәмел-бөлдан» исемле китабында, татарлар Болгарга килеп җиттеләр, дип кенә әйтә дә, чолгап алу һәм аны яулап алу турында ләм-мим.

«Раузатес-сафз»да һәм башкаларда: «Аксак Тимер Туктамыш ханга-һөҗүмендә шәфәкъ батмый торган җиргә житте», — дип әйтү белән генә чикләнелә. Әмма: «Болгарны алды, харап итте, җимерде, барын да үтерде», — дигән сүз әйтелми. Аксак Тимер Кытай сәфәрендә 807(1405) елда «Утрар» дигән җирдә вафат була һәм бу аның вәфаты тарихын сөйли торган сүз булып кала. Аның гасырыннан соң Болгарда татар ханнары исеменә сугылган тәңкәләр күпләп табыла. Бәс, шулай булгач, Тимер Болгарны бөтенләй җимерде дигән сүз дөрес булмый.

## Болгар халкының әсәрләре һәм галимнәре турындагы фасыл

Алмас хан гасырында Болгарның үзендә һәм читтән килүчеләр арасында дин һәм шәригать хөкемнәреннән хәбәрдар булган галимнәр һәм хәкимнәр булган дип уйланыла. Шуңа да карамастан, ул, татарларның иске мәкальләрендә әйтелгәнчә, «олы казанда кайнаган ит чи калмас» дип, Багдад хәлифәлегенә* илчеләр җибәреп, дин һәм Ислам әдәпләрен, кием кию һәм тормыш рәвешләрен өйрәтү өчен Ислам хәлифәсеннән галимнәр, һәрбер эштә оста булган белгечләр

сораган. Әмма үзләреннән махсус, ачык итеп язылган тарих китаплары калмаганлыктән, патшаларның, галимнәрнең һәм башка кешеләрнең күпчелегенең дөрес хәлләре мәгълүм түгел. Болгарның казые булган Ягькуб бине Ногман әл-Болгар дигән кешенең Болгарга багышланган махсус тарих китабы булганлыгы билгеле булса дә, ул китапның нөсхәләре хәзерге заманда табылмый. Хәтта үзебезнең гасырыбызда Аруфи[65] дәүләтләре махсус игъланнар бастырып, зур игътибар белән, төрле ислам мәмләкәтләреннән ул китапны һәм Ибне Фазланның рисаләсен эзләсәләр дә, һичбер җирдә барлыгы мәгълүм булмады.

Әбү Хәмид әл-Әндәлеси 529(1134) елда шәһре Болгарга килгәч, «Болгар тарихы» иясе белән күрешеп, аннан күп сүзләр күчереп сөйли.

Зәкәрия бине Мөхәммәд әл-Казвини, ул Әбел-Мәгали Габделмалик бине Габдулла әл-Җәвәйнинең юлдашыннан иде, ди. Бу шәхес 559(1163) елда вафат була.

Болгар галимнәренең берсе Әбел-Галя Хәмид бине Идриси әл-Болгаридыр. Бу шәхес 500(1106) елларда исән була. «Зөһрәтер-рияз» китабын язучы Сөләйман бине Давыд әс-Сәкъсини үзенең китабын алтмыш җиде бүлектән ясап, «Зөһрәтер-рияз вә нөзһәтел-колүб әл-мираз»[66] исеме белән исемләп, һәр бүлекнең башында бу затка бәйләп бер хәдис сөйләп нәсыйхәт бирә. Беренче бүлек башында китерелгән сүзе түбәндәгечә башланып китә: «Остазыбыз Әбел-Галя Хәмид бине Идрис казый әл-Болгари... Габдулла бине Мәсгудьдән күчереп сөйләүче Хисаметдин Әбел-Мөгыйнь Мәймүн бине Мөхәммәд бине Мөгътәмидел-Мәкхулиән-Нәсәфи сүзләрен китерә». Унынчы бүлек башында: «Имамнар шәехе Хәмид бине Идрис Ибне Гомәрдән күчереп сөйләүче Әбү Бәкер Мөхәммәд бине Габдулла әс-Сәрхәкти сүзләрен безгә сөйләде», — диелә. Уникенче бүлек башында: «Имамнар шәехе, остаз Әбел-Галя Хәмид бине Идрис Әсбаг бине Бәнанәттән күчереп сөйләүче Әбү Ибраһим Исмәгыйль бине Мөхәммәд бине әл-Хәсән әл-Хөсәени сөйләгән сүзләрне сөйләде», — дип языла. Егерме икенче бүлектә: «Имамнар шәехе, остаз Хәмид бине Идрис Габдеррахман бине Гауфтан күчереп сөйләүче казый Гыймадетдин Әбүбәкер Мөхәммәд бине әл-Хәсән бине Мансурән-Нәсәфи сүзләрен сөйләде», — диелә. Кырык дүртенче бүлектә: «Имамнар шәехе, остаз Хәмид бине Идрис Әбүзәрдән күчереп сөйләүче Әбүбәкер Мөхәммәд бине Гомәр әл-Базар сөйләгән сүзләрне сөйләде»,— диелә. Илле алтынчы бүлектә: «Имамнар шәехе, остаз Хәмид бине Идрис Җобир бине Габдулладан күчереп сөйләүче Әбүбәкер Мөхәммәд бине Гали бине әл-Фазыл әл-Бүздигари сүзләрен безгә сөйләде», — диелә.

Тәрҗемәче фәкыйрь болай ди: «Әбел-Мөгыйнь ән-Нәсәфи 508(1114) елда — Нәсәфтә, Әбүбәкер Мә-хәммәд бине Хәсән бине Мансур ән-Нәсәфи әл-Гавидни 505(1111) елда — Бохарада, Әбүбәкер Мөхәммәд бине Габдулла бине Сәрхәкти 518(1124) елда вафатлар. Әбү Ибраһим Исмәгыйль бине Мөхәммәд бине әл-Хәсән әл-Хөсәени Әбел-Ясир әл-Бәздәви һәм Әбел-Мөгыйнь ән-Нәсәфи белән яшьтәш иде. Аның турында Әхмәд бине Мөхәммәд әл-Хөкми, Әбүбәкер Мөхәммәд бине Гомәр әл-Базар, Әбүбәкер Мөхәммәд бине Гали бине әл-Фазыл ән-Нисабури әл-Бүздигари яздылар. Аларның һәркайсы 500(1106) елның азагында вафат булды, Бүздигар — Хорасанда Нисабур авылларыннан танылган һәм мәшһүр авыл.

Хуҗа Әхмәд әл-Быргыри «Салават мәсгуди» китабында: «Хуҗа Әхмәд Быргыри» дип язылган, әмма башка урыннарда: «әш-Шәйхе Әхмәд әл-Болгари солтан Мәхмүд бине Сәбәктәкин әл-Газнәвинең остазы һәм шәехе», — дип телгә алына.

Галяэддин Габделгазиз бине Әхмәд әл-Маймыргый «Ысуле Фәхрелислам» шәрхе «Кәшфе кәбир» һәм «Ысулел-хосами» шәрхе «Тәхкыйк»дә күп урыннарда аның исемен, фамилиясен, чыгышын һәм нәсел-нәсәпләрен искә алмыйча, кайберләрендә: «Имамнар шәехе әл-Быргыри әйтте», кайберләрендә: «Имам әл-Быргыри әйтте», кайбер урыннарда: «Быргырия юлы», кайберләрендә: «Имам әл-Быргыри сүзе», — дип кенә телгә ала...

Гомумән, бу кеше — галим, шәригать кануннарын яхшы белүче, зур дәрәҗәгә лаеклы кеше һәм уп Шәмсел-оммәти-әс-Сәрхыси, Фәхрелислам-әл-Бәздәви, Шәйхелислам Хаваһирзадә тасырдашлары һәм шулар кебек кеше.

«Быргыр» дигән сүзнең «шәһре Болгар» булуы Мәсгуди, Якут өл-Хәмәви һәм башкалар китабында әйтелгән,

«Шәех Әхмәд» — ул бер генә кешеме яки берничәме — тәгаен мәгълүм булмады. «Тарикаи Быргырия»нең тәмамланган нөсхәләрен күргәнебез, ул китапка ия була алганыбыз юк. Шулай ук бу шәхеснең дә тәрҗемәи хәлен хәзергәчә һичбер тарих китапларында тапканыбыз юк.

Янә Әш-шәйхе Борһанетдин Ибраһим бине Хозыр әл-Болгари әл-Хәнәфи «Ысулел-хосами» исемле китабын язып тәмам иткән. Китап азагында: «Бу китап 751(1350) елда, рәбигыль-әүвәл аеның өченче көнендә тен вакытында Ибраһим бине Хозыр әл-Болгари кулы белән язылып тәмам булды», — дил язылан. Китабының нөсхәсе төзек һәм ачык, язуы дөрес, белеме ташып тора. Димәшкъ һәм Сүриянең башка шәһәрләрендә булган хатларга [язу стиленә] охшаш. Тәрҗемәче фәкыйрь кулында заманның җитешмәгән әйбере [дефицит] исәбеннән санала.

Янә Әш-шәйхе Мөхәммәд Садыр бине Галяэддин әл-Болгари рәхмәтуллаһи. Аның фикердәшләреннән Таҗетдин Ибраһим бине Мөхәммәд исемле кеше «Ысуле имам Фәхрелислам» китабын язып, ахырында: «Бу китап 765(1363) елда җөмадиел-әүвәл аеның унынчы көнендә Ибраһим Шәех бине Мөхәммәд хуҗа бине Таҗетдин әл-Кыртимәни кулы белән язылып тәмам булды»,— дип куя. «Кыртымәни» яки «Кырйы-мәни» исемендә Казан өязендәге бер авыл булыр...

Янә Әш-шәйхел-имам Хуҗа Хәсән бине Гомәр әл-Болгари. Күп шәехләрдә укыса да, шәех Сәгьдетдин әл-Хәмәви мөриде булганлыгы билгеле. Икенче бер сүзгә караганда, бу галим тумышы белән Азәрбайҗан мәмләкәтенең Гәнҗә шәһәреннән булса да, Болгар шәһәрендә күп заман яшәгәнлеге сәбәпле «Болгари» дип мәшһүр булган. Халык телендә йөргән кайбер сүзләргә караганда, Болгар шәһәрендә яшәгән вакытында кайбер дошманнарының яла ягулары сәбәпле манарадан ташлап үтерелергә хөкем ителгән булса да, качып китеп котылган.

Бохара шәһәре эчендә, Хәлләбакан мәхәлләсендә бер изгеләр кабере бар. Ул Хуҗа Болгари кабере дип йөртелә. Йола буенча кабере өстенә барып табыналар. Халкы шәһре Болгарга ихтирам йөзеннән бу каберне «Хуҗа Болгари» дип атый. 1270 (1853) елда вафат булган, «әс-Сагати» исеме белән танылган мелла Хөсәен бине әл-Мөхәммәд бине Гомәр әл-Болгари әл-Каргалы үзенең васыяте буенча

шуның янына күмелгән, Хәсән һәм Хөсәен әл-Болга-рилар да шунда күмелгән. Садыреш-Шәригать Гобәйдулла бине Мәсгуд бине Тажеш-Шәригать әл-Кирмәни Бохарада шәех Хәсән әл-Болгари белән очрашкан һәм аңа ияреп дөрес юлга күнгән. 699(1299) елда Тибриз шәһәрендә вафат булганлыгы билгеле.

Янә Әш-шәйхе Борһанетдин Ибраһим бине Йосыф әл-Болгари, «Кешфез-зөнун» китабында «Шәрхе әда-бес-сәхаиф»[67]не бу кеше язган дип телгә алына. Тагын «Фосул ән-Нәсәфи фи гыйльмил-җәдәл» [ән-Нәсәфинең диалектика фәнендә казанышы] китабына Борханетдин әл-Болгари шәрех [аңлатма] яза. Икесе бер үк кешеме, әллә икесе ике кешеме — мәгълүм булмады.

Янә Әш-шәйхе Касыйм бине Ибраһим әл-Казани. «Касыйм шәех Газизан» дип танылган. Вәли Газизан әл-Кәүһәзирнең мөрите иде. 998(1590) елда Бохара белән Сәмәркand арасында Кәрминәдә вафат булган. «Тәварихы Болгария» иясе Хисаметдин бине Шәрәфетдин әл-Мөслиминең сүзенә караганда, шәех Касыйм бине Ибраһим — Яңа Казан кешесе, вафаты да шунда ук. Чаллы авылыннан чыккан хәлфә Юныс бине Зөлмехәммәд мөриде[68] булмыш. Атасының исеме Ибраһим булган. Казан халкы телендә аның чыгышы да Казаннан дип әйтелә. Хәтта кайберәүләр ул Казанда күмелгән дип тә сөйлиләр. Мавәраэннәһердә Миянкялат һәм аннан башка өлкәләр халкы телендә дә Казаннан чыккан диләр. Үзләре белепме, әллә Коръән әһелләреннән ишетеп әйтәләрме — алла белә. Кабере анда, билгеле. Хәзер дә истәлекле, зиярәт кыла торган урын булып тора. Хәзерге вакытта да Казанда беренче мәчет мәхәлләсендә бер йортны «Касыйм шәех йорты» дип, якыннарын да «Касыйм шәехләр» дип йөртәләр. Халык нәзер, садаканы, тавык, күркә, каз кебек нәрсәләрне «Касыйм шәехкә» дип китерә...

Янә Әш-шәйхе Минһаҗетдин Ибраһим бине Сөләйман әс-Сараи. Аның остазы Рәшид-әд-Дин Исмәгыйль бине Мәхмүд бине Мөхәммәд әл-Кәрдари «Фаваидел-мәсаилез-зарурия» дигән китап язган. Үзе «Мәфатихел-әкфал» исемле китап язып, Харәземдә 771(1369) елда тәмамлаган.

Янә Әш-шәйхе әл-Вагыйзь ән-Насыйх Әхмәд бине Шәмселөммәт әс-Сараи. Ибне Гарәбшаһ аның турында: «Гарәп, фарсы, төрки телләрнең патшасы, заманның гаҗәеп кешесе иде», — ди торган иде. Бу галимне Аксак Тимер Сәмәркандка чакыртып алган.

Янә әл-галлямәте Сәгьдетдин Мәсгудь бине Гомәр әл-Хорасани ән-Нәсаи әш-Шафигый. «Тәфтәзани» дип мәшһүр булган галим. «Шәрехел-гакаид» һәм башка бик күп китапларның авторы. «Тәлвих галят-тәузыйх» китабын 753(1352) елда Гөлстан шәһәрендә язган. «Шөрехет-тәлхыйс» китабын сарай патшасы Җанмбәк ханга бүләк иткән... Сәмәркандта Тимер хозурында очраклы рәвештә үлеп калган. Җеназасы Сәрхәскә күчерелгән һәм анда шәех Әбел-Фазыл әс-Сәрхәси янында күмелгән...

Янә Әш-шәйхе Хафизетдин Мөхәммәд бине Шиһаб бине Йосыф әл-Харәзми әл-Кәрдәри. Исеме «Ибне әл-Бәззаз» дип мәшһүр булган. Яше сиксәннән үтеп, 827(1423) елда рамазан аенда вафат булган. Башлангыч белемне үз илендә алганнан соң, Болгар, Кырым һәм Рум мәмләкәтләрендә булып, аларның галимнәре, бөек кешеләре белән аралашып, алардан; күп гыйлем алган. Күп заман Болгар шәһәрендә, Хаҗитарханда һәм Кырым шәһәрләрендә торган. Татар патшалары, Җуҗи хан балалары алдында кадер-хөрмәттә һәм бик югары

дәрәҗәдә булган. Хәнәфи, мәзһәбенең* төп кагыйдәләрен туплаган һәм «Бәз-зазия фәтвасы» («Фәтавә Бәззазия») дип исемләнгән китабы билгеле. Хәл-әхвален [аңлатып] Сираҗетдин Әхмәд бине Фазыл әл-Хаҗитарханига язган рөхсәт кәгазен «Вафийятел-әслаф...»та искә алдык. Ул Аксак Тимерне «кяфер» дип фәтва биргән галимнәрдән...

Янә Госам бине Әлмәлик әл-Мәргыйнани. Дөрес юлга күндерүче. Тимер гасырында атасы белән бертуганның углы Габделәүвәл бине Гали белән икесе мәмләкәтнең олыларыннан саналганнар. Үзе галим Һәм шагыйрь булган. Хафизетдин бине әл-Бәззаз белән уртак гыйльми эшләре һәм сүзләре дә булган. Аксак Тимер фетнәсе соңында, Болгар илендә һәм Бәррийятел Бәрәкәттә булган чуалыш, фетнә һәм көнчелек** нәтиҗәсендә, хаҗ сәфәреннән кайту юлында күп төрле мәшәкатьләр күреп, 814(1411) елда Хаҗитархан шәһәрендә вафат булган...

Янә зур дәрәҗәле галим Шиһабетдин Әхмәд бине Мөхәммәд бине Габдулла әл-Карши әд-Димәшкый. «Ибне Гарәбшаһ» исеме белән мәшһүр. 791 (1388) елда Сүриядә Димәшкъ шәһәрендә туып, 854 (1451) елда вафат булган. Ул — галим, әдип һәм шагыйрь, халыкның көнкүрешеннән, дөнья тарихыннан, үткән заман хәлләреннән дә хәбәрдар булган. Болгар илендә, Гыйракта, Хорзсанда, Румда, Мавәраэннәһердә, Магул һәм Төрек илендә, Харәземдә сәяхәт итеп, күп нәрсә күргән. Күргәннәреннән күп тәҗ. рибә алып, күп китап язган. Бәрийятел Бәрәкәттә (Алтын Урда) озак яшәгән. Углы Таҗетдин Әбел-Фазыл Габделваһһаб 813(1410) елда Хаҗитарханда туа. Ул да галим кешеләрдән була һәр икесе сөнниләр, дән*. «Вафийятел-әслаф...»та һәр икесенең озын тәрҗемәи хәлләре бар.

Ибне Гарәбшаһ «Гараибел-мәкъдур фи навадири Тимур» исемле китабында әйтә: «Дәштнең башкаласы — Сарай шәһәре. Ул — мөселман шәһәре, биналары төзек булган ил. Бәрәкәт солтан мөселман булгач, шушы шәһәрне бина итте һәм аны башкала итеп билгеләде, аны төзек, пакь итте. Дәшттә яшәүчеләрем не ислам кабул иттерергә өлгерде. Шуңа күрә, һәр изгелек һәм бәрәкәтнең урыны булган кебек, бу шәһәр «кыпчак» сүзенә өстәлеп йөртелгән шикелле «Бәрәкәт» сүзенә дә өстәлеп йөртелде».

Ибне Гарәбшаһ тагын болай дип дәвам итә: «Бәрәкәт хан ислам кабул итеп, Хәнәфиләр мәзһәбен алгач, халкына дин өйрәтү һәм бер аллага ышану юлларын төшендерү өчен, төрле яклардан галимнәр һәм шәехләр чакыра. Моның өчен ул зур юмартлык күрсәтә, килүчеләргә бүләк диңгезләре яудыра, гыйлем һәм галимнәрнең хөрмәтен күтәрә, аллаһе тәгаләнең һәм пәйгамбәрнең байрагын олылый. Шуңа күрә ул яшәгән заманда, ягъни Үзбәк хан, Җанибәк хан заманнарында һәм алардан соң, остазыбыз Котбетдин, галимнәрнең галиме әр-Рази, әш-Шәйхе Сәгъдетдин әт-Тәфтазани, әс-Сәеде Җәләлетдин, «Хаҗбия» китабына шәрех язучы һәм башка хәнәфи һәм шәфигыйләрдән** олы кешеләр күп була. Алардан соң — остазыбыз Хафизетдин әл-Бәззаз һәм остазыбыз Әхмәд әл-Җөнди. Шушы өлкәннәр арасында Сарай шәһәре гыйлем урыны һәм бәхет чыганагы булып әверелә. Анда галимнәр, олылар, әдипләр, изгеләр, яхшылар җыела. Мондый олылык ияләре шундый аз вакыт эчендә башка һичбер урында бу кадәр күп булмый.

Болар чыгышлары ягыннан Болгар кешеләре буямасалар да, Болгарга килгәннәр һәм анда озак торганнар».

Янә Әш-шәйхе Мөхәммәд әл-Болгари. Вәгазь һәм нәсыйхәт бабында «Хәзинәтел-голямәэ вә зиннәтел-фөкаһаэ» исемле кысиа бер китап язган.

Янә Әхмәд бине Габдулла әл-Кырыми. Габделәүвәл бине Гали әл-Фиргани, Хафизетдин бине әл-Баз-заз һәм Шәрәфетдин бине Кәмалетдин әл-Кырыми аның шәкертләреннән була. «Әхе Чәләпи» дип танылган Йосыф бине Җөнәед әт-Тукатый да — аның шәкерте.

## Болгар патшалары турындагы фасыл

Хисаметдиннең[69] тарихын* игътибарга алганда, борынгы Болгар патшаларыннан безгә билгеле булганнарының беренчесе Тукый хан, аннан соң аның углы Айдар хан булып, аның гасырында сәхабәләр** килеп, аның авыру кызын дәвалап сәламәтләндерәләр, шуның өчен хан һәм Болгар халкы мөселманлыкны кабул итә. Ләкин мин бу хәбәрнең дөреслегенә һич тә ышана алмыйм.

Моннан соң Зөбәер хан була. «Бу хан күп гаскәр белән барып, Кастантиния кайсарын һәм аның халкын зур куркуга төшерде», — диелгән. Бу хәл исламнан элек булмаска кирәк.

Аннан соң — Силки хан. Ул — башлап мөселман булып, Багдадка илчеләр җибәреп, исламга керүен хәлифәгә мәгълүм иткән Алмас ханның атасы. Алмас хан үзенә Җәгъфәр дип, атасына Габдулла дип исем биргән була.

Аннан соң — аның углы әмир Җәгъфәр. Моның гасырында Болгар шәһәренә Багдадтан Сәһсән әр-Рәсиби, Бәдәр әл-Хәрәми һәм Әхмәд бине Фазлан исемле илчеләр җитәкчелегендә дин өйрәтү өчен галимнәр, төзелеш һәм башка эшләр өчен оста белгечләр килә. 332(943) елда әле әмир Җәгъфәрнең сәламәт булуы, Кастантиния һәм шул тарафтагы башка мәмләкәтләргә һөҗүм итүе Әбел-Хәсән әл-Мәсгуди китабында ачык итеп әйтелгән.

Аннан соң — аның углы әмир Әхмәд. Бу шәхес Мокътәдир биллаһ хәлифәлеге вакытында Багдад аркылы хаҗга барып, хәлифәлек диварыннан аңа күп маллар, хайваннар, киемнәр, байраклар, музыка кораллары бүләк итеп бирелгән.

Аннан соң — аның углы әмир Талиб. 338(949) елда бу шәхес исемендә шәһре Болгарда сугылган тәңкәләр бар.

Аннан соң — аның углы әмир Мөэмин. Бу кеше патшалык иткән вакытта, ягъни 358(969) елда Россия хөкемдары Владимир кыпчак төрекләренең ярдәме белән Болгар иленә һөҗүм итеп, аны талый, җимерә, халкын үтерә һәм әсир итеп ала. Болгарларга салым салырга теләгәндә, рус гаскәрләре башлыгы үзенең хөкемдарына: «Боларның аяклары итекле, болардан без салым ала алмабыз, без чабаталылар өстенә барыйк, безгә шулай кулай булыр»* дип әйткәнлеге риваять ителә, ягъни алар [болгарлар] мәгърифәтле, мәдәниятле халык булган. Шәһре Болгарда 366(977) елда бу кеше исемендә сугылган тәңкәләр бар, ул Габбаси хәлифәләреннән әт-Таигы биллаһ Әбү Бәкер Габделкәрим бине әл-Мотыйгның замандашы булган.

Аннан соң — әмир Шәмгун. Бу кеше Дунай болгарларыннан булса кирәк.

Аннан соң — әмир Хәйдәр. Аннан соң — аның углы әмир Мөхәммәд, Аннан соң — аның углы әмир Сәгыйдь. Аннан соң — әмир Баражҗ. Аннан соң — әмир Ибраһим. 560(1164) һиҗридә бу кеше әле исән була. Болгар мәмләкәтендәге мәшһүр Ибраһим шәһәре бу кеше исеме белән бәйләнгән түгел микән? Аннан соң — аның углы әмир Сәлим. Габбасия хәлифәләреннәнән-Насыйре ли-динуллаһи Әбел-Габбас Әхмәд бине әл-Мөстәзаэнең замандашы була. Болгарда сугылган акчалар арасында «ән-Насыйре ли-динуллаһи әмирел-мөэминин» дип язылган тәңкәләр бар. Үзебез дә берничә данәсен таптык. Ләкин соңгырак заманда сугылган.

Аннан соң — аның углы әмир Илһам. Бу патшалык иткән заманда, 620(1223) елның ахырында, татарлар шәһре Болгарга килеп, болгарлардан җиңелеп, исән калганнары Талкан шәһәрендәге патшалары — Чыңгыз хан алдына кайтып китә. Шуннан соң юллар ачылып, кәрваннар йөреп, сәүдәләр була башлый. Җуҗи хан үзенең атасы Чыңгыз ханнан алты ай элек вафат була. Чыңгыз хан мәрхүмнең өлешен аның икенче углы Бату бине Җуҗи ханга биреп, аңарга «Саин»[70] дигән кушамат куша. Бату хан бабасы Чыңгыз хан яныннан китә. 633(1235) елның ахырында икенче мәртәбә Болгарга һөҗүм итәргә уйлап, Субутай дигән кешене гаскәр башлыгы итә. Бу сугышта Субутай гаскәре җиңә, ә болгарлар җиңеләләр, Болгар әмире татарларга салым түләргә риза булып, алар хөкүмәтенә буйсынып, урынында калдырыла.

Соңыннан — әмир Фулад Тимер, моның гасырында, 762(1360) елда, болгарлар Нижний шәһәренә баралар.

Аннан соң — әмир Габдулла. Аннан соң — әмир Хәсән. 770(1368), 776(1374) һәм 778(1376) елларда Болгарда моның исемендә сугылган тәңкәләр бар. Казанда Кабан күле башындагы, әскаф йортының капкасы алдындагы зур таш бу кешенең каберенә куелган таш түгел микән? Безнең фикеребезчә, ул чыгышы белән татар ханнарыннан булмаска кирәк, чөнки алар мөстәкыйль патшага «хан» урынына «солтан» димәгәннәр. «Солтан» исемен шаһзадәләренә биргәннәр. Ул ташта: «Әмир вә солтан вә зыйльлуллаһе лил-галәмәен», — дип язылган. «Зыйльлуллаһе лил-галәмәен» дигән сүзләр һәм аннан башка билгеләр дә аның мөстәкыйль патша булганлыгын күрсәтәләр, һәм бу исем белән генә канәгатьләнеп, «хан» исеме телгә алынмау аның татар ханнары җөмләсеннән булмаганлыгын күрсәтә.

Моннан соң — аның кардәше әмир Мәхмүд. Аннан соң — әмир Габдулла. Халык телендә: «Аны Аксак Тимер үтерде, аның Алтынбик исемле тугыз яшьлек, Галимбик исемле җиде яшьлек ике углы калды. Тимер Болгарны ватты, җимерде, халкын таратты», — дип сөйлиләр. Ләкин бу сүз дөрес түгел, чөнки Тимер Туктамыш хан белән 793(1391) елда сугышкай* һәм 807(1495) елда Кытай сәфәрендә «Утрар» дигән җирдә вафат булган. «Утрар» сүзе аның вафаты тарихына кереп калган. Бу вакыйгадан соң, ягъни 830 (1426) еллар үтеп киткәч, шәһре Болгарда татар ханнары исемнәренә сугылган тәңкәләр күп.

Шәһре Болгарның кайсы заманда Россия кулына керүе, кайчан һәм нинди сәбәпләр белән җимерелүе мәгълүм түгел. Язмыш аркасындамы, берәр дошманлык сәбәплеме — һичберсе ачык түгел. «Тимер харап кылды», — дигән сүз дөрес булган очракта да, аның аркасында бөтенләе белән җимерелеп,

ташландык булып калуы турында уйлау кирәк түгел. «Руслар әмир Мөэмин заманында харап кылды», — дигән сүз дә ышанычлы түгел**. Аннан башка тагын: «Болгарны 677(1278) елда татар патшаларыннан Мәнгу Тимер хан харап кылды», — дигән сүзләр дә бар, ләкин һичкайсында тәмам җимерелгәнлеге турында хәбәр юк. Татар җәмәгатьчелеге телендә «Болгарны Канаш[71] исемле әскаф харап итте — җимерде», — дигән сүз дә йөри. Бу сүзнең дөреслеге шул: үзенең тәгассебе[72] сәбәпле, бәлки берничә бинаны җимерсә җимергәндер. Татар халкы авызында: «Идел күчү сәбәпле җимерелде», — дигән сүз дә бар. Хода белә: бәлки, руслар Казанны алган чакта Болгарга да хуҗа булганнардыр. Халкыбызның гаять әһәмиятле тарих гыйльме белән кызыксынмавы сәбәпле, барлык хәл яшерен булып, караңгылыкта калган. Хәтта хәзерге гасырыбызга кадәр сакланып калган ике манарасының зурысы егылгач, шуның кайсы елда җимерелеп төшкәнен эзләп, сорап, байтак вакыт үткәннән соң гына, бу мәгълүматлар Спасе өязе Олы Чаллы авылының мәрхүм Фазлулла бине Бохаранның язма җыентыгыннан табып алынды. Ул: «1260(1844) һиҗридә сишәмбе көн кичәсендә, рамазан аеның 19ында, ярты төндә җимерелде», — дип яза.

Мәрхүм Ибраһим әфәнде 1235(1819) елда җәй көне шәүвәл аенда шәһре Болгарга барган. Ул вакытта әле манара үз урынында утыра торган булган. Шул кеше үзенең җыентыгында: «Ул манарага җитмеш өч баскыч белән мендек», — ди.

Мәрхүм мелла Габделваһһаб бине Имамколын әр-Рәҗәби дә шулай ук хикәя кылган иде. Бу шәһре Болгарның мәчете һәм манарасы борынгы төзелешләр икәне ачык, бәлки, Багдадтан килгән илчеләр җитәкчелегендә булган осталар ярдәме белән салынган булганнардыр.

Бер фарсыча китапта: «Болгар шәһәре — Мартыс диңгезе буена утырган бик зур шәһәр, аларның бинալары нарат, чыршы шикелле агачтан эшләнгән, шәһәрнең ихатасы да агачтан эшләнгән, аларда бик салкын», — дип язылган.

Бер борынгы терки китапта: «Болгар шәһәре бик зур түгел, ләкин бинаалары гаять төзек, халкы зифа, матур», — дип язылган.

«Фәрһәң Мәснәвидә»: «Бик зур шәһәр, шулай ук ил исеме; бу илдә өч шәһәр бар: беренчесе — Болгар, икенчесе — Суар, өченчесе — Ислә. Болгар халкы барысы да кяферлар һәм төрекләр», — диелә.

## Искәрмәләр

[1] Ибне Дастә чыгышы буенча хәзерге Иран ягыннан. Шуңа күрә Хәзәрне «күл (ягъни кечкенә диңгез) артындагы ил» дип атый.

[2] Мәдииәтел-баб — капка шәһәре, Дәрбәнд шәһәрене икенче төрле аталышы.

[3] Шам — Сүрия.

[4] Болгә иделе — «Идел» сүзе зур суларны аңлаткан төшенчә урынында кулланылып, биредә «Болгә» — «Волга» елгасы мәгънәсендә килә.

[5] Сүзнең нинди җыентык турында барганлыгы ачык түгел.

[6] Кәрамәт — могҗиза.

[7] Табиб — дәвалаучы, доктор.

[8] Мәдинәи мөнәүвәрә — Нурлы шәһәр. Согуд Гарәбстанындагы Мәдинә шәһәре икенче төрле шулай атала.

[9] Берадәр — бертуган.

[10] «Мәгърифәтес-сәхабә» — «Танылган сәхабәләр» — китап исеме.

[11] «Нократ» — гарәп телендә «эшкәртелгән көмеш» дигән сүз.

[12] Ш. Мәрҗани. «Мөстәфадел-әхбар»ның I томы ахырында шундый сүзләрне алфавит тәртибендә китерә.

[13] Аңа — Габдеррахманга.

[14] Шәһрияр — патша, хөкемдар.

[15] Ул — Габдеррахман бине Рәбига.

[16] Тимер капка — Дәрбәнд шәһәре. Бу шәһәр гарәпләрнең Европага утеп керүләре өчен кирәкле юл өстендә торганга күрә, ул заман Риячыларының телендә күп тапкырлар искә алына.

[17] Аларны — Хәзәр төрекләрен булса кирәк.

[18] «Моннан башка да әлеге зыян (ягъни корылык һәм ачлык сәбәпле бик зур борчу-хәсрәтләр булды. Татулашу-килешү вакытында алар (ягъни Хәзәрләр) игътибарны йомшартмадылар, гаять дәрәҗәдә курыкканнар һәм бик нык котлары очкан иде. Якут». (Мәрҗани иск.)

[19] Шигырь гарәпчә, биредә сүзгә-сүз тәрҗемәсе китерелә. (Тәрҗ. иск.)

[20] Тәрҗемәче — Мәрҗани үзе.

[21] Жизья — салым.

[22] Ганимат — сугышта җиңүче як кулына тешкән мал, байлык.

[23] Җаһилият —бу урында — мәҗүсилек.

[24] Гыймарәтләр — төзелеш, биналар, ейләр.

[25] Нөхбәтед-дәһер фи гаҗаиби-бәрри вөл-бе-хер —кори җирдәге һәм диңгездәге могҗизаларда чорның бетүе (күренү).

[26] Сәхабәләрнең белемен урмандагы арыслан белән тиңләү.

[27] Асарел-биляд — илләр истәлеге.

[28] Әбү Хәмид — XII гасырда яшәгән испан-гарәп сәяхәтчесе, галим Әбү Хәмид әл-Гарнатый.

[29] Ягъни «белүче, галим» мәгънәсендә. (Мәрҗани иск.)

[30] Рисаләтел-интисаб — туганлык турында мәкалә.

[31] 9нчы гасырның беренче яртысында.

[32] Җөрҗания — хәзерге Харәзем өлкәсенең башкаласы Үргәнеч шәһәре.

[33] Кятиб — секретарь.

[34] Багдад шәһәре «Мәдинәтес-сәлам» дип йөртелгән.

[35] Дибаҗ — ефәктән тукылган пәрдә, җәймә.

[36] Кәбаб — кыздырылган ит.

[37] Я хода, патшаны, Болгар патшасы Белекварны, изгелеккә юнәлдер.

[38] Я хода, үзеңнең колың һәм хәлифәң, әмирел-мөэминин әл-Мокъәдир биллаһны изгелеккә юнәлдер.

[39] Ягъни мөселман түгел иде.

[40] Я хода, Болгар әмире, колың Җәгъфәр бине Габдулланы һәм хуҗасы әмирел-мөэмининне изге юлга күндер.

[41] Гаҗаибләр — гаҗәп нәрсәләр.

[42] Мөрәббәгъ — квадрат.

[43] Мәрҗани үзе.

[44] Мөтәрҗим — тәрҗемәче. Бу очракта Мәрҗани үзе.

[45] Әбел-Хәсән бине әл-Хөсәен бине Гали... — пәйгамбәрнең өлкән сәхабәләреннән Габдулла бине Мәсгудь балаларының [берсе], [ул] Багдад галимнәреннән [санала]. [Мәрҗани иск.]

[46] Галәмнәр — байраклар, әләмнәр,

[47] Сәриияләр — отрядлар.

[48] Бәхре Рум — Кара диңгез.

[49] Бу дәвердәге сугышларда гади сугышчыларга караганда күп көчле булган аерым батырлар бик кадерле булганнар, алар турында төрле хикәяләр сөйләнгән. Мәсгудинең бу сүзләрендә дә шул хәл чагыла булса кирәк.

[50] М.И. Артомонов бу турыда: «һәр көймәдә 200 кеше булган», — ди дә: «Монда Мәсгуди санны артык күбәйтеп күрсәткән, елъязмалардан күренүенчә, рус көймәләре ул чакта 40 кеше утырта торган булганнар. Шулай итеп, барлыгы 20000 кеше була. Шундый төзәтмә белән Мәсгудинең санын кабул итәргә мөмкин», — ди. М.И. Артомонов. «История Хазар», примечание к стр. 371. Ленинград, 1962.

[51] Хәзерге китапларда: Җәел — Гилан, Табстан — Табаристан, Әбскүн — Азәрбайҗан, Җөрҗан — Ширван — Каспий диңгезе буендагы өлкәләр, дип күрсәтелә.

[52] М.И. Артомонов «История хазар» исемле китабында бу вакыйганы рус дәүләте түгел, бәлки аңа буйсынмаган ярым сәүдәгәр, ярым талаучылар төркеме оештырганлыгын яза. Ул дәвердә мондый төркемнәр төрле илләрдә күп булганнар.

[53] Мөрәүвиҗаз-зәһәб — алтын өләшүче.

[54] Мантыш, Мантыс, Нитыш — барысы да Кара диңгезнең элекке исемнәре. «Камусел-әгълам», I-II т.

[55] Техфәтел-әлбаб — акыл бүләге.

[56] Беҗтәк— баҗанак, печенег.

[57] Башҗырд — башкорт.

[58] Бү сүз «әл-бортәси» дип басылган. Төрки телдә «бортас» сүзе «әсир», «кол» мәгънәсендә йөргән. Шуңа күрә бу сүз «әсир» дип тәрҗемә ителә.

[59] Шигырь гарәпчә, биредә сүзгә-сүз тәрҗемәсе бирелә. (Тәрҗ, иск.)

[60] Мәҗмәгыль-әнсаб — туганлык җыентыгы (шәҗәрә).

[61] «Раузатес-сафа» — ссфлыч бакчасы.

[62] Гошер — малның уннан берен салым итеп алу.

[63] Болгар-хөкемдары Карабат — Сүз VII йөздә Азов Диңгезе, Дон, Кубань һәм Дунай елгалары буенда яшәгән болгарларның хөкемдары — Кубрат хан турында бара.

[64] Силсилә — нәсел-нәсәп бәйләнеше, династия.

[65] Аруфи — Европа.

[66] Авыруларның йөрәкләрен дәвалаучы чәчәкләр бакчасы.

[67] Шәрхе әдабес-сәхаиф — язылган битләрне әдәби аңлатып бирү.

[68] Мөрид — иярчен, фикерен, эшен дәвам иттерүче.
[69] «Тәварихы Болгария» кигабын язучы Хисаметдин Мөслими.
[70] Саин — сайланып алынган, хөрмәтле. Бату ханның кушаматы.
[71] Канаш — 1740-1755 елларда епископ булып торган Лука Канашевич турында сүз бара.
[72] Тәгассеб — фанатазим.

## «МӨСТӘФАДЕЛ-ӘХБАР...»НЫҢ ИКЕНЧЕ ТОМЫНДА ТЕЛГӘ АЛЫНГАН МӘДРӘСӘЛӘР ИСЕМЛЕГЕ

Адай авылы мәдрәсәсе.
Арбаш авылы мәдрәсәсе.
Ашыт авылы мәдрәсәсе.
Байморад авылы мәдрәсәсе.
Бай Оланнары авылы мәдрәсәсе.
Бизнә авылы мәдрәсәсе.
Бик авылы мәдрәсәсе.
Бирәзә авылы мәдрәсәсе.
Болгар җирендәге башка мәдрәсәләр.
Борындык авылы мәдрәсәсе.
Бохара шәһәре мәдрәсәсе.
Бохарадагы кечкенә «Җуйбар» мәдрәсәсе.
Бохарадагы «Миргарәб» мәдрәсәсе.
Бохарадагы Фәтхулла Кушбиги мәдрәсәсе.
Буби Нигъмәтулла мәдрәсәсе.
Бәләбай өязенең Корыч авылы мәдрәсәсе.
Бәрәскә авылының мелла Бәшир мәдрәсәсе.
Бөгелмә еязенең Минзәлә башы авылы мәдрәсәсе.
Вятка өязенең Янгыл иле авылы мәдрәсәсе.
Галич төбәгендә Олы Җәке авылы мәдрәсәсе.
Иске Кенәр авылы мәдрәсәсе.
Иске Чокалы авылы мәдрәсәсе.
Кабул шәһәре мәдрәсәсе.
Казакълар авылы мәдрәсәсе,
Казан артындагы Кили авылы мәдрәсәсе.
Казан төбәге, Мамадыш өязенең Симет авылы мәдрәсәсе
Казан өязенең Кариле авылы мәдрәсәсе.
Казанда беренче мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда икенче мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе,
Казанда дүртенче мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда бишенче мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда алтынчы мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда җиденче мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда сигезенче мәчет мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда күл башы мәдрәсәсе.

Казанда күл буе мәдрәсәсе.
Казаңда мелла Әбүбәкер бине Йосыф мәдрәсәсе.
Казаңда «Таҗик ермагы» мәчете мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Казанда «Җиһанша мәчете» мәхәлләсе мәдрәсәсе.
Көзиле авылы мәдрәсәсе.
Каргалы авылы мәдрәсәсе.
Кариле авылы мәдрәсәсе.
Кече Сөн авылы мәдрәсәсе,
Кизләү авылы мәдрәсәсе.
Коллар авылы мәдрәсәсе.
Курса авылы мәдрәсәсе.
Кушлавыч авылы мәдрәсәсе.
Кызылъяр шәһәре мәдрәсәсе.
Кышкар авылы мәдрәсәсе.
Кәче авылы мәдрәсәсе.
Күшәр авылы мәдрәсәсе.
Күәм авылы мәдрәсәсе.
Мазар башы авылы мәдрәсәсе.
Минзәлә төбәгендә Симак авылы мәдрәсәсе.
Мәмсә авылы мәдрәсәсе.
Мәчкәрә авылы мәдрәсәсе.
Мәңгәр авылы мәдрәсәсе.
Наласа авылы мәдрәсәсе.
Олы Кавал авылы мәдрәсәсе.
Оренбург янында Кондырау авылы мәдрәсәсе.
Орнашбаш авылы мәдрәсәсе.
Оры авылы мәдрәсәсе.
Саба авылы мәдрәсәсе.
Салавыч авылы мәдрәсәсе.
Саена авылы мәдрәсәсе.
Сәмәркандта Хуҗа Әхрар мәдрәсәсе.
Сәрдә авылы мәдрәсәсе.
Сүриянең Димәшкъ шәһәре мәдрәсәсе.
Ташкичү авылы мәдрәсәсе.
Тәтеш өязенең Барыш авылы мәдрәсәсе.
Тәтеш өязенең Кайбыч авылы мәдрәсәсе.
Түнтәр авылы мәдрәсәсе.
Урбар авылы мәдрәсәсе.
Утыз Имән авылы мәдрәсәсе.
Хөснә авылы мәдрәсәсе.
Чакмак авылы мәдрәсәсе.
Чистай шәһәре мәдрәсәсе.
Шайтан елга авылы мәдрәсәсе.
Шашы авылы мәдрәсәсе.
Шырдан авылы мәдрәсәсе.

Шәриф авылы мәдрәсәсе.
Эстәрлетамак шәһәре мәдрәсәсе.
Югары Сәрдә авылы мәдрәсәсе.
Ябынчы авылы мәдрәсәсе.
Яңа Кишет авылы мәдрәсәсе.
Яңа Сала авылы мәдрәсәсе.
Яңа Тазлар авылы мәдрәсәсе.
Яңа Әлмәт авылы мәдрәсәсе.
Әгерҗе авылы мәдрәсәсе.
Әлдермеш авылы мәдрәсәсе.
Өшкәтә авылы мәдрәсәсе.

Шиһабетдин Мәрҗани, “Мөстәфәдел-әхбар Фи Әхвщли Казан вә Болгар” китабыннан (Казан һәм Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр) тәрҗемә итүче һәм төзүче Хәйруллин Ә. Н. Казан, 1989 ел.

## Бохара юлчылыгы

Ул заманнарда Казан татарларының Бохара белән алыш-бирешләре булып торган, сату, мал төягән кәрваннар һәрвакыт ике арада йөреп торганнар. Казаннан һәм башка җирләрдән Бохарага баручы шәкертләрне һәм муллаларны, Бохарадагы кешеләргә дигән амәпәтләрне шушы кәрәваннар йөртә иде. Мәрҗанинең юл йөргәне, үз авылыннан 50 чакрым булган Казанда да булганы юк иде. Ул Бохарага Мәңгәр авылының бер сәүдәгәре маллары төялгән бер дөянең сыртына утырып юлга чыгачак иде. 1838 елның 17 мае (30) көнне әтисе белән саубуллаша.

Сатучы Мохтар агайның маллары йөкләнеп бетмәгәнгә, ул көнне алар юлга чыга алмыйлар, Мәрҗани кире авылына кайтып китә. Гомерендә беренче тапкыр ерак һәм озын юлга чыгу, озакка аерылу аны дулкынландыра, шуңа күрә бер көнгә генә булса да әтисе янына кире кайтуга ул бик сөенә. Күңеле тула, кайда барып җыларга белмәгән Мәрҗани мәчеткә кереп ике рәкәгать намазы чыга һәм рәхәтләнеп бер җылап ала. Иртәгесен юлга чыгалар. Мәрҗани юлда очраган авыл, кала һәм салаларны, тау, елга, чүл һәм күл кебек үзе күргән нәрсәләрне дәфтәрләренә язып бара икән.

Юлда, Троицк каласына җиткәч, анда дүрт ай туктап торганнар. Троицкадан соң кыргыз-казакъ чүлләренә, Азиягә таба юлга чыгуның бер вакыты бар икән, каравайчылар шактый гына җыелганнан соң гына юлга чыгалар икән. Азиягә баручы кәраваннар аз булганга алар да Троицкида шулай көтеп торырга мәҗбүр булганнар. Анда Ташкичү авылыннан килеп бирегә урнашкан бер сатучыга очрап, аннан күп ярдәм күргәннәр. Анда бер фатир тотып, шушы дүрт ай буенча яшәгәннәр. Мулла, мөәзиннәр белән танышып, мәҗлесләрдә төрле белем мәсьәләләре турында сөйләшкәннәр. Курсазиның әсәрләрен укып шактый зур белем иясе булган бер мөәзин белән сөйләшеп, Курсави турында бик күп нәрсәләр ишеткән. Мөәзин Курсавины бик мактаган, бик зур бер дин белгече, галим дип аңа зур бәя биргән. Мәрҗани исә, киресенчә, Курсавины яманлаган. Әһле сөннәт вә әлҗәмәгате мәзһәбенә[2] каршы килүдә гаепләп, шәригатькә каршы килде дип, Бохара әмире Хәйдәр аны төрмәгә утыртачак булган. Курсави моннан качып кына

котылган, дип сөйләгән. Ләкин соңыннан Мәрҗани бу мөәзинне бик мактап искә төшергән. «Ул туры сөйләгән икән, мин ялгышканмын, Тәңре ул мөәзиннән разый булсын», — дип дога кылган.

Троицкида дүрт ай тору Мәрҗанинең күзләрен киңрәк ачарга һәм аның тормышы, эшчәнлеге өчен шактый зур-этәргеч булган. Аның әтисе бай кеше булмаган. Әтисе углына юл өчен һәм дә Бохарада бүлмә тотар өчен биргән акчасы дүрт ай эчендә байтак кимегән. Акчасы юл расходларына җитсә дә бүлмә тотарга калмас кебек күренә. Шунлыктан ул Троицкицан Бохарага таба юлга чыкканда кулында калган бар акчасына кечкенә тартмалар, бизәкле савытлар, вөк-төяк төрле нәрсәләр сатып ала һәм аларны юл уңаенда кайберләрең сатып, шактый гына файда итә. Шул акчалар белән Бохарада үзенә бер бүлмә (һөҗрә) сатып ала. Юлда барганда казакъ илләрен күреп күңел ачканы кебек, үзе белән алган китапларны укып та вакытын бушка уздырмый. Сәфәр вакытында Мәрҗани «Гакаиди нәфисә»[3] китабын бөтенләй яттан өйрәнгән була.

Мәрҗанинең юлдашлары — сатучылар — юлда казакъ-кыргыз илләрендә, кайбер урында берничәшәр көн, кайбер җирләрдә бер-ике атналап тукталып сату итеп баралар. Шул вакытларда Мәрҗани кайбер казакъ өйләрендә кунак булып кала икән. Бер казакъ Кунакбай Мәрҗанинең укымышлы, мулла кеше икәнен белгәч, аннан бер «Тәба-ра»[4] сүрәсен укуны үтенгән. Мәрҗани һәм Тәбарәкне, һәм дә Ясин шәрифне күңеленнән укыгач, казакъның исе киткән. Бу хәтле күп Коръән сүзләрен һич түкмичә күңелдән ятлап укып чыккан бу татар егетен: «бик мулла кеше икән», дип һәр очраган кешеләргә сөйләп йөргән: «Анави ногай Ясинны да белә, бик мулла кеше»,— дип сөйләгән.

Бу авыр һәм озын юл Троицкидан Бохарага хәтле тагын өч айга сузылган, өйләреннән чыгып китүгә жиде айдан артык сузылып, алар 1838 елның 25 декабрендә (1839 елның 7 гыйнварында) Бохарага барып җиткәннәр.

## Ш. Мәрҗани Бохарада

Бохара мәдрәсәләрендә укучылар шуларның берәрсен-дә бүлмә алып, шунда урнашып укырга тиешле булалар иде. Бу бүлмәләр вакыф (берәр кеше аны бүләк итсә) булса да, шулай сату гадәте яшәгән икән. Бу бүлмәләрнең ашау-эчү һәм башкача да файдалары булганлыктан, чит илләрдән, еraклардан килгән шәкертләр өчен шундый бер бүлмәгә ия булу бик кирәкле һәм шәкертләрнең тормышы өчен чиксез уңайлыклары булган бер нәрсә иде. Мәрҗани, акчасы аз булганга, очсызрак һәм файдасы азрак булган бер бүлмәне 150 сумга сатып алган.

Бүлмәгә урнашканнан соң Бохараның иң атаклы мәдрәсәләреннән булган һәм әтисенә дә сабак биргән олуг бер остаздан дәрес ала башлый. Бу остаз бераздан дөнья куя. Аннан соң Мәрҗани икенче остаздан дәрес ала һәм бу мөдәррисне беренчесеннән дә артык хөрмәт итә. Бу зат бик динчел кеше булганы өстенә сүзгә бик оста, акыллы һәм зирәк тә булган. Бохара әмиренең дусты да булган. Берара бу дуслык бозылу сәбәпле, бу остазга әмирнең боерыгы белән дәрес бирү тыелган була. Шундый сәбәпләр аркасында Мәрҗанигә Бохарада җиде остаздан дәрес, алырга туры килә. Боларның дүртенчесе атаклы татар белгечебез Курсавиның төшенчәләрен яклаган бер зат булып чыга. Бишенче остазы бик күп

илләрне гизгән, Һиндстанда, Гарәбстанда, Истанбулда һәм Рәчәйдә йөреп, һәр илдән күп китаплар китергән бер зат иде. Бу мөдәррис үзен бөтенләй гыйлемгә багышлаган, һич өйләнмәгән, бөтен гомерен уку һәм укытуга багышлаган олуг һәм бик кәттә кеше була.

Ш. Мәрҗани Бохарада әтисенең мәдрәсәсендә укыган дәресләрен яңабаштан укырга керешә. Ул дәрес китапларын аның шәрехләре (киңәйтелгән мәгънәләре), һашиятләре (китап бите читенә белгечләр өстәгән язулар) белән бергә укып, дәресләрне яхшы хәзерләгәнлектән, башка шәкертләрдән аерылып торганлыгын мөдәррисләр бик тиз җүргоннәр. Барча иптәшләреннән күп югары тора иде.

Белем мәсьәләләрендә бәхәсләшкәндә гел өскә чыга, җиздә торган була. Шунлыкта мөдәррисләре башка шәкерт-ләренә: «Сез сабакларыгызны Ш. Мәрҗанидән өйрәнегез», — дип киңәш бирә икән. Бер-ике елдан соң Ш. Мәрҗани Бохарада үзе мөдәррис булып, үзе дәрес бирә башлаган.

Ш. Мәрҗани Бохара мәдрәсәләрендә алган белемнәре белән генә канәгатьләнми, белемен арттыру өчен башка юллар да эзли. Бу мәдрәсәләрдә Коръән, Хәдис, Гарәп әдәбияты дәресләренең аз булуына аптырый. Бу турыда үзенең «Вафиятель-әсләф» атлы китабының кереш сүзендә болай дип яза: «Безнең татарлар уку, укыту эшләрендә, бигрәк тә мәдрәсәләрдә Бохараны күчергеч итеп алалар. Аны бик зурлап: «Бохара шәриф», — дип сөйләшәләр. Хәлбуки, Бохараның һәм халкы, һәм дә хөкүмәте бик надан, башкармалары бик бозык, уку һәм укыту эшләре бер дә юлга куелмаган, бик иске һәм бик файдасыз рәвештә йөртелә. Мәсәлән: бер «Молла җами» китапны өч ел укыйлар. Аны да баштан башлап түгел, киредән башлап башка таба — тискәре яктан укыталар. Кайбер урыннарын укымыйча калдырып та китәләләр. Бер «Шәмсия» китабын ике ел «Гакаиди нәсәфиә» китабын өч ел укыталар. Мантыйк дәресен «Тәһзип»[5] китабыннан башлап, бер «Әлхам дулил-ляһ»[6] сүзен бер ел буенча «һамд баһси»[7] дип укып вакыт уздыралар; шулай ук «Әлләзи һәдана»[8] сүзен дә «Һидаят баһси»[9] дип бер ел укып маташалар; «Фәһаза гайсте мантийкый вә әл-калам»[10] сүзен дәхи бер ел буенча «Ишарәт баһси»[11] дип укыйлар. Хәлбүки, бу бәхәсләрнең һич бересе мантыйк белән элемтәле дә түгел. Асыл «Мантыйк» белеменнән иң кирәкле булган мантыйк кагыйдәләрен укытмыйча кичеп китәләр», — дип зарлана иде. Шулай ук «Хәдис»тән «Мишкатүл мәса бик»[12] китабыннан бары беренче хәдисне генә укып узалар. «Тәфсир» — Коръәнгә мәгънә биргән китаптан «Бәйзави»[13]ның ялгыз «Әгъүзе белән бис-миллапың» һәм дә «Әлхәм» сүрәсенең мәгънәләрен бер ел укытып вакыт уздырганнан соң, шәкерт-ләргә бөтен белемнәре укып бетергән иттереп шәһадәтнамә бирәләр икән.

Бохарада Коръән, Хәдис, Ысул белеме, Хикмәт-физикә, Гарәп әдәбияты, Җәгърафия, Тарих һәм Дөнья хәлләре фәннәреннән бер нәрсәдә укытмыйлар икән. Укучысы булмаган кебек, укытучысы да юк. Тормыш өчен иң кирәкле булган бу фәннәр Бохарага күрә кирәкмәгән нәрсәләр санала имеш. Чөнки бу белемңәрне кирәксенгән бер кеше дә күренмәгән. «Фикъһе»[14] китаплары да — күбесенчә белемнәре кечкенә, үзләренә ышаныч азрак булган кешеләр ягыннан язылган китаплар гына Бохарада укытыла икән. Бу китапларда данлыклы зур мәзһәп[15] башлыкларына һәм олуг белгечләргә каршы бик зәгыйф дәлилләр белән

каршы чыгулар да бар икән. Шунлыктан Бохарада укыган дин белгечләренең шәригать буенча белемнәре бик сап булып кала, надан саналалар.

Ш. Мәрҗани Бохара мәдрәсәләренең бу кимчелекләрен андагы остазларга һәм зур урындагы белгечләргә дә язып аңлаткан булса да, аның сүзләренә зур бәя бирмәгәннәр вә һичбер үзгәреш кертмәгәннәр. Ләкин Ш. Мәрҗанинең бу тәнкыйть фикерләре бер эз һәм тиешле юл ясамаса да, безнең үз илебездә аның бу карашлары динне тирән белергә, фәнне тирәң өйрәнергә омтылучылар арасында тиешле тану тапкан, үзенә юл сала башлаган. Ят өлкәләргә укырга китүче татар шәкертләре Бохараны артык бер белем кыйбласы дип танымыйча, Истанбулга һәм Мисырга таба юнәлә башлаганнар. Ш. Мәрҗани үзенең углы Борһанетдинне дә Истанбулга җибәреп укыткан.

Ш. Мәрҗанинең Бохарада укыган вакытында анда иң зур белем учагы булып Көнгүлдаш мәдрәсәсе булган. Бу мәдрәсәнең мөдәррисе дә Бохараның иң олуг дин белгече саналып, Бохараның әмире тарафыннан билгеләнә икән. Бохарадагы кайбер китап йортларында бик әһәмиятле әсәрләр дә табыла икән. Ш. Мәрҗани Бохарада яшәгән соңгы елларында мөдәрристән һич ни сабак алмыйча, китап йортларындагы китапларны укып, сирәк очырый торган китапларны эзләп табып, шуларны уку һәм кирәкле урыннарыннан үзе әһәмиятле санаган фикерләрне үз дәфтәрләренә язып алу белән шөгыльләнгән. Яисә башка китапларда тапкан белемнәрне үзенең шәхси китапларының тиешле битләренең читләренә язып куя торган була. Мәрҗани бу китапларда очрый торган әһәмиятле мәгълүматларны үзенең китапларының читләренә гарәпчә язып куя торган була.

Ш. Мәрҗанинең Бохарадагы шәкертлек еллары ярлы-чарак булган. Кайвакытлар ялан аякка башмак киеп 3-4 чакрымдагы мәдрәсәгә укырга йөргән. Әтисе бай булмаганга акчаны күп җибәрә алмаган. Әтисе бер хатында шулай язган: «Углым, сиңа ике алтын тәңкә белән бер чикмән җибәрәм. Акчаны бик иттимат[16] тот. Чикмәнне көннәр суыткач сатарсың да акчага әйләндерерсең», — дигән. Мәрҗанигә анда булган илдәшлә-ребездән Каргалы дәмулла Хөсәен хәзрәтнең күп ярдәме тигән. Бу зат анда бер мәдрәсәдә мөдәррис булмаса да, бик зур дин белгече булган. Бу кеше Бохара әмире белән до таныш булып, үзенең бик бай бер китап йорты да бар икән. Үзенең язган әсәрләре дә булган. Мәрҗани бу затның һәм үзеннән, һәм аның китапларыннан, һәм дуслыгыннан, һәм дә белеменнән файдаланган.

Ш. Мәрҗани кышын үзе укып, җәен башкаларны укытып бераз акча таба, шул акчага торып, кышын укуын дәвам итеп килә. Шул сәбәпле Мәрҗанинең җәен үзбәк һәм төрекмәннәрдән байтак кына шәкертләре булган. Мәрҗанинең җәен авылларда укыткан шәкертләре кышын аның үзе белән бергә Бохарага да килеп, яно Мәрҗанидән сабак алалар икән. Бу шәкертләрнең әтиләренең Мәрҗанигә күп ярдәмнәре дә тигән. Бу шәкерт-ләрдән берсе турында Мәрҗани «Вафиятел-әслаф» әсәрендә дә язган. Ш. Мәрҗанидән 8 ел укыган бу шәкерт Каракүл каласыннан бер байның баласы булган. Бу байның Мәрҗанигә күп ярдәме булып, Мәрҗани Бохарада яши башлаган елларның биш елы буенча һәр җәй Каракүл каласына барган, бу байда торган һәм андагы шәкертләрне укыткан. Биш елдан соң Мәрҗани Сәмәрканд каласына китә.

## Ш. Мәрҗани Сәмаркандда

Ш. Мәрҗани Самаркандда Ширдар-Арсланлы дигән бер мәдрәсәдә урнашкан. Бу мәдрәсәнең, мөдәррисе һәм Самарканд казыйы булган Әбү Сәгыйть хәзрәтләре бу илнең иң зур дин белгечләреннән икән. Ш. Мәрҗани бу олуг белгечтән күп белем алган. Шул ук вакытта бу затның ир һәм кыз балаларын укыткан. Шуңа күрә араларында тирән бер дуслык һәм хөрмәт урын тоткан. Бу мөдәрриснең бик бай бер китап йорты бар икән. Аннан ул Мәрҗанигә укырга бик күп китап биреп торган. Мәрҗани бу китаплардан «бик күп мәгълүматларны күчереп язып алган. Бу китаплар турында Мәрҗани: «Болар минем юл күрсәткечләрем булдылар», — ди икән. «Миңа аң биргән һәм төшенчәләремне төзәткән һәм миндә яңа төшенчәләр тудырган китаплар шулар булды», — дип язган.

Бер көнне Ш. Мәрҗани Әбү Сәгыйть хәзрәтләрнең өенә барганда, аның кулында «Тәһзибүл-мантыйк вәлкаләм»[17] китабы булган. Бу китапны күргән Әбү Сәгыйть хәзрәт: «Эһ, бу китап миндә юк, әгәр син миңа бу китапны күчереп язып бирсәң, бөтен китапларымны файдаланырга сиңа рөхсәт бирәм», — дигән. Шиһап Мәрҗанинең бар хыялы шул китап йортына чуму икән. Күчереп язып бирергә бик разый булып, ул китапны ике көндә күчереп язып та биргән. Шуннан соң ул китап йортында теләгәнчә файдаланган һәм бик күп файдалы һәм әһәмиятле әсәрләр белән танышкан.

Ш. Мәрҗанинең иттикат[18] мәсьәләрендә кайбер шикле җирләре бар икән. Илдә һәм Бохарада ялгыз мөтәгаллимин»[19] белгечләренең сүзләрен өйрәнеп, кайбер нәрсәләрне күңеле белән кабул итеп бетермәгән икән. Бу китап йортында бик иске дин белгечләренең фикерләре теркәлгән китаплар табып, ул шикле итикатларны төзәткән. Мөтәккәллимин мәзһәбендә булган кайбер төпсез сүзләрнең төбен-тамырын тикшереп өйрәнгән Галләмәй Тәфтазани[20] һәм Фәхретдини Разиларның[21] кем икәнлекләрен аңлаган. Ш. Мәрҗани Сәмаркандда яшәгән вакытын иң файдалы, иң кыйммәтле заманнарым дип искәрә һәм шул турыда әсәрләрендә язып калдыра. Аңа иң күп белем биргән Кеше Әбү Сәгыйть хәзрәтләре була. Бу зат гарәпчә дин белемнәреннән башка Тарих, Дөнья белемнәре, Хисап, Җәбер, Мөкабәлә[22], Хәндисә, Һәйәт[23] һәм Җәгърәфия фәннәрен вә башка гакли[24] һәм нәкъли[25] фәннәрен белә торган кеше икән. Шуның өстенә ул күркәм холыклы, юмарт, гәпләшергә хуш, инсафлы, үзенә исе китми, башкаларга дәрәҗәсенә күрә хөрмәт күрсәтә торган олуг һәм кәттә бер гыйлем иясе була.

Бергәләп намаз кылганда бу остаз үзе имамлык итми,. Мәрҗаниие имам итеп, аның артыннан намаз кыла икән. Кайвакыт, намазның вакыты кичекмәсен дип, бакчаларда намаз кылган вакытларында, Мәсарканд казасын таныган кешеләр бу олуг затка хөрмәт белән өйләреннән намазлык китереп бирсәләр, аны Мәрҗанигә биреп, аңа имам булу тагын да лаегырак, ди икән. Бер вакыт бу зат Мәрҗанине Самарканд хакиме белән таныштырганда: «Бу егет иске заманнарның иң олуг белгечләреннән дә белеклерәк зур бер белгечтер», — дип таныткан, һәм бик мактаган.

Ш. Мәрҗанинең тарих сөюенә һәм тарих белән шөгыль-ләнүенә Әбү Сәгыйть хәзрәтләре сәбәп булган. Бу затның китап йортында тапкан әсәрләрдән,

аның үзеннән һәм бергә утырышкан чаклардагы фикерләреннән, киң мәгълүматларыннан Мәрҗани күп нәрсәләрне белгән, өйрәнгән, үзләштергән. Үз татар белгечләребездон Әбүинасыйр Курсави хәзрәтләренең күтәренке дәрәҗәсенә анннан өйрәнеп, Курсавига зур мәхәббәт тоткан. Ш. Мәрҗанигә имам Газали[26] әсәрләрендәге фикерләр бик нык тәэсир иткән, һәм бик тирән булган. Үзенең «Вафиятель-әслаф» әсәрендә ислам динен бик туры аңлаучының, зур дин белгеченең имам Газали хәзрәтләре булганын язып калдырган.

Ш. Мәрҗани кирәк үз авылында чагында, кирәк Бохарада булган вакытында, күбесенчә «Гыйлеме Каләм»[27] һәм «Мантыйк» белән шөгыльләнә, бөтен белемнәрен китаптан алган кебек тора, бу белемнәрдән алган аеры бүтән үзе чыгарган бер төшенчәсе юк иде. Ул Сәмаркандка барып, андагы китаплардан файдаланганнан соң бөтенләй башка бер кеше булып әверелде. Ул шулай итеп аерым шәхес һәм үзе ачкан төшенчәләргә ия булган олуг затка әйләнде. Укыган китапларын уз карашы нигезендә бер сөзгечтән кичереп, аңа үзенчә бер бәя бирә, аны үз карашыннан тулыландыра, киңәйтә, бәяли торган чын бер белгеч, зур белемле бер адәм булып җитешкән иде.

Татарлар арасында җитешкән иң олуг имамыбыз Әбүинасыйр Курсави хәзрәтләре турында Мәрҗани шулай яза: «Яшь вакытымда чынбарлыкны аңламыйча, башкаларга ияреп мин дә аңа каршы торган, аның төшенчәләренә көлен кенә караган идем. Соңгарыдан зур имамнарны ышанычлы, туры сүзле белгечләрнең әсәрләрен укып, үзем дә чынлап тикшереп, туры дин, чын хикмәт һәм чынбарлыкны аңлап, аның әсәрләрен табып укып акылыма килдем. Бохарага кире килгәч тә элек Ә. Курсави белән элемтәдә булган илдәшебез Дәмелла Исмәгыйль Кышкари янына барып, Курсавиның китапларын укырга теләгәнлегемне сөйләдем. Ул китапларны уку Бохарада бик каты тыелган булу сәбәпле, Дәмелла аларны миңа бик сыкранып кына бирде. Бер атна эчендә кайтарып бирүне шарт итеп куйды. «Мин бу китапларны берәр көндә укып чыгып, вакытыннан элек кайтарып бирдем. Ул китапларда иске дин белгечләренең сүз һәм иттикатларына каршы язылган бер сүз дә юк иде. Бөтен китапларында чынбарлыкның аның ягында булганын күрдем. Аның хакында начар сүзләр сөйләүчеләр иске олуг дин белгечләренең иттикатлары ничек булганын белмәгән надан муллалар гына иде». Бу сүзләрне Сөйләгән Ш. Мәрҗани Курсавины яклап бер әсәр дә язган һәм «Тәнбиһи әбнаүәлгасир битәнзиһи әнбау Әбүн-насыйр»[28] атлы рисаләне бастырып чыгарган, ди.

Ш. Мәрҗани Сәмаркандда ике ел торгач, Әбү Сәгыйть хәзрәтләрдән иҗазатнамә (үзеннән өйрәнгәннәрне башкаларга да өйрәтергә изин) алып, яңадан Бохарага кайта. Бу юлы Бохараның бик бай мәдрәсәләреннән булган «Мир Гареб»тә бер бүлмә ала. Бер елдан соң кардәше Садретдин дә Сәмарканддан кайткач, икесе бергә шул бүлмәдә яшиләр. Ш. Мәрҗани бу юлы Бохарага бер максат вә програм белән кайту сәбәпле, вакытын тагын да файдалырак рәвештә үткәрә. Бүлмәсеннән бик күп чыгып йөрмичә, күбесенчә төрле китаплар укып, кайберләрең күчереп язып алу белән шөгыльләнә. Күчереп алырга дигән китаплар бик күп булганга, кайберләрең башкалардан да күчертеп яздыра; кайвакыт шәкертләрне җыйнап, өмә белән дә яздыргалаган.

Ш. Мәрҗани бу эшләр белән шөгыльләнеп, Бохарада тагын биш ел буе яши. Сандыклар тутырып китаплар хәзерләгән кебек, бер-ике тулы мукча үзе язган кәгазьләр һәм дәфтәрләр дә җыела. Аларда ул төрле җирләрдә күргәннәрен, шулай ук үзе ишеткән нәрсәләрне язып барган була. Ибне Фадланның «Рисалә»[29] дигән әсәрен дә бер китап йортында табып, күчереп алган була. Үзенең кайбер әсәрләрен ул Бохарада язган, икенчеләрен шунда яза башлаган була. Бу соңгы биш елда Бохарада бик күп татар, үзбәк һәм төрекмән шәкертләрен дә укыткан. Китаплар күчереп язу эшләрендә алардан да файдаланган.

Ш. Мәрҗанинең әйтүенә караганда, бу биш ел эчендә Бохарада тапкан табышының иң зурларыннан берсе Идел-Урал, Куруч авылыннан килгән Низаметдин Илһами белән дуслашу булган. (Низаметдин Илһами бу китапны язучы доктор Ләбиб Каранның әтиләре ягыннан якыннарыннан булган кебек, Каран авылы мәдрәсәсеннән Бохарага килгән була. Бу мәдрәсәдә дә аны зирәклеге өчен «хыялый» дип йөрткәннәр.) Аның белән Сәмаркандда танышып, аннан Бохарада да еш аралашып дүрт ел яшәгәннәр. Соңыннан ул иптәше Гариф дигән кеше белән һиҗазга[30] китеп хаҗ кылганнан соң Һиндстанга улашканнар. Бу ике илдәшебез 1856 елда югалганнар. Кайдадыр юлбасарлар тарафыннан үтерелгәндекләрен сөйләгәннәр. Ш. Мәрҗани бер ара: «Низаметдингә очрамаган булсам, Бохарага килүдән күргән файдам бик аз булсы икән», — дип сөйләгән. Низаметдин докторлык белемнәрен дә, һәйәт һәм һәндәсә[31] фәннәрен дә тирән үзләштергән гыйлем иясе булган. Анын ярдәме белән Мәрҗани дә һәйәт һәм һәндәсә китаплары язып алган. Низаметдин бик зирәк, туры сүзле, бик тиз җавап таба торган кеше булганга, аңа иптәшләре «Илһами» дигән исем такканнар.

Ш. Мәрҗани кичләрен янына каләм, кәгазь, шырпы һәм шәм, яисә лампа куеп ята торган булган. Йокы арасында уянган чакта берәр нәрсә исеНә килсә, шунда ут кабызып, аны ул кәгазьгә теркәп куя икән. Аның бу гадәте үлгәнче шулай дәвам иткән.

Ш. Мәрҗани Бохарада Ишани Төрекмәни дигән бер ишанга кул биреп, илгә кайтканда аннан ишанлык иҗазат-иамәсе[32] дә алган. Ишани ана бер таяк, бер туры юлга өндәү хаты һәм бер чапан биргән. Ләкин Мәрҗани илгә кайткач ишанлык кылмаган кебек, башкаларга да ишанга кул бирүне һич тә киңәш итмәгән. Хәтта шәкертләреннән кайберләре ишанга кул бирергә теләп: «Безгә кайсы ишанны күрсәтерсез икән?» — дип сораучыларга да: «Иң яхшы Ишан Коръәни Кәрим», — дип җавап биргән, һәр көн: «Бераз Коръән укыгыз һәм дә мәгънәсен аңлап укырга тырышыгыз!» — дип киңәш бирә торган булган.

Бохарада су аркылы йога торган бер Риштә-Гошә дигән бер чир бар икән. Бу авыру йокмасын өчен суны һәрвакыт кайнатып эчәргә кирәк икән. Мәрҗани саулыгын сакларга бик тырышкан... Ләкин бер дә туйганчы йоклый алмаган, һәр вакытын уку, күчереп язуга биргән. Кайвакыт көннәр буе яланаяк йөргән. Шәкерт чагында кием-салымга бер дә исе китмәгән. Ләкин илгә кайтып мулла һәм мөдәррис булгач, бик яхшы һәм бик пөхтә киенүгә чиксез ригаять[33] иткән. Бохарада шәкертләр арасында очрый торган начар хәлләрдән, әфиүн йотудан, тәмәке тартудан, отыш уеннарыннан бик сакланган, хәтта, атна кичләрдә шәкертләр ясый торган уен, көлке җыеннарына да һич йөрмәгән. Каядыр якын җиргә барганда яисә бер кибеткә чыкканда бер чапан ябын кына чыга икән. Берсе

аннан «Нигә болай кыланасың?» — дип сорагач: «Таныган берсе очрап мин сүзгә тотмасын дип шулай эшлим, һәм аның, һәм минем дә вакытыбыз бушка китәр, сөйләшкәндә күп вакыт әрәм була»,— дигән, һичбер кеше белән талаш, тартыш ясамаган. Үзенә авыррак сүз җиткерүчеләргә дә илтифат итмичә эндәшмәгән, берәү белән дә әрепләшеп тормаган. Үз эшен үзе күргән. Башкалардан сүз күчереп йөртмәгән. Сөйләгән сүзләре һәрвакыт чын, туры һәм дәлилле булган. Бохара халкы кебек рия[34] нифак[35], икейөзлелектән бик сакланган.

## Мәрҗанинең илебезгә кайтуы

Ш. Мәрҗани 1849 елның 3 июнь (яңача 16 июнь) дә зур бер татар сатучылар кәрваны белән Бохарадан илгә таба юлга чыккай. Төрле нурлар белән тулган нурлы башыннан тыш, илебездә булмаган, төрле белемнәрне эченә алган бик әһәмиятле китаплар тутырылган сандыклар белән илебезгә кайту голына чыккан. Аның нурлы башы тулы белемнәре аркылың тышка таба чыга иде. Шуңа күрә аның сөйләгән сүзләре белем, язган язулары белем белән тулы була иде. Юлчы кәрван иптәшләре, гол буенча аннан ислам тарихын тыңлап, күп гыйлемнәр алалар. Юлчылар аңа бик күп дин һәм шәригать турында сораулар бирәләр, болар турында аннан бик туры, чын җаваплар алганнар.

Бу караванда бер сарт та бар икән. Ул бөтен бу сөйләшүләрне тыңлап барганнан соң: «Мин гомеремдә бик күп дин белгече, муллалар, мөдәррисләр күрдем. Ләкин бу ногай белгече хәтле тирән һәм киң белемле, тәмле сүзле бер белгеч күрмәдем», — дигән. Юлда Имән Кала, Орски, Оренбург калаларын уран, аларда бераз тукталып йөри торгач, ике ай да ике көннән Казан каласына килеп җиткәннәр. Икенче көнне Ш. Мәрҗани үз авылы Ташкичүгә кайтып әткәе һәм кардәш-ыруглары белән кавышкан.

## Казанга чакырылу

Ш. Мәрҗани илгә кайткан чакта Казанның беренче мәчетенең имамы булмаган. Хаҗга китәр өчен имамлыгын ташлаган булган. Шул мәхәлләнең башы саналган, Казанның атаклы, зур байларыннан булган Ибраһим Юнусов (Озын Ибрай) дигән кеше, мәхәлләсенә иң атаклы бер мулланы имам итеп сайларга җыенуын әйтеп, шундый данлыклы бер дин белгечен эзләргә дә керешкән икән. Ул олуг белгечне тапса, башта аны Казанга чакырып, биредәге мөдәррисләр, хәзрәтләрне җыйнап, бер моназәрә[36] (дини бер мәсьәләдә сүз көрәштереп тартышу) ясаячагын да әйткән икән. Шулай итеп бу яңа муллага бер имтихан (сынау) ясау шарты куйган.

Ш. Мәрҗани белән бер кәрванда булган сатучылар Ибраһим байның бу сүзләрен һәм шартларын ишеткәч, аның янына барып, Ш. Мәрҗанине бик мактаганнар. «Бохарада укып илгә кайткан дин белгечләренең иң зуры, иң белемле һәм кәттәсе бу егеттер», — дигәннәр. Мәңгәрләр авылы сатучысы Мохтар бай да Ш. Мәрҗанине мактаган, бу егет яшь булса да, Казандагы Кәрим хәзрәтне ун ел укытырлык бер белгечтер, дип югары күтәргән. Бу мактауларны бик чын күңел колагы белән тыңлаган Ибраһим бай Ш. Мәрҗанине үз мәхәлләсе

мәчетенә имам итеп сайлау кирәклеген төшенеп, аны Казанга чакырып, муллалар белән бер мөиазәро кылдырырга теләгән. Чыннан да Ш. Мәрҗани мактаган нәрсәләргә лаек булса, аны Казанның беренче мәхәлләсенә имам итеп тамга җыярга хәзер булуын белдергән. Шуннан ул Ш. Мәрҗанигә Казан муллаларының зур мәҗлесенә чакырып хат җибәргән. Мәрҗани шул чакыру буенча 1849 елның 2 ноктябрендә (яңача 15 октябрьдә) Казанга шушы муллалар мәҗлесенә килгән.

Ибраһим бай бу мәҗлескә Казанның гына түгел, башка җирләрдән дә зур хәзрәтләрне чакырган була. Бу муллалар, бигрәк тә Мәңгәрле Мохтар байның сөйләгән сүзләрен ишеткән Кәрим хәзрәт, байтак китаплар актарып, шәрех һәм Хашияләрне[37] дә күздән кичереп, бу мәҗлескә, мөназогага хәзерләнеп килгәннәр. Кәрим хәзрәтнең планы буенча мулла Габделвәли Ш. Мәрҗанигә карап: «Сездән бер сүз сорар идем», — дигәч, Ш. Мәрҗани: «Мәҗлестә олуг хәзрәтләр бар, алардан сорагыз», — дигән. Теге мулла да: «Сездән ишетәсебез килә иде», — ди икән. Ш. Мәрҗани бу сорауга җавабны бөтен дәлилләре белән бик яхшы биргән булса да, Кәрим хәзрәт сүзгә катышып, башка муллалар да аңа ияреп, шактый мәгънәсез сүзләр белән көрәшүләрне — мөназәгаиы — озайтып җибәргәннәр. Ибраһим бай бу сүз тартышып бик кызыксынып карап торса да, нәтиҗәдә кайсы якның җиңгәнен аңламыйча калган. Ләкин анда булган бер авыл хәзрәте Гали ишан һәм башка ике якка да тигез күз белән караган муллалар Ш. Мәрҗанинең сорауларга биргән җавапларын бик туры һәм бик төпле тапканнарын Ибраһим байга белдергәннәр. Шуннаң соң Ибраһим бай Ш. Мәрҗанинең бик мулла бер зат булуы турында ышанган. Бу мәҗлестән соң Мәңгәр сатучысы Мохтар байны үзе исеменнән Ш. Мәрҗанине мәхәлләнең имам һәм мөдәррисе итеп килергә чакыруын үтенгән. Мохтар бай да Ш. Мәрҗанигә Ибраһим байның үтенечен белдергән. Мәрҗани: «Әтием изен[38] бирсә, бу чакыруны кабул итәрмен», — дип җавап биргән дә авылына кайтып киткән.

Бөтен бу шау-шудан соң Ибраһим бай мәхәллә халкын җыйнап, мәхәлләләре өчен бик әйбәт бер мулла тапканлыгын, аны имам хатип Һәм мөдәррис итеп сайларга тамга җыю кирәклеген белдергән. Мәхәлләнең башы һәм олуг вә юмарт бае булуын искә алып, мәхәллә халкы аның теләге буенча бик тиз генә тамга җыеп, Ш. Мәрҗанине үзләренә мулла итеп сайлаганнар. Шуннан сон. Ибраһим бай Ш. Мәрҗанине Корбан бәйрәмендә корбан ашына чакырган. Бу мәҗлескә ул отисе белән килгән. Бу мәҗлес янә дә зур бер мәҗлес булыр, күп муллалар чакырылган, биредә элекке мәҗлестәгедән дә мөназәгалар кылышу үткәрелгән. Ш. Мәрҗани бу юлы, авылына кайтканнан соң бер ай үткәч, Ибраһим бай аларның берсенә ике ат, икечесенә өчәр ат җигелгән өч чана җибәреп, мулласын Казанга алдырган. Шулай итеп Ш. Мәрҗани бөтенләйгә Казанга күчеп килгән, 1849 елның 8 декабрендә (яңача 21 декабрендә) беренче җомга намазы кылдырган.

Бер айдан соң чанага утырып Уфага — мөфти һәм казыйлар алдында имтиханга бара. Уфада мөфти Габделвахит хәзрәт аны үз өендә кунак итеп, казыйлар янына алып барган да: «Мин бу олуг дин белгечен Казан каласының беренче мәхәлләсенә имам хатип һәм мөдәррислегенә лаек таптым. Сез ни әйтерсез икән?» — дигән. Алар да: «Сез лаек күргәч, без дә кабул итәрбез». — дигәннәр. Имтихан-фәлән булмаган. Ләкин казыйлар: «Безнең башкармабыз олуг

бер мәхкәмәдер. Бу зат турында монда бер мәҗлес булырга тиештер. Ш. Мәрҗани хәзрәтләре һич булмаса бер Илһам сүрәсен укысыннар», — дигәннәр. Бик зур бер имтиханга хәзерләнеп килеп, бер «Илһам» сүрәсе уку белән генә имтихан үткәрү Ш. Мәрҗанинең кәефен бик бозган. Моны ул мыскыллау төсле, башы иләс-миләс килеп, «Илһам» сүрәсен укыганда ялгышканлыгын риваять итәләр.

Ш. Мәрҗанинең Казанга килгәнче үк аның атаклы зур белгеч булганын ишеткән байтак кына шәкертләр Ибраһим байның мәдрәсәсенә җыелганнар. Ш. Мәрҗани тезләнеп утырган 65 шәкерткә Тәфсир[39] укыта башлаган. Чиксез шат, кәефле булып, күп вакытын шәкертләре белән бергә шөгыльләнеп уздыра торган булган. Бер елдан соң хатыны — абыстай үлеп китсә дә, шундый кайгылы вакытта да шәкертләрне укыту, тәрбияләүне һичбер көн онытмаган, киресенчә, алар белән көн кичереп юана торган булган. Бер ел ярым буе өйләнмичә мәдрәсә һәм шәкертләре белән мавыгып эшләп вакыт кичергән.

Ибраһим бай да бик кәефле: Мәрҗанинең зур бер дин белгече булганына чын күңелдән ышанганы өстенә, мәдрәсәсенең башка мәдрәсәләрдән югары торганын күреп, аның һәр яктан бик шәп һәм төзек булуына бик тырыша иде. Мәрҗани икенче тапкыр өйләнгәндә аның туен ул үз өендә ясатты. Биш елдан соң мәдрәсәдән югары белемле муллалар җитешеп чыга башлады. Ләкин бу шатлыклы, кәефле алга бару гел генә болай сузылып китмәде. Арага шайтан килеп керде дә Ибраһим бай белән Ш. Мәрҗанинең дуслыгын бозып китте.

Ибраһим бай Казанда бик зур бер кеше булып санала иде. Чөнки бик зур бер бай булу белән бергә хөкүмәт йортларында да зур урыны бар иде. Шуның өстенә үзе бик юмарт, хаклыкны бик сөя иде. Шунлыктан бөтен Казан татарларына сүзе кичә (үтә. — Ә. К.), һәркем аны хөрмәт итә иде. Шул сәбәпле үзен бик зур кеше дип уйлаган бу бай үзен мәхәллә халкыннан һәм башка байлардан югары тоту белән генә канәгатьләнмичә, ул үзен хәтта бөтен муллалардан да югарырак саный иде. Менә шуннак чыгып ул һәр нәрсәне үзе теләгәнчә йөртергә тырыша, янәсе, аның сүзе генә чын, хак сүз дип эш итә. Шул ук вакытта ул мулла, хәзрәт, шәкерт дип тормый, һәркем белән шаяруны да ярата иде. Кайвакыт бу шаяруларда чигеннән үтен, байлык югарылыгы белән бик хөрмәтле затларны да мыскыл итеп куя иде. Аның Мәрҗанигә хөрмәте зур булуга карамастан, ул аны үзе теләгәнчә йөртергә, аңа уенчык ясарга да тели иде.

Ш. Мәрҗани, олуг бер дин белгече булу сәбәпле, надан бер бай кулында уенчык булырга түземлек күрсәтә торган затлардан түгел иде. Ибраһим бай салдырган мәдрәсәнең иясе һәм аның өчен кирәк-яракларга ярдәм итүче буларак мәдрәсәдә алып бара торган дәресләргә дә тыгылырга ярата иде. Хәтта тора-бара Ш. Мәрҗанинең мәдрәсәгә керткән дәрес тәртипләрен үзгәртергә дә тыгыла башлады. Бер шәкертнең әхлаксызлыгы ачылгач, Мәрҗани аны мәдрәсәдән куа. Бу шәкерт байга барып зарлангач, бай Мәрҗанигә: «Син минем мәдрәсәдән бу шәкертне ничек куа аласың?» — дип аңа бик авыр сүзләр әйткән. Ул шәкерт байга барып: «Мәрҗани сезнең турыда шулай сөйләде, болай сөйләде», — дип, ике араны шактый бутаган икән. Бу хәлдән соң бай Мәрҗанине акшамнан соң өенә чакырган. Ш. Мәрҗани дә байга: «Бу ахшамнан соң мине бер фәкыйрь чакырды, аңа сүз бирдем», — дигән булса да, Ибрай бай бер ярлык кеше өчен минем хәтеремне аска салмас дип уйлаганга, Мәрҗанинең үзенә киләчәгенә һич тә

шикләнмәгән. Ш. Мәрҗани исә иң элек ярлы кешегә киткән, аннан соң гына бай өенә килгән. Ибраһим бай бик ачуланып, авызына килгән бик каты, начар сүзләр белән ябырылса да, Мәрҗани бер дә кызмыйча: «Элек чакырганга элек киттем. Шәригать шулай куша», — дип җавап биргән.

Беркөнне Ибраһим бай Ш. Мәрҗанике өенә чакырып, үз кәефенс кәеф итеп, Мәрҗани белән шаярып уен-көлке ясарга тотынган. Мәрҗанинең моннан кәефе китеп: «Әгәр сез мондый мәсхәрәлекләрдән ваз кичмәсәгез, мин сезнев өегезгә моннан соң һич аяк басмам!» — дип байның өеннән чыгып киткән. Бай белән Мәрҗанинең арасы бозылудан файдаланырга теләгән кайбер муллалар Мәрҗани турысында төрле ярамаган сүзләр сөйли башлаганнар: «Ш. Мәрҗани шәригатькә хилаф сүзләр сөйли, аның артында оеп намаз кылу шөбһәледер», — дигәннәр. Бер мөдәррис Ибраһим байга хәтта: «Бу мулланың иттикады[40] бозык. Аны Себергә җибәрү өчен мал сарыф итү хаҗга бару хәтле саваплы бер эш булыр. Бу юлда түгелгән малдан кыямәт көнендә сорау да булмас», — дип бик ямьсез котырту сүзләре җиткергән.

Шушы вакытларда берекче мәчет муллалыгын ташлан хаҗга киткән Сәгыйть хәзрәт тә Казанга кайткан була; муллалыгын ташлаганга бик үкенеп, яңадан берәр мәчеткә имам булу юлларын эзли башлаган була. Ш. Мәрҗани белән арасы бозылган Ибрай бай янына барып ялагайлана да башлый. Мено шулай итеп Мәрҗанигә каршы дошманнар күбәеп, берләшеп китәләр, шулар: «Яше кермәгән бер кызга никах укыды», — дип Ш. Мәрҗани өстеннән шикаять ясаталар. Мондый хәл булмауга карамастан, байның сүзе көчле дип күрсәтелеп, 1854 елның 3 сентябрендә (яңача — 16 сентябрь) Мәрҗанинең указлыгы алына; имамлык, мәдрәсәдә сабак бирү дә, укыту да тыела. Сәгыйть хәзрәт, моннан файдаланып, тиз генә тамга җыеп, беренче мәчеткә тагын имам булып урнаштырыла. Ул, мәдрәсәгә килеп, шәкертләргә дәрес бирергә дип тә хәзерләнә башлый.

Бу көтелмәгән үзгәреш бик әйбәт җитлегеп килгән шәкертләрнең башына йодрык белән тондырган кебек була. Бик сәләтле һәм зур дин белгечләре булырга өметләнгән шәкертләрнең киләчәккә тоткан юллары өстенә таштан койма куелгандай була. Бу шәкертләр: «Без Ш. Мәрҗани хәзрәтләрдән башкасыннан укымыйбыз, гомеребезне бушка үткәрә алмыйбыз», — дисәләр дә, Сәгыйть хәзрәтнең: «Мәдрәсәдән чыгып китсеннәр», — дип, байдан боерык килгәч, бу шәкертләр башка мәдрәсәләргә таралып киткәннәр. Мәдрәсәдә бары 5-6 гына шәкерт калып, бу мескен белем йорты бер ташландык өйгә әйләнеп кала.

Ш. Мәрҗани бу нәхак, начар хәлләрдән бик күңелсезләнеп, Бохара һәм Сәмәрканддан җыйнап, үзләштереп алган белемнәрен кешеләргә җиткерә, тарата алудан өметсезлеккә төшеп, башка өлкәләргә күчеп китү турында уйлана башлаган. Шакир Казаковның сөйләвенә караганда Ш. Мәрҗани аңа: «Казанда белем эшләренә хөрмәт калмаган. Бу сәбәптән башка ислам йортына күчү кирәклеген төшенә башладым. Багдад каласына китәргә уйлыймын», — дигән.

Чынлап торып ул чорда бөтен татар муллалары Ш. Мәрҗанигә каршы булып, аның Казанда файдалы бер эш алып баруы мөмкин түгел кебек күренә иде. Ләкин мәхәллә халкы арасында Ш. Мәрҗанине яраткан һәм аңа бик хөрмәтле татарлар да бик күп була. Никах яшенә җитмәгән кызга никах укыды дигән

сүзләрнең ялганлыгы танылгач, бу эшне яңадан кире тикшерүне сорыйлар. Бу эш тикшерелсә Ш. Мәрҗанинең гаепсез булганлыгы мәйданга чыгачактыр дип, кирәк урыс хөкемәтенә, кирәксә Уфадагы шәргыять мәхкәмәсенә баш органнар. Шулай ук: «Без Ш. Мәрҗанидән башка бер имам да теләмибез», — дигәннәр. Әле эшнең тикшерелә башлавында көтмичә, шул шау-шу арасында Ш. Мәрҗанигә яңадан тамга да җыеп куйганнар. Бу эшне тикшереп, Ш. Мәрҗанинең хаклы, байның хаксыз булганлыгы мәйданга чыккач, бер ел вакыт эчендә аның указы да, мөдәррислеге дә кире кайтарылып бирелгән. Бу эштә Казанның иминлек башлыгы — полицмейстры булган Шах Әхмәт Алкипның күп хезмәте тигәч.

Ш. Мәрҗани яңадан үз урнына килеп утыргач, Уфадагы мөфтилеккә бер сорауча — прошение язып, мәдрәсәнең укыту эшләренә һәм эчке тәртипләренә Ибраһим байның катнашмавын теләгән иде. Мөфти бу теләкне туры табып, Ш. Мәрҗанигә мәдрәсәнең укыту һәм эчке башкарма эшләрендә аның үзе сүз иясе булганлыгын күрсәткән бер кәгазь җибәргән. Башка мәдрәсәләргә таралган шәкертләре кире кайтып, укыту эшләре тагын алга таба йөри башлаган, ди. Ләкин мәдрәсә бик искереп чери башлаган булса да, Ибраһим бай үзенең сүзе кичмәгән бу мәдрәсәне төзәтү эшенә колак та салмаган. Мәдрәсә үз малы булганга, башкаларга аны төзәтергә дә ризалык бирмәгән. Кирәк Ш. Мәрҗани үзе, кирәк мәхәлләнең зурлары байга барып мәдрәсәнең төзәтелүенә, яисә үзләренә төзәтергә изин бирүне үтенсәләр дә, һич нәрсәгә бай колак салмаган.

Мәдрәсә артык бер ташландык өй кебек булып калган, ди. Асты таш, өсте агач булган мәдрәсәнең, почмакларын ишелеп төшү хәленә килгән: идән башлары череп тишелгән, тәрәзә астындагы тишекләрдән кышын кар, буран кереп торган. Мәдрәсә җимерелеп төшмәсен дип, тышкы яктай төрле баганалар белән терәтелгән була. Ибраһим бай мәдрәсә җимерелеп төшсен дә Ш. Мәрҗанинең башын бер бала килсен, яисә шәкертләр мәдрәсәдә тора алмыйча таралып китсеннәр дип, ерактан көлеп карап йөргән. Мәдрәсәнең, суы да киселгән, шәкертләр комган һәм чиләкләр белән Кабан күленнән су ташыйлар, тышта тәһарәт алалар, туңалар иде. Шәкертләр утын сорап байга барганда: «Туңып үлмәссез әле, тышта кар күп, кар ягып җылынырсыз», — дип җавап бирә торган булган.

Мәдрәсәнең бу хәле политсайга билгеле булып, политсай ягыннан аның бинасы яшәргә, торырга ярамый, дип рапорт төзелгәч, Ибраһим бай аны тышкы яктан такталар кадаклатып төзәткәндәй булса да, эчке ягы черегән көйгә калды. Ш. Мәрҗаии яңа мәдрәсә салып бетергәнче олуг остаз шул иске мәдрәсәдә мең төрле зәхмәт, мәшәкать белән 22 ел укыта. Мәдрәсәне, укытуны ташламый. Ибраһим байны һәм мәдрәсәнең шул хәлгә төшүеннән Казан муллалары Мәрҗанигә каршы көнчелек һәм дошманлык йөзеннән төрле кирәкмәгән сүзләр тарataлар, янәсе Ш. Мәрҗаниинең мәдрәсәсе бер төрле үсмәде, алга китмәде, шәкертләре саны да 70-80нән артмады, дип ялган таратталар.

22 ел буе Ш. Мәрҗанинең дошманнары төрле яктан тынычсызласалар да, аны бертуктаусыз кайгыга салсалар да, ул үзенең Бохарада корган изге програмыииан кыл хәтле аерылмыйча, өлкәбезгә, халкыбызга вә барча ислам илләренә файдалы эшләүдән кире калмады. Мәхәллә эшләреннән калган вакытларын милли һәм дини хезмәтләренә биреп, бик күп эшләр башкаруга

бирде. Укытты, укыды, язды. Бик күп әсәрләрен шул чорларда хәзерләде. Ул чорларда муллалар арасында зур тавыш күтәргән «На-зурәтелхак», «Әлхикмәтел-балига» һәм «Мулла Җәләл һәкиясе» әсәрләрен мәйданга куйган иде.

Ш. Мәрҗани бөтен шул шау-шуларга бер колак салмыйча мәхәллә, мәдрәсә эшләрен ташламыйча, җәйге озын көннәрнең күбесен Казан эчендә, Казан тирәсендәге авылларда, гүр бакчаларында йөреп, гүр ташлары тикшереп, милли тарихыбызның нигезен кору буенча армый-талмый эшләп килде. Дөньяда татар дигән бер милләтнең, булганлыгын, аның шул Казанда яшәгән халыкның үзе икәнен, Идел-Уралда, Урта Азиядә һәм дә Төркестанда яшәгән халыкларның да татар икәнлеге вә аларның ялтыраган уртак тарихлары булганлыгың язып чыгарды. Бу турыда башлап «Гилаләт әз-зәман фи тарихи Булгар вә Казан» атлы бер китап язды. Бу китап урыс иске әсәрләр җәмгыятенең Казанда җыйналган тулы, зур җыелышында атаклы Көнчыгыш белгече Радлов[41] каләме белән урысчага әйләндерелеп, Ш. Мәрҗанинең белем юлындагы хезмәтенә котлау булды. Бу зур җыелышта Ш. Мәрҗани үзе дә катнашкан иде. Аннан соң бу тарих китабының тагын да зуррагы булган «Мөстәфадел әхбар фи тариһим әхвали Казан вә Булгар»[42] китабын язып чыгарды. Урта Азия. тарихы өчен бик кыйммәтле бер әсәр саналган «Гарафәтү-әл һәүакин»[43] атлы әсәр дә язып бастырды. Әсәрләренең, иң зуры булган җиде җилдән[44] «Вәфиятел-әслаф вә тәһиуател аһлаф» әсәренең дә күбрәге шул елларда язылган иде. Шул ук елларда Коръәнне төзәтеп, пәйгамбәребез һәм сәхаилары[45] заманындагы Коръән кебек бастыру эшенә билгеләнеп, бу эштә бик зур хезмәтләр күрсәтте. Бу турыда бер «Фәваиди мөһимме» атлы әсәр дә язды.

Ш. Мәрҗанинең бу чорда озын Ибрай оештырган начарлыклары һичбер эш күрсәтмәслек дәрәҗәдә күп булса да бу олуг белгеч аңа, тормышына һәм эшләренә каршы салынган бөтен киртәләрне атлап, эш арбасы тәгәрмәченә тыгылган таякларны сындырып, зур көч куеп кичте вә шул хәтле зур һәм игелекле изге эшләрне башкарып мәйданга чыгарды. Бу олуг, хөрмәтле белгечебезнең бетмәс-төкәнмәс зур белеме һәм шуның хәтле чиксез зур энергиясе булган икән. Андагы бу чыдамлык, бу түземлек шуны, күрсәтә.

## Мәдрәсәдән күчү

Ш. Мәрҗани бөтен шул авырлыкларга күкрәк киереп эш күрүе, чиксез әсәрләр мәйданга бирүе белән көнче дошманнарының да хөрмәтләрен үзенә тарта башлаган иде. Казан муллалары арасында да Ш. Мәрҗанинең тирән һәм киң белемен, күрсәткән гайрәтләрен, гаять алапа, иелмәгән башын күз алдында тотып, теләр-теләмәс аның алдында хөрмәт белән иелергә тиешлекне күрүчеләр булды. Чөнки үзләре башкара алмаган байтак дини эшләрне аңа тапшырырга тиешле тапканнар иде. Шул ук вакытта Уфадагы мөфтилектән аңа ахунлык дәрәҗәсе дә бирелгән иде (1867 елда).

Бер көнне Казан губернаторы Ш. Мәрҗанине янына чакырып, хөрмәт белән кабул итеп, аннан хайваннарны корумак турысында татарча бер брошюр язуны үтенгән иде. Шул сорау буенча ул язган ул брошюр хөкүмәтчә бик яхшы каршы алынып, губернатор аңа бу турыда бик рәхмәт укып хат яза һәм бу брошюр,

хөкүмәт хисабына бастырылып (1869), татарлар арасында бушка таратыла. Шулай итен, төрле яктан Ш. Мәрҗанинен дәрәҗәсе күтәрелә, хөрмәте арта барган саен, Ибраһим байның дәрәҗәсе төшә бара иде.

Казанда Ислам мәһкәмәсе дигән өч мәһкәмә бар иде. Аларның барсының да баш Ибраһим бай иде. Тора-бара ул мәһкәмә бетерелеп, байның ул дәрәҗәсе дә калмаган иде. Мәдрәсә мәсьәләсендәге тискәрелеге бөтен Казан байларын үпкәләткән һәм үзенә каршы кыймылданырга көчләгән иде. Беренче мәхәлләнең башка байлары берләшеп, үзара акча җыйнап, хәзерге көндә Ш. Мәрҗани мәдрәсәсе дип йөртелгән урынны һәм йортларны сатып-алын, бер мәдрәсә ачканнар иде. Озын Ибрай мәдрәсәсенең шәкертләре 1871 ел 22 ноябрь (яңача — 5 декабрь) көнне иске мәдрәсәне ташлап яңа мәдрәсәгә күчкәннәр иде.

Мәхәлләнең башка байлары бу эшкә керешкәндә, Ибраһим бай ал арны мыскыллап: «Алар сарык кына бит, ул сарыклар миннән башка ни эшли алалар», — дип азлардан бик көлгән иде. Теге байлар һәм мәхәллә халкы бу сүзләрне ишеткәч, тагын да гайрәткә килеп, яңа мәдрәсәне тагын да яхшырак карарга керешкәннәр иде. Мәдрәсәләренең күршесендә тагын бер йорт сатып алып, ул яңа мәдрәсәне зурайтып җибәргәннәр иде.

Мәчет, мәдрәсәләрнең бер кеше карамагында булудан бик газап чиккән Ш. Мәрҗани хәзрәтләре мөфтилеккә бер сораучы җибәреп, мәчет һәм мәдрәсәләрнең халыктан сайланган бер җыйнау — һәйәт карамагында булуын теләгән иде. Аның бу теләге кабул ителеп, Рәчәйдәге бөтен татар мәдрәсәләре өчен бер карауч‌ы җыйнау эше һәм мөфтилекчә, һәм дә хөкүмәтчә бер төзек хәленә китерелде. Бу тартыкта җиңелеп, бик түбән төшкән Ибраһим бай соңыннан мәдрәсәсен таштан салдырып, Ш. Мәрҗанидән шәкертләрне анда күчерүне үтенгән. Мәрҗани дә мәдрәсәне кулына тапшыру шарты белән килә алачагын белдергән. Ләкин бай бу шартны кабул итмәгән. Соңга таба разый булган булса да, башка байлар шәкертләрнең айда күчүләренә разый булмагач, хәзер укый торган мәдрәсәләрендә калганнар. Ибраһим бай шәкертләрне үзенең мәдрәсәсенә хөкүмәт көче белән көчләп китерүне төшенеп, татар уку йортларын күздән кичерүче инспектор, атаклы Көнчыгыш; белгече Радловтан бу ярдәмне сорады. Ш. Мәрҗанинең дусты булган Радлов бу ярдәмне аңа бирмәде. Радлов Ш. Мәрҗанигә бер хат язып, иске мәдрәсәдән күченүнең нәрсә икәнен аңлап бетермәвен аңлатып бирүне сорады. Ш. Мәрҗани дә мәхәллә халкы һәм балаларын анда китерүгә булмаганлыктан күченеп баруга ризалашмавын 1875 ел 14 август (яңача — 27 август) белдерде.

Ш. Мәрҗанинең бу яңа мәдрәсәсе агачтан булганга, бераздан ул да чери башлады, тузды. Ул шул чакта ул! мәхәллә байлары һәм үзен сөйгән Казанның башка мәхәллә байлары белән бергә җыйналышып, күп акча җыеп, бүгенге көндә Казанда Ш. Мәрҗани мәдрәсәсе дип танылган зур, таш мәдрәсәне салдырып, аны Мәдрәсәи Галия дип атаганнар (1881 ел 8 октябрь, яңача — 21 октябрь). Бу яңа мәдрәсәдә Ш. Мәрҗанинен шәкертләре елдан-ел арта барды. Бигрәк тә бу таш мәдрәсәнең шәкертләр саны бик арткан иде. Ш. Мәрҗани бу мәдрәсәдә 8 ел дәрес укыткан. Бу мәдрәсә салынгач, Ш. Мәрҗани мәдрәсә башкармасы өчен бер Низамнамә[46] ясап куйган һәм аның ярдәмендә эшне оештырып җибәргән. Аңа хәтле: һичбер мәдрәсәдә низамнамәләрнең булганы юк иде.

## Ш. Мәрҗанинең укыту программы

Ш. Мәрҗанинең укыту програмын бер тикшереп карасак, нәкъ Бохара програмы белән укытуы күзгә чалына. Хәлбуки, ул Бохара мәдрәсәләрене яратмыйча, аларның. укыту ысулларына бик ачык кимсенеп, андагы остазларына да бу төшенчәләрне белдергән иде. Бу тикшерүчеләр бу хәлгә бик аптырап, Ш. Мәрҗани мәдрәсәсендә укып чыккан хәзрәтләрдән моның сәбәбен сораганнар. Ш. Мәрҗани Казанга килеп имам һәм мөдәррис булгач, иң элек шәкертләрне Тәфсир дәресе белән укыта башлаган иде. Бу башлату аның чын үз програмы буенча булып күренә. Ләкин ул соңыннан Тәфсир, Хәдис, Гарәп әдәбияты, Әхлак, «Хикмәти кадимә[48], Ислам тарихы һәм Сәйяра[49] дәресләрене програмындан төшереп, алар урнына өченче-кирәксез саналган Мантыйк, Кәлам һәм кайбер шәрехләрне укыту белән нигә үзенә үзе каршы килгән? — диләр. Бу сорауларга каршы җаваплар шул рәвешләрдә булган:

1. Ш. Мәрҗани заманында бөтен татар мәдрәсәләрендәге укыту системы Бохарадагы төсле булган. Атаклы татар мәдрәсәләренең шәкертләре бер-берсе белән аралашып, Мантыйк, Каләм фикъһе дәресләре бәхәсләре өстендә торып мөназәгә кылышалар иде. Ул чакның шәкертләре күп укып белем алудан бигрәк, күп мөназәга кылып сүз көрәштерү белән күбрәк мавыгалар иде; кычкырышудан тәм табалар иде. Аларча, белемле һәм бик шәп мулла булу шул фәннәрдә оста сөйләшә белү белән үлчәнә иде. Әхлак һәм дин дәресләрен генә укып маташучыларга алар «туң» «бөн» дип кенә карыйлар иде. Ш. Мәрҗани-нең шәкертләре дә, шул иске агымга ияреп, Мантыйк, Калам дәресләренә бирелеп киттеләр. Шунлыктан Ш. Мәрҗанинең мәдрәсәсендә дин дәресләренә күп урын бирелмәгән. Әгәр Ш. Мәрҗани «Мөкаддимә»[50] китабына язганы кебек, ул заманның модасы булган дәресләрне укытмаса иде, шәкертләре башка мәдрәсәләргә таралый киткән булырлар иде.

2. Ш. Мәрҗани хәзрәтләре китап язу эшләренә бик бирелеп, татар тарихыны төпчү, тикшерү кебек тирән төшенчәләргә чумган иде. Мәдрәсә әлшәрен хәлфәләренә тапшырып, күбесенчә аларның теләкләренә калдырган иде. Уку эшләрендә, дәрес китапларын билгеләүдә шәкерт һәм хәлфәләр ирекле иделәр. Ш. Мәрҗани көчләп укытуны бер дә сөйми иде. Шәкертләрнең үз кирәкләрен үзләре кайгыртуны бик ярата иде. Әгәр шәкертләрдән кайберәүләре берәр яңа дәресне укытуны аннан сораса, ул сөя-шатлана аны укыта иде. Дөреслеккә килгәндә, Ш. Мәрҗани мәдрәсәсенең дәрес програмында ачык күрсәтелмәгән бик күп сабакларны укыткан. Төрле вакытларда төрле Тәфсирдән («Казый Бәйзави»[51], «Тәфсир Мәдарик»[52], «Кәшшаф»[53]) булсын һәм Хәдистән «Саһиһ и Бухари»ны[54], «Мишкатул Мәсаби»ны[55], бәлагат[56] дәресеннән «Тәлһис»не [57] укыта. Бу дәресләр күбесенчә атна кич һәм җомга көннәре укытылганга, мәдрәсәнең төп програмында язылмаганнар иде. Бу дәресләрне укырга теләмәгән шәкертләр дәрестән качалар иде.

3. Ш. Мәрҗани сабак укыткан чакларында шәкертләренә татар мәдрәсәләрендәге дәрес програмларының начарлыгын-нан, аны төзәтү кирәклеген бик зарланып сөйли иде. Бик күп дәресләрендә (Тәфсир, Хәдис, Сәйяри Нәби)[58]

дин, гарәп һәм фарсы әдәбиятыннан, бигрәк тә ислам һәм татар тарихыннан, дин белгечләренең тормышларыннан күп белекләр бирә иде. Ш. Мәрҗани бу белем һәм белекләрне Бохара һәм Сәмаркандда төрле китап йортларында чокчынып, эзләп табып алганы өчен, бик күп китапларны үз бүлмәсендә бикләнеп уку белән чиксез белемләргә ия булганлыктан, шәкертләрдән дә шул рәвештә кызыксынып, мавыгып белем алуларын көтә иде. Аларны һәр төрле белемнәр алырга, күп белекле булырга кызыктыра, ләкин һич тә көчләми иде. Ләкин аның хәлфәләре: «Әгәр без Мантыйк, Кәлям укымасак, башка мәдрәсә шәкертләре каршында авыз ачып утырачакбыз», — диләр вә, мантыйкны иң алдынгы бер дәрес белеп: «Бер шәкерт мантыйкыны белсә һәр дәресне белә ала, гакълый гыйлемнәр — бөтен белемнәрнең ачкычы», — диләр иде.

Менә шул рәвештә Ш. Мәрҗани хәзрәтләре, мәдрәсә програмнарын төзәтү турындагы төшенчәләрне эшкә ашырырга юл тапмаганга, ярдәмчеләре булмаганына бик үкенә, аптырый һәм кайгыра иде. Күп вакытларда «Шәкертләрем, Кышкар, Буа, Казан мәдрәсәләре шуларны укыта, ул шәкертләр шулардай чыгып сөйләшәләр, дия-дия минем мәдрәсәне дә юлдай чыгардылар», — дип зарлана иде. «Бохарада уйлап тапканым, шулай укытырмын дип, төшенеп кайтканым, бөтен планнарым илгә кайткач бозылды. Шәкертләр юк нәрсәләр белән гомер түкәтәләр, кирәклене укымыйлар. Кирәклене кирәксенмәгән адәмне ни эшләтәсең? Мин шул шәкертләремнең кирәксен-гәнләреннән берсене дә укытмас идем дә аларны, теләгәнен укыттым», — дип сөйли, һәрвакыт дәрес програмларыннан зарлана, ләкин заманның көчләвенә буйсынып, үзе теләмәгән нәрсәләрне дә укыта иде. Ш. Мәрҗани кайбер дәресләрендә татар тарихыннан, яисә гарәп вә фарсы әдәбиятыннан сүз ачып, шәкертләренә бик файдалы белем һәм белекләр биргән булса, андый дәресләрдән соң шәкертләр: «Дәмулла бу дәрестә әллә нинди гарәп һәм фарсы бәетләре укып бик эчебезне пошырды; иске ханнар заманасында булган эшләрне, онытылып беткән әкиятләрне, борынгыларның үлгән кардәш, ыруг һәм туганнарын сөйләп гомер уздырды. Бу сүзләре кайчан бетәр икән дип, көтә-көтә зарыгып беттек», — дип зарланалар имеш.

## Ш. Мәрҗанинең шәкертләреннән кайберләре

Ш. Мәрҗани хәзрәтләренең мәдрәсәсендә 200дән артык мулла җитешеп чыккан иде. Болар — Кырымнан, Себердән, Әстерханнан, Пенза, Саратов, Самар, Рязань, Кострома, Тамбов, Петербург, Вятка, Казан, Уфа, Оренбург, Томск губерналарыннан килгән шәкертләр иде. Алар арасында мулла булган җирләрендә зур мәдрәсәләр ачып, йөзләрчә шәкерт укытканнары һәм башкача татар милләтенә файдалы булганнары бар иде.

1. Уфадан килеп укыган Салих углы Мөхәммәт мулла бер вакытлар Мәкәрҗә-Нижний Новгородта имам булып торганда Казанга килеп, аның 10 нчы мәхәлләсендә мулла булган һәм Госмания мәдрәсәсендә мөдәррис булып шәкертләр дә укыткан иде.

2. Тымтык авылы мулласы һәм имам, хатип, мөдәррисе булган Әхмәт Латыйф хәзрәт Ш. Мәрҗанинең иң олуг шокертләреннәидер. Бу затның зур

мәдрәсәсендә һәр ел 500дән артык шәкертләр укый һәм тирә-як губерна һәм өязләренә муллалар әзерли иде. Бу зат шул ук вакытта күп мөритле бер ишан хәзрәт тә иде. (Бу хезмәтне язучының әтисенең дә остазы иде.)

3. Фәйезхан углы Хөсәен Сембер губернасыннан булып, Мәрҗани мәдрәсәсен бетергәннән соң Казан университетында профессор булган Казембек[59] белән танышып, аның исеменнән «Мифтаху гәнеҗел Коръән»[60] исемле әсәре бергә төзеп бастырганнар. Хөсәен әфәнде соңра Петербурга китеп, андагы Университетның Көнчыгыш телләре факультетында гарәп һәм төрки телләре укытучысы итеп билгеләнгән. Татар мәдрәсәләре һәм аларның төзәтелүе турысында бер әсәр язганы кебек, Кырым ханнарының Польша һәм Рәсәй патшалары белән хатлашуы турында да 941 битлек бик зур бер тарихи әсәр мәйданга, китергән. Татарча язылган бу әсәрдән Ш. Мәрҗани дә файдаланган. Ш. Мәрҗанинең «Мөстәфад әл-әхбар фиәхвали Казан вә Болгар» әсәренә дә шактый ярдәме булган.

4. Сембер тирәсендәге Кеше авылыннан булган Сәй-фетдин углы Кәмалетдин әфәнде Мәрҗани мәдрәсәсендә ун ел укыганнан соң хаҗга киткән. Аннан кайтышлый Мисыр җирләрен урап Каһирәдәге Мәдрәсәтел-Әзһәрдә урнашып калган. Анда Коръәнне бикләгән һәм бер вакытлар Җәмигул Әзһәрнең төрекләр бүлегендә имам булып, торган. Казанга кайткач ун ел буенча Мәдрәсәи Мөхәммәдиядә шәкертләргә туры Коръән укуны өйрәткән. Шулай ук Казанның дүртенче мәчетендә дә теләгән кешеләргә Коръән укуны өйрәткән. Казан татарлары арасында туры Коръән укуны өйрәтүчеләрдән булып, Кәмал Карый исеме белән дан алган бер кешедер. Мисырда булган вакытында Ш. Мәрҗанигә кирәкле китаплар алып җибәрү белән ярдәме дә булган икән.

5. Уфа губернасыннан Базы Буга Каран авылыннан Гайнелкәмал углы Нурлыгаян хәзрәт Ш. Мәрҗанинең гыйлемгә ихласлы, сөекле шәкертләреннән саналадыр. Ш. Мәрҗани аңа бик илтифат итә һәм иң сөйгән китапларын да аңа укырга бирә иде. Бу зат, укуын бетергәч, Мәрҗани мәдрәсәсендә 2-3 ел хәлфә булып та торган иде. Ш. Мәрҗанинең китапларында дәгъва, каза, мирас һәм игътикат турыларында язган язулары да табылган. Әтисе Гайелкәмал хәзрәтнең үлүе белән, авылы Каранга кайтып, әтисе урынына имам һәм мөдәррис булып 20 ел дәрес укыткан, авыллары тирәсенә күп белем тараткан бер остаздыр. (Бу зат шушы юлларны язучының абыз әтисе — гамуҗасы буладыр.)

## Урысча уку турысында Ш. Мәрҗанинең төшенчәсе

Рәсәйдә 1870 елның 15 февраленнән соң ачылган татар мәдрәсәләрендә урысча укыту тиешлеге турында бер төзек-канун-закон чыгарылган. 1872 елда татар мәктәп, мәдрәсәләрен тикшерү, күзәтеп тору өчен инспекторлар билгеләнде. Шул чорда мөселман татар мәдрәсәләренә урысча укытучыларны билгеләү эше йөкләтелә башлау белән татарлар арасында моннан риза булмау, зарланулар башлангач, халыкка каршы каты тәдбирләр дә күрсәтелде. Шунлыктан кайбер җирләрдә фетнәләр дә чыга башлады. Моның асыл сәбәбе урысча укытучының тормышлыгы — жалуньесын да татар мәдрәсәләре бирергә тиешле булуы иде. Бер өяздә — Вятка губернасында — чуалулар да булган иде.

Шул чорда татар муллалары арасында урысча укырга ярыймы, юкмы, дигән бер мәсьәлә чыккан. Муллалар икегә аерылып, урысчаның файдасыннан, зыяныннан сүз ачын кычкырышулар, талашулар да була иде. Байтак дин белгечләре урысча укуны хәрам дигәннәр. Урысча укырга ярый диючеләр бик аз табылган. Аларның башында Ш. Мәрҗани хәзрәтләре тора иде. Аныңча, урысча укырга, өйрәнергә тиешлебез. Башка бер милләт кул астында яшәгән бер халыкка үзләре хакында хөкүмәтләренең алганы тәдбирләрснә, үзләре белән элемтәле төзек һәм низамнарны белү кирәкледер. Ул телне үз телебез итеп алу, урыс гореф-гадәтләрен кабул итү, татарча сүзләр арасына урыс сүзләре катыштыру кебек эшләрдән сакланырга тишлебез, ди иде.

Урыс хөкүмәтеңчә Казандагы мәдрәсәләргә урысча укытуны кертү турысында мәдрәсә мөдәррисләренең төшенчәләре соралганда, алар шулай җавап биргәннәр: «Безнең халкыбыз һәм шәкертләребез бик ярлылар. Мәдрәсәләрдә уку хакы бирмичә, бушлай укыйлар. Мәдрәсәләребездә урысча укыту башланса, без ул укытучының айлыгын үтәүдән гаҗизбез. Безләрнең бу хәлебезне күз алдында тотып, бу гозеребезне кабул итүләрен хөкүмәт түрәләреннән бик үтенәбез», — дигәннәр. Бу җавап, башка Казан мулла һәм мөдәррисләрнең үтенүе буенча, Ш. Мәрҗани кулы белән язылып, башкалар да аның астына кулларыны куйганнар иде.

Шушы урысча укыту эше уртага чыгып, төрле җирләрдә тавышланулар булып үткәч, татарларга урысча укытучы хәзерләү эше мәйданга килгән. Казанда бер Укытучы уку йорты — Учительская школа ачылган. Бу укыту йортына дин белемнәре өйрәтүчесе итеп Ш. Мәрҗани билгеләнгәч. Аның бу эшкә керүен бөтен Казан татарлары, бигрәк тә муллалар бик гаепләгәннәр. Аңа төрле ямьсез сүзләр сөйләгәннәр. Тирә-яктан атылган бу пычак укталуларга җавап итеп, бу олуг зат дусларына шул сүзләрне сөйләгән: «Минем бу школага дин өйрәтүчесе булып керүем акылыма килгәне юк иде. Хәтта бу эшне миңа элек тапкыр сөйләгәннәре заманда кабул итү ниятендә түгел идем. Ләкин атаклы бер белгеч һәм үземезнең яхшы дустым Радловның миңа кабат-кабат килеп, иллә дә бу эшкә мине куярга теләвен, Казан губернаторының да бик кыстап үтенүен бик кире кагарлык нәрсәләр түгел иде. Соңра үзем дә шулай төшендем: «Әгәр бу урын баштан ук бер дин белгече кулында булмаса, бәлки бөтенләй дин белмәгән кешеләр кулында калыр. Анда укучы татар шәкертләре бөтенләйгә мөселманлыктан ерак, динне белмәгән, милләтне танымаган егетләр булып чыгарлар, дип курыктым да бу хезмәтне кабул иттем. Монда укучы татар яшьләренә мөселманлыкның тормышка һәм һәр төрле фәннәргә карашын, мөселманнарның һәр төрле белемга хөрмәте булганлыгын белдерергә тиешле идек».

Ш. Мәрҗанинең дөньяга килүенең йөзенче елын котлау уңае белән басылган зур «Мәрҗани» китабы өчен Бер мәкалә язган Фуат Туктар[61], бу школа ачылгач,беренче тапкыр шәкерт булып кереп, укуыны бетергәч тә шул УК школада укытучы булып калган Шакирҗан Таһировтан ишеткәннәрен шулай белдергән: «Ш. Мәрҗани хәзрәтләре тарихны бик сөя, тарих белән бик шөгыльләнә иде. Шунлыктан ул Казан Универ-ситетының Археологический җәмгыятенә бер муча-әгъза булып язылган иде. Кайбер язган әсәрләрен дә анда укырга биргән иде. Шул сәбәпле Көнчыгыш белгечләре арасында ул да бар һәм

алар кашында игътибары да зур иде. Бигрәк тә атаклы белгеч В.В. Радлов белән бик яхшы танышып, аның белән күп вакытларда дусча сөйләшеп утыргалый иде. 1886 елда ачылган Казандагы Учительская школаны Радловның бер хезмәте, дип карарга ярый. В.В. Радлов татарларга яхшы урысча өйрәтеп, алар арасында Европа белемнәрен таратуны бик тели иде. Бу тел аркылы татарлар төрле белем һәм фәннәрне өйрәнәчәкләр, соңра үз телләрендә дә бу фән белемнәрен күбәйтергә тырышачаклар дип төшенә иде. Бер мимеч булган Радловның бу хезмәт һәм ниятендә аз гына булса да урыслаштыру мәгънәсендә бер миссионерлык төшенчәсе юк иде, диючеләр бик күп иде. Казанда бу школаны ачарга уйлагач, ул моннан татарлар шикләнмәсен, курыкмасыннар дип, андагы укытучы-ларның барчасының да татарлардан һәм ышанычлы Кеше-ләрдән булуыны бик тели иде. Шушы төшенчә белән бу школаның башкаручылыгына, урыс төзекләре буенча бер дә хаккый булмаган бер татарны Гали Мәһмүдовиы билгеләде. Кимая өйрәтүчесе итеп Ибраһим Терегуловны, башка бер өйрәткеччелеккә Шаһбазгәрәй Ахмеровны һәм анда укып чыккан Шакирҗан Таһировны да рәсем һәм матур язу өйрәтүчесе итеп билгеләгән иде.

В.В. Радлов үзенең яхшы белгән һәм бик яратканы Ш. Мәрҗанине бу школага дин өйрәтүчесе итеп кую белән бу йортының татарлар арасында игътибар күрүен төшенә иде. Чөнки Ш. Мәрҗани Казан татарлары арасында иң күп хөрмәт күргән, күп сөелгән бер дин белгече иде. Соңра Ш. Мәрҗани урысча уку һәм укытуга каршы килмәгән, аңлы бер татар олугасаны иде. Ш. Мәрҗани бу школада фикъһедан Кодури[62], иттикаттан «Гакаиде Тәһави»[63], ысулы фикъһедән «Мөхтәсар Хисами»[64] китапларын һәм дә Фәраиз[65] дәресләрен укытты. Бу дәресләр соңгы заманга күрә бик кечек күренсә дә ул вакытка күрә бик туры иде. Чөнки ул чактагы төшенчәләргә караганда, бу школадаи муллалар чыгачак вә алар татар мәдрәсәләрендә урыс теле дәресләре укытачак иделәр. Шунлыктан бу школага дини мәдрәсәләрдә укыган, гарәпчә сарыф һәм нәхү дәресләрен аңлаган шәкертләр алыначак иде.

Ш. Мәрҗани дәрес вакытларында тарихтан, татар һәм ислам тарихларыннан сүз ача, хәлифләрдән, һарунуррә-шиддән[66], хәлифә Әлмаэмүн[67] заманындагы хәлләрдән сөйли иде. Кай вакытлар дәресләр арасында шәкертләргә «Җәбер»[68], «Мукабәлә»дән[69] дә мәсьәләләр сорый, эшләп чыгара аямасалар, узе эшләп чыгара, аларга һәр нәрсәне өйрәтергә тырыша иде.

Ш. Мәрҗанинең бу хезмәте бик яхшы ният һәм милләтенә хезмәт теләге белән булган булса да Казан татарлары аңа начар күз белән карыйлар, аның школада дин дәресе бирүен мөселманлыкка каршы бер хыянәт дип уйлыйлар иде. Ш. Мәрҗанинең школага дәрескә барып кайтуын яхшысынмаган татар халкы баштарак, беренче көн, бик гаҗәпсенеп, урамнарда җыйналып карап торганнар иде. Кара халыктагы бу кара төшенчәләргә сәбәп — муллалар арасындагы шаушулар иде. Казанның олы мөдәррисләреннән берсе: «Шиһап мулла миссионер булды. Ул — урысларга сатылган кеше. Татарларга урысча укытуга ул сәбәпче булды. Кыямәт көнендә колубез якасында булыр, иншалла», — дип сөйләгән, ди. Бу сүзләр татарлар арасында да җәелгәч, кара халык арасында Ш. Мәрҗанине үтерергә хәзерләнүчеләр до булган. Бу турыда Мәрҗанигә каршы сөйләүчеләр арасында дошманнары түгел, дуслары да бар иде. Ләкин Ш. Мәрҗани хәзрәтләре,

төшенчәсендә бик ирекле булганы кебек, ышанып тотынган бер эшендә дә таянучы, нык торучы батыр бер кеше иде. Халкының, хәтта кара төшенчәле муллаларның бу шау-шуларына бер дә исе китми, өстән генә карап кичерә бирә; бер нәрсәнең турылыгына, чынлыгына ышандымы, башкаларның каршы торуларына фәлават[70] та итми иде. Шулай итеп ул, кара халыкның һәм кара төшенчәле муллаларның шау-шуына, янауларына карамастан, эшенә йөри биргән һәм дә тугыз ел буе бу хезмәтне күргән иде. Бу турыда һичбер кеше белән сүз көрәштермәгән. Бу турыда үзенә дуслык белән сөйләүчеләргә дә ул: «Безнең халык мәсьәләне төшенеп җитмидер. Аларча, урысча уку кирәксез бер нәрсә, бу кирәкмәгән нәрсәне дә Ш. Мәрҗани теләп уртага кунган һәм дәвам иттерә. Гүя, мин теләмәсәм бу урысча укытылмаячак, дип төшенәдер. Ләкин эш бөтенләй башкача. Әгәр шул школага кереп укытучы башка бер яхшы дин белгече табылса, үзем дә бу укытуны ташларга торам», — ди иде.

Ш. Мәрҗани бөтен авырлыкларга карамыйча, бу эшне дәвам итә иде. Ләкин соңрадан, школаның тикшерүчесе — инспекторы һәм кайбер укытучылары белән аралары бозылып китү сәбәпле, бу эшеннән аерылган иде. Ике араның бозылуына сәбәп шул иде, инспектор һәм башка өйрәтүчеләр бу школадан ялгыз татарларга урыс теле өйрәтүчеләр генә җитештереләчәк, дигәннәр. Ш. Мәрҗани исә, бу школадан татарларга татар мәктәп һәм мәдрәсәләрендә һәм урысча өйрәтүче һәм дә яңа фәннәрне татарча укытучы һәм дә татар авылларында мулла булырлык файдалы егетләр җитешәчәктер. Без бу школаны. шул төшенчәләр белән ачтык һәм шундый кешеләр җитештерергә тиешлебез, ди икән. Күпчелек Ш. Мәрҗанигә каршы булгач, ул аннан аерылып чыккан иде. Мәсьәләне В. В. Радлов та нәкъ Ш. Мәрҗани кебек төшенә иде. Радлов күп вакыт татар зурлары белән сөйләшкәндә: «Татарларның, уянып, тизлектә алга китүләре өчен ин файдалы юл — урысчаны яхшы белгән муллаларны күбәйтүдер», — дип сөйли икән. Бу сүзләрне бу школаның соңгы дин өйрәтүчеләреннән булган Фәсхетдин әфәнде дә сөйли икән.

Ш. Мәрҗани үзенең төшенчәсенә күрә бу школага гарәпчә сарыф һәм нәхүне белгәч, ислам динене яхшы аңлаган яшьләрне генә алу ягында булган. Мөселманча бер дә укымаган, мөселманлыкны аңлап җитмәгән татар яшьләрен школага кабул итү, милли татар телен бөтенләйгә ташлау юлын тоту буладыр, ди икән. Үзенең диненнән, милли телемдәй уку, язудан хәбәре булмаган яшьләрне бу школада укытудан татар милләтенә һичбер файда килмәс, дип уйлаган. Ш. Мәрҗани бу төшенчәләрне үзенең мәдрәсәсендәге шәкертләренә дә бик күп аңлаткан. Дөньядагы төрле телләрне белүгә: «Төрле һөнәр һәм белемнәрне өйрәнүгә ислам дине һич тә каршы түгел, хәтта үзе кызыктыра, игътикадны[71] төзәтергә кирәк, игътисад төзек, иман нык булгач, урысча уку зыян бирмәс. Ләкин мөселманлыкны белмәгән яшьләрнең урысча укулары татарлар өчен зыян гына булачак», — ди икән.

Казандагы Учительская школа беренче еллар шул Ш. Мәрҗани төшенгәнчә йөреп, мөселманча яхшы белмәгән шәкертләрне анда кабул итмәгәннәр. Соңрадан татарча язу танымаган; үз теленнән, мөселманлыктан аз гына да белеме булмаган татар малайларын да ала башлаганнар. Ш. Мәрҗани үзенең дәресләрендә үзе белгәнчә, искедән булганы кебек укыта иде. Ләкин әлеге мөселманча белмәгән

шәкертләр аның дәресләрен аңламыйча йөреп кенә башлаганнар. Школаның инспекторы бу эшкә разый булмаган. Бу түбән дәрәҗәдәге надан шәкертләр файдаланырлык рәвештә сабак укытуны теләгән. Шулай итеп ике арада аңлашылмаучанлык килеп чыккан. Ш. Мәрҗанинең картлыгына да сылтау итеп, школадан аерылуны сораганнар. 1884 елында Ш. Мәрҗани бу эшеннән аерылган. Аерылганда үз урынына Казаклар авылы имамы Борһанетдин мулланы куярга теләсә дә, аны алмыйча, школа башкаручысның якыннарыннан һәм аның сүзеннән чыкмаслык булган Таип әфәндене алганнар. Бу дин өйрәтүче озын заманнар бу школада калган, ди.

## Ш. Мәрҗанинең хаҗга китүе

Ш. Мәрҗани 1880 дә, хаҗга барырга хәзерләнеп, васыятнамәсен язган һәм үзенең эш күргән урыннарына төрле урынбасарлар билгеләгән. Үзе белән әсәрләреннән берничә китап алып юлга чыккан. Янына 1400 сум акча алып, 1880нең 23 августында (яңача — 5 сентябрь) Казаннан кузгалып, иң элек Мәкәрҗә-Нижнийга барган. Ярминкә вакыты икән. Андагы аны таныган сатучылар үзара 300 тәңкә акча җыйнап, изге юл юлчылыгы өчен Ш. Мәрҗанигә бүләк иткәннәр. Аннан соң юлы Мәскәү, Курск, Киев аша тимер юлы белән Одессага юнәлгән. Истанбулда 12 көн калып, бөтен зур мәчетләрне йөреп кергән. Казанлылар Тәккәсенә барып караган. Кайбер китап йортларына кереп, укырга тиешле буяган әсәрләрне укып, кирәкле китапларны да язып алган. Баязит китап йортына үз әсәрләреннән берничәсен бүләк иткән.

Төрек олугларыннан берничәсе белән күрешеп танышкан. Шәйхелислам Әсгать әфәнде Ш. Мәрҗанине бик яраткан. «Әгәр берничә көн Истанбулда тагын да калсагыз, мин солтан Габделхәмиткә сөйләп, Сезне хөкүмәт уткимәсе белән Җидде каласына хәтле җибәрер идем», — дигән. Мәрҗани, бик рәхмәт укып, моны кабул итмәгән. Гаделия назире Әхмәт Җәүдәт паша белән танышып, бу тарихчы пашага үзенең әсәрләренең кайберләрең бүләк иткән. Ә. Җәүдәт паша да аңа үз әсәрләрен бүләк иткән. Соңра беренче Тәккә шәехләре белән дә танышып, болардан Әс-Сәйт Гаун белән бик сөешкәннәр. Бу шәех аны янына утыртып, байтак гарәпчә сөйләшкәннәр. Ш. Мәрҗанидән «Рисалә» һәм «Назурателхак» атлы әсәрләрен сораган, хаждан кайткач җибәрүен үтенгән. Соңра Ш. Мәрҗанидән: «Сез үзегез татар. Халкыгыз татар, нигә әсәрләрегезне гарәпчә язасыз?» — дип сораган. Мәрҗани дә: «Илебезнең укымышлылары гарәпчәне аңлыйлар. Әсәрләремне башка өлкәләрдәге мөселман укымышлылары да укып аңласыннар дип язамын. Ялгыз үз телебездә язсам, башкалары укып аңламаслар»,— дигән. Теге шәех тә бу җавапны кабул итеп: «Әйе шул, гарәпчә — мөселманнарның уртак теледер», — дигән. Аерылышу вакыты җиткәч: «Бу сөйләшүебезгә туймадым. Хаждаи кайтышлый да бер күрешсәк иде», — дигән. Аерылганда икесе дә бер-берсенең кулларын үпкәннәр. Ш. Мәрҗани: «Бу шәех яныннан бик күңелем йомшап аерылдым; үзенә кайбер әсәрләремне дә бирдем», — дигән.

Солтан Сәлим мәчете имамы Мәсгудидия белән сугыш кимәсенә барып, аны күргәннәр. Меңбашы Гариф Бәк кимәнең һәр ягын күрсәтеп йөреп, һәр

шәкәлтмәсен[72] аңлатып биргән, каhвә[73] эчергән. Кимәдән аерылганда чәриләргә: «Сәлам тор»,— дип команда биргән. Саф-саф тезелгән чирүләр[74] мылтыкларын бераз күтәреп, гәүдәләре турысында тотып хөрмәт күрсәткәннәр. Шаhанә кайыккәмә белән озаткан.

Ш. Мәрҗани Истанбулда булудан бик киенгән. Истан-булдагы татарлар арасында кунак булып йөреп бик сыйланган. Истанбул белгечләре дә аны бик яратканнар. Атаклы мөдәр-рисләрдән Исмәгыйль Каккый әфәнде аның турысында: «Ш. Мәрҗани миңа зур истәлекләр калдырды. Аның әсәрләреннән hәрвакыт бик файдаланабыз. Ул — бик олуг белгеч hәм hәр нәрсәнең төбенә хәтле тикшерүче. бер зат. Аның әсәрләрендә яңа сүзләр, яңа төшенчәләр-күрәбез», — дип мактаган. Шәех Халис әфәнде дә: «Ш. Мәрҗани хәзрәтләре бик туры сүзле бер белгечтер. Аның теленнән hәм каләменнән утлар чәчелә. Әгәр ул хәзер сау булса иде, ялгыз аны бер күрер өчен Рәчәйгә барыр идем», — дигән.

Ш. Мәрҗани Истанбулдан үткимосенә менеп, Искәндә-риягәчә[73] билет алган. Янындагы юл иптәше — Казан татары Зәйни хаҗи бу уткимәсенең hәр ягын карап йөри икән. Уткимәсендә ашау, эчү билет хакы белән бергә булган. Зәйни хаҗи аш пешкән җирләргә дә кереп, бисмилласыз гына бер тавыкның башын пычак белән чабып өзгәннәрен күргән дә Мәрҗанигә килеп сөйләгән. Бу хәбәргә Ш. Мәрҗанинең бик эче пошкан да иптәшенә: «Сиңа боларны тикшереп йөрергә чуртмы кушты?» — дигән hәм аннан соң анда тавык ите ашамаган.

Бу уткимәсе юлда Измир каласына җомга көне ураган. Калага чыгып, андагы татарларны табып күрешкәннәр, бергәләп, бер мәчеткә барып, җомга намазын кылганнар. Мәчеттә дә Коръән күреп, аны алып бераз укыган. Коръәннең ике җирендә ялгыш күреп, төзәткән. Намаз кылдырган имамны да шулай тәнкыйть иткән: «Хөтбәдә имам кулына таяк тотмады. Намазны «Инна әгътайна»[76] hәм «Колhу Аллаh»[77] белән кылдырды, сөннәтне[78] ташлады. Ихтиати зәhәрне[79] кылмаенча, ул бид-гатьтән[80] котылды. Җомгадан соң Коръән укымады», — дигән. Искәндәриядә дә гарәпләрнең намаз кылуларын яратмаган.

Халык, намазны бетереп, имам белән бергә дога кылмыйча, мәчеттән чыгалар да китәләр икән. Мисырда ике мисырлы дин белгече белән кайбер җирләрне күреп йөргән. Ш. Мәрҗани аларга Мисырның төрле урыннары hәм белгечләре турысында сөйләгән. Мисырлылар аптырашып калганнар. Ш. Мәрҗани Мисырдагы без белмәгән нәрсәләрне белә икән, дигәннәр.

Мәдинәдә бер атна калып, Росулуллаh[81] hәм сәхаб-ларының гүрләренә зиарәт кылганнан соң Шәех Шамилне[82] дә зиарәт иткән. Анда солтан Хәминең Истанбулдан сөргән иске Шәйхелисламнардан Хәсән Фәhми әфәнде белән танышып бик дуслашканнар hәм Мәккәгәчә бергә юлдаш булганнар. Бу зат: «Рәсәйгә яшәгән татарлар арасында нинди зур белгечләр җитешкән!» — дип сөйләп йөргәне кебек, татарлардан бер хаҗи күрсә, hәрвакыт татарларның хәлләрен сораша, кардәшлек күрсәтә икән. Ш. Мәрҗани Мәдинәдә икәндә Шамдан[83] бер хаҗилар төркеме килгән. Мәдинәнең сакчысы паша бу төркемне, кала тышына чыгып, музик белән, туплар атып каршылаган. Мәрҗаниләр дә Мәдинәдән Мәккәгә таба бу төркем белән бергә голга чыкканнар. Төркемне саклаган чәриләр дә бар икән hәр намаз вакытында туплар атыла, төнлә йоклаганда чәриләр сакчы караул торалар икән, ди.

Юлда Зөлхәлиф[84] — Бирәи Гали дигән урында ихрам[85] бәйләдек, ди. Мәдинәдән Мәккәгә 13 көндә барганнар. Мәккәдә дүрт көн хаҗ гыйбадәтләрен кылый, ихрамнаи чыктык, ди. Бик күп урыннарны зиарәт кылганнан соң бер кич Кәгъбәтуллаһның[86] эченә кереп, ике рәкәгать[87] намаз кылу белән бик кинәндем, ди. Мәккәдә 13 көн калып, кайту юлына чыкканнар. Кайтышлый Истанбулда дүрт көн булып, тарих, җәгърафия, физик, математик фәннәрдән китаплар сатып алган.

Соңра уткимәсе белән Одессага килеп, аннан Нижний-гача тимер юл белән, аннан ат һәм чана белән Казанга кайткан. Нижнийдан чыйым-телеграм белән хәбәр биргәнлектән, шәкертләре аны Казанның тышына чыгып каршы алганнар. 1881 ел 2 гыйнвар (яңача 15 гыйнвар)да икенде[88] вакытында Казанга кайту белән, иң элек мәчеткә төшкән. Анда дус-иш, кардәш, ыруг һәм шәкертләре белән кочаклашып күрешкәннән соң икенде намазын кылгач, өенә килеп кергән.

## Ахунлык эшләре

Ш. Мәрҗани заманында муллалар арасында күп ызгы-шуларга сәбәп булган нәрсәләрдән берсе уразага керү һәм гает уку көннәрен билгеләү эше иде. Гаетне төрле җирләрдә төрлечә кылып, 2-3 көн бер-бере артыпча гает укылганы күренә һәм ишетелә иде. Хәтта бер кала, бер авыл эчендәге ике мәхәллә мулласы бер-берсенә ышанмыйча ике көндә гает укыйлар иде. Хәлбүки, динебездә бәйрәм көнне ураза тоту хәрамдыр.

Ш. Мәрҗани ахун булганчы бу мәсьәләләр турында Казан муллалары белән ни хәтле киңәшеп караса да алар белән бер сүзгә килә алмадылар, һәр ел Казан эчендә һәм тирәсендә ураза һәм гает турысында һәр як үзенә күрә бер сүз, зәгыйфь булса да бер дәлил табып, шул башбаштаклык сузылып килә иде. Ш. Мәрҗани ахун булгач, бу болганчылыкны бетерер өчен, ураза һәм гает көннәрен билгеләү эшен ахуннар кулына тапшыруны җәпләшкә күреп, мөфти хәзрәткә язган, мөфти дә моны туры тапкан иде. Шунлыктан Ш. Мәрҗани, ураза вакыты килгәч, Казан муллаларына бер боерык язып таратты:

*«Хөрмәтле имам әфәнделәр,*

*Мөфти хәзрәтнең боерыгы буенча, бөтен имамнарга шуны хәтерләтәм ки, уразага керү һәм гает укуда бар да бер сүздә булсыннар. Искесе кебек, һәркем үзе теләгәнчә кыланып көлкегә калмасыннар. Бу 1873 елда безнеңчә Рамазан аеның башы шәригать буенча чәршәмбе көнедер. Чишәмбе кич Тәравих[89] укып, уразага керәчәкбез. Ишеткәнлегегезгә шул кәгазьгә кул куеп белдерүегезне үтенә-мен.*

*Вәссаләм.*

*Ахун Ш. Мәрҗани.»*

Бу язуга Казан муллаларының бик ачуы килеп, бер арага җыйналалар да, Ш. Мәрҗанинең бу сүзләрен шәригатькә каршы табып, аның сүзе белән йөрмәскә сүз беркетәләр һәм дә Уфадагы шәригать мәхкәмәсенә 12 мулла кул куеп шул рапортны җибәрәләр:

*«Бик хөрмәтле мөфти әфәнде хәзрәтләре,*

*Ахун Ш. Мәрҗаниңең безгә җибәргән боерыгын Сезгә сунабыз. Безгә белдергән чәршәмбе көнне ай күренмәсә, шәригатьчә Шәгъбан[90] аеның башы да билгеле булмаса, Сишәмбе көн кич тәравих намазы кылып, Чәршәмбе көнне*

*уразага кермәячәкбез. Бүген һава аяз, 200ләп кеше бик тырышып, тегәлеп айга карасалар да күрә алмадылар. Шунлыктан без Чәршәмбе көн уразага кермәдек, мулла Мәрҗани нинди дәлилгә таяна безгә бу боерыкыны биргәне, үзеннән соралса иде. Сездән түбәнчелек белән үтенәбез ки, бу ахун Мәрҗани шәригатькә каршы боерыклар биреп, бездән кул куйдырырга көчләмәсә икән.*

*7.11. 20.11. 1873.»*

Шәригать мәхкәмәсе бу рапортны алгач, бу эшне тикшерүне Ш. Мәрҗанине сөймәгән муллалардан ахун Исмәгыйль Кашкарига тапшырган. Ул да янына, Ш. Мәрҗанинең назурә[91] эшләренә каршы җәридә[92] дип, бер китап язган Габдуллаһ мулланы ярдәмче итеп алып, икесе дә Мәрҗанигә дошманча бер караш белән эшне тикшергән булып, Мәрҗанине шәригатькә каршы эш кылуда гаепләп, бер рапорт язып җибәргәннәр. Шул рапорт буенча мөфтилек Ш. Мәрҗанинең указын алып, алты ай буенча имамлыктан тыйган иде. Ләкин бөтен мөселман илләрендә Ш. Мәрҗанинең боерыгына җәп-ләшкә рәвештә уразага керелгәнс аңлашылгач, ялгыш хөкем бирелгәне күренеп, Мәрҗанинең указы кире кайтарылып бирелгән иде.

## Ш. Мәрҗанинең мөфтилеккә язган киңәшләре

Ш. Мәрҗани хәзрәтләре бөтен милли эшләребезнең бик туры бер юлда йөрүен, мәктән һәм мәдрәсәләребезнең низамлы, төзү булуын, мөәзин, мулла, имам хатип һәм мөдәррисләрнең дә белем дәрәҗәләренең үлчәүле, бер-берсенә охшаш булуларын бик тели иде. Ләкин бу милли эшләрне бер юлга кую эше бигрәк тә Уфадагы шәригать мәхкәмәсенең програмлы эш коруына баглы булу сәбәпле, бөтен изге төшенчәләрне барлыкка китерү нияте белән, мөфтилеккә өч төрле теләгән язып белдергән иде. Ул теләкләр шулардыр:

**1. Беренче теләк.** Мөәзин, мулла, имам хатип һәм мөдәррис була алыр өчен шул белемнәрдән имтихан бирүләре кирәк саналса иде: Мөәзин булыр өчен иман китерә белеп, аның мәгънәсен аңлап, чын күңелдән йөреткән сизүе; татарчадан Устуани китабыны[93], гарәпчәдән Тәглйм-мөсаллат[94] дәрәҗә-сендә белекле булуы тиешле күрелсен. Мәхәллә мулласы булыр өчен боларның өстенә Гакаид, Кудури китапларын[95] укып аңлаганнан башка, түзүче Коръән укый белергә тиештер.

Имам хатип һәм мәктәп укытучысы була алыр өчен дә, боларның өстенә, «Мөхтасәрел викайя»[96], Шәрхи Викайя, әхлактан Гайнелгыйлем[97], нәхүдән Әнмүзәҗ[98], Шәхри мулланы укыган булырга тиештер.

Мөдәррис булыр өчен исә, боларның өстенә игътикдана[99] Шәрхи Какаид, мантыйктан Шәмсия, фикъһедәп Хидая[100], Шәрхел Җәмигулкабир[101], Шәрхи Фәрахиа Сираҗия[102], Хөлә-сәтелхисап[103], Тәүзих[104], хәдистән Мишка-телмәсабих[105], тәф-сирдән Бәйзави[106], Мәдарик[107] кебек китаплардан шәкертләргә сабак бирә алсын.

Әгәр мөфтилек шушы програмны кабул иткән булса иде, бөтен татар мәдрәсәләре дә билгеле бер програм белән дәрес укытырга башлап, төзелеп киткән булырлар иде.

**2. Ш. Мәрҗанинең икенче теләге.**

Уразага керү һәм уразадан чыгып гает намазын бөтен Йдел-Уралда бер вакытта ясау, бер мулла бер көндә, икенчесе башка көндә кылу кебек көлке хәлләрдән котылу һәм бигрәк тә чит диндәге халыкларны үзебездән көлдерү башбаштак-лыкларын юк итү өчен белем һәм фәннәрдән файдаланырга тиешбез, дип киңәш бирә иде. Бу сүзләрдән ап-ачык аңлашылган нәрсә шулдыр: астрономия фәненә караганда яңа айның кай вакыт һәм кайсы сәгать вә минутта туганлыгы билгеледер. Шулай булгач, болытлы, томанлы көннәрдә ай күрергә маташулар, яисә, аязда булса, соңгы заманнардагы зәгыйфьләнгән күзләребез белән айны күрмәдек дип яңа ай туганы хәлдә уразага кермичә калулар, яки гает укымаулар бик көлке, хәтта уйларлык хәлләрдәндер. Ислам диненең һәр төрле белемнәргә хөрмәте, ышанычы бардыр. Белем, хикмәт — маэмәннәрнең[108] югалган бер малыдыр; аны кайда күрсә, тапса, үзенә алсын, дигән. Олуг пәйгамбәрләребезнең боерык-ларыннан да белем һәм фәннәргә күрә гамәл кылу, ш күрү тиешлеге күренеп торадыр.

**3. Ш. Мәрҗанинең өченче теләге.**

Коръән, Хәдис һәм башка дин һәм игътикад китапларының бастырылып, мөселман халкыбыз арасында таралуында дини эшләребезнең үзәге саналган Уфадагы шәригать мәхкәмәсенең күз-колак булуы тиешледер, һәр гарәпчә сүзне үзенең дәгъвәсеиә дәлил итеп сөйләшергә гадәтләнгән татар муллалары кайвакыт борынгылар сүзләрене, яисә иске Юнан[109] философларының гарәпчә тәрҗемәләрен хәдис дип ялгыш сөйләүләре мөмкиндер. Мондый ялгыш төшенчә һәм аңлаулар белән уртага чыккан мондый сүзләрнең китап булып язылып чыгуы да шулай ук бик мөмкин булган бер нәрсәдер. Шуның өчен мондый дини әсәрләрнең зур һәм ышанычлы дин белгечләренең карамагында бастырылулары дин һәм игътикадыбызныа сау, сәламәт калуы һәм дәвам итүе өчен соң дәрәҗәдә кирәкледер. Ш. Мәрҗани хәзрәтләре дә мөфтилегебездән шуның баш-карылуын теләгәндер. Ләкин бу теләкләрдән һичберсенә мөф-тилек колак бирмәгән. Шул йөрәктән чыккан милли һәм дини теләкләргә тиешле бәяне бирә алмаган надан мөфтиләр аларны кабул итеп, эшкә ашырмаганнар.

## Ш. Мәрҗани замандашлары, татар дин белгечләренең Мәрҗани белән ызгышулары

Ул вакытта татар олуг дин белгечләренең күбесе Бохарада укып кайткан кешеләр иде. һәркайсы иленә кайткач шул ук Бохара күчергечендә бер мәдрәсә ачып, шәкертләр укытып, халкыбыз арасында белгәннәрен Тәңре ризасы өчен бушлай таратып яталар иде. Халкыбыз да аларга тиешле хөрмәтне күрсәтсә дә, кимчелек кылмау, аларның аягының ултырагы булырга хәзер иделәр.

Бохара кучергечендәге бу мәдрәсәләрнең татар шәкерт-ләренә өйрәткән нәрсәсе исемнәре югарыда бик күп кабатланган төрле гарәпчә китапларда язылган белем һәм сүзләрне нәкъ китаптагыча алып-сату рәвешендә кабатлаудан гыйбарәт иде. Шәкертләр, нәкъ китаптагы сүзләр һәм төшенчәләрне һич үзгәртмичә, бер-берләре белән мөназәрә кылышалар, үзләре-нең һичбер төшенчәсе юк иде. Ягъни шәкерт бер грамофоп плагындан аермасыз бер машина парчасы кебек нәрсә булып әверелә иде. Шәкертләр бу. белемнәрдән файдаланып, үзеннән бер

төшенчә чыгарып сөйләшә алмыйлар иде. Укыган китаплары да басма йортларда басылмаган булу сәбәпле, шәкертләр бөтен сабакларын үзләре язып алып укырга тиешле иделәр. Бу рәвештә уку чын мәгънәсе белән шәкертләрнең бөтен гомерләрен шул иске китапларга бәйләп куя, җанга һичбер нәрсә бирми иде. Өстәдек йөренгән нәрсәләре дә дин, игътикат эшләренә яраган әйберләр — түгел иде.

Бу файдасыз нәрсәләрне бер белем дип уйлаган бу шәкертләр өчен дөнья һәм ахирәте өчен бик кирәкле булган тарих, җәгърафия, табигать белемнәре һәм физик, математик сабакларына бер сабак диеп карамыйлар иде. Иҗазатнамәсе[110] булмаган бер мөдәррис аны укыта алмый иде. Тормыш өчен иң кирәкле бер белем булган «Фикъһе»дән укуны ваксыну кебек аңлыйлар, аны да бик укымыйлар иде. Бу мәдрәсәләрдә укытылган «Фикъһе» китабы да татар муллаларының иң күп ышанган Җәмигәррүмездән[111] гыйбарәт иде. Хәлбуки бу китап кайбер зәгыйфь риваятьләрне дә эченә алган, бик ышанычлы саналмаган әсәрләрдән берседер. Бу китап буенча эш күргән, фәтва биргән муллалар Коръән, Хәдис ничек әйтә икән дип төпченеп тә карамыйча, ул китапның сүзләренә бәйләнеп, дип җөкемнәрен өйрәтә бирәләр иде, Тәфсир, Хәдисләрне асыл дәлил итеп алмаган муллаларның хөкемнәре арасында бер-берсенә капма-каршы килгәннәре дә килеп чыга иде. Хәябүки, шәригатьнең хөкеме кайсы мулла ягыннан бирелсә бирелсен, бер төсле булырга тиештер. Ул вакыттагы муллалар бик эре табигатьле, надан булса да, үзенә карашы бик зур булып, чалма һәм чапанның да бик матурын киеп халык каршысында үз урынын бик югары тота беләләр иде. Һәр авылда, начар булса да бер мәктәп ачып, укытырга да тырышалар иде. Төп максатлары мөселманлыкны саклау, урыслардан мөмкин мәр-тәбә читтәрәк тору, урысча өйрәнеп, урыслар белән аралашудан саклану, урыс мәдәниятеннән качу иде. Шул сәбәпле аларның һәм халкыбызның дөнья барышында, дөнья милләтләренең кайда таба китүендә һичберсенең хәбәрләре юк иде. Татар телендә гәзит, китап җыемнары да булмагач (журналлары. — Ә. К.), милли телебез дә тутыгып ята иде. Мәдрәсәләрнең телләре гарәпчә булганлыктай, аны да чынлап белгән, аңлаган кеше юк иде. Шулай итеп муллалары белән бергә бөтен татар милләтенең төшенчәләре томанлы; ап-ачык, чын булмаган бер нәрсә юк иде. Искеләргә охшарга тырышу, берсенә ышанып аның артыннан ияреп йөрү, аны яклау бик көчле иде. Бөтен халкыбызда булган кебек, муллаларыбыз да остазларыннан ишетмәгән, үзләре укымаган, китапларда күрмәгән яңалыкларга, хәтта иң яхшы төшенчәләргә дә бидгать дип, начарлык дип хөкем бирәләр иде. Шуңа күрә иске өйрәтү, өйрәнү юлларыннан һич тә аерылмыйлар, иске белгәннәреннән башканы теләмиләр, үзләренең булган кимчелекләрен дә күрмиләр, төзәтүне дә уйламыйлар иде.

Ш. Мәрҗани Бохарадан кайткач менә шул төсле муллаларның һәм халыкның эченә килеп керде. Өйрәтү юлларының кимчелекләрен, халык арасына таралган кирәкмәгән нәрсә (бидгать)ләрне, халык арасында яхшы кебек танылган ялгыш игътикатларны үзенең туры күрүе, кискен каләме белән сирпалый (тәнкыйть итә) башлады. Үзенең чын һәм төпле белеме белән тоткан төшенчәсе илдәшләре татарларга, диндәшләре мөселманнарга хезмәт итү иде. Шуның өчен бу эшкә бөтен көче белән сарылды. Кайбер дин белгечләре аны аңласалар да, диннең төп нигезен аңлап җитмәүләреннән, башкаларына ияреп йөрүләр синән,

үзләреннән өскә чыккан берсен күрергә теләмәүләреннән Ш. Мәрҗанинең сүзләренә, эшләренә каршы төштеләр. Үзләреннән югары булганын күргән хәлдә, аның чын, пакь, яхшы ниятләрен дә күз алдында тотмыйча, аннан үзләре файдаланасы җирдә, тискәре бер юл тотып, халыктан артык халыкча булган булып, кара халыкның төшенчәләренә иyргән муллалар, мөдәррисләр һәм байлар белән берләшеп, Ш. Мәрҗанигә каршы кузгалышка күчтеләр, аны танырга теләмәделәр, аның туры сүзләрен киресенчә аңладылар. Юкны бар күрсәтеп, мөселманлыкларын бер якка атып, аны урыс хөкүмәтенә әләкләп, ике тапкыр указын алдырдылар. Икесендә дә ялгышканлыклары, ялганчылыклары мәйданга чыкты. Шулай була торып ни югарысы, ни түбәнгесе бу хаксызлыкларын төшенеп уйламадылар, килеп гафу үтенмә-деләр. Янәдә ана каршылыкта аяк терәделәр. Динне киң күрсәтергә тырышса, игътикади бозык, диделәр. Халыкны аннан нәфрәт иттерергә тырыштылар. Аның туры төшенчәләрен, файдалы юлларын ялгыш һәм зарарлык дип күрсәтер өчен, искелекне яклап яшәтер өчен аңа каршы китаплар, брошюралар язып тараттылар.

Бервакыт Казан муллалары, башта Галләм хәзрәт Ш. Мәрҗанинең игътикатлары турысында Бохара мөфтиләреннән фетвалар сорадылар. Кайбер Казаң муллалары аны шәфигый[113], кайберсе мөгътәзил[114], рәфизи[115], хәтта шигый[116], зиндикъ[117], мөнафыйк[118] вә кафер дә диделәр. Кайбер шәригать хәкемнәрендә Мәрҗани шәфигыйләрнең дәлилләрен көчлерәк күреп, аның белән эш күрүне тулырак тапкан. Шуңа күрә Шафигый дигәннәр. Мәгътәзилләрдән булган олуг белгеч Зимәһшәринең «Тәфсире Кәшшаф»ны[119] мактаганы һәм аны дәлил итеп күрсәткәне өчен Мөгътәзили диделәр. Ш. Мәрҗани Мөгътәзиле һәм Рафизиләрне мөселман дип таныйдыр. Дин эшендә бик ашыгып башкаларга кяферлек пичәтен басуны сөймәгәнгә, аңа шигый, рафизи, зиндикъ дип хөкем иттеләр.

Казан һәм башка як мулларының Ш. Мәрҗанине сирпалауларының сәбәбе күбрәк шул өч төрдә җыйнала иде:

1. Ш. Мәрҗани — Коръән һәм Хәдис белән күп шөгыль-ләнгән һәм иске мөселманнарның, пәйгамбәребез заманында беренче, икенче йөз еллардагы асыл мөселманнарның мәзһәпләре[120] игътикатлары, гыйбадтәләре ничек булганын бик нык тикшергән олуг бер белгечтер. Соңгы заманнарда күргәннәрен шул искедәге чын мөселманлык белән чагыштырып караганнан соң, соңгы вакытларда байтак игътикат һәм фикъһе мәсьәләрендә пәйгамбәребез вакытындагы юлдан аерылып, шул ук мөселманнарның күп сөннәтләрне бидгать, күп бид-гатьләрпе дә сөннәт ясап куйганлыкларын күргән. Соң за-маннарда ислам китапларына шәригатькә каршы булган байтак нәрсәләрнең кергәнлеген аңлаган. Шуңа күрә, әгәр Ш. Мәржа-нидән берсе бер шәригать мәсьәләсе сораса, ул иң элек Коръәннән, Хәдистән дәлил эзли иде. Теге башка муллалар әлеге Җәмигуррузмузда язылган белән канәгатьләнеп, күп тик-шереп тормыйча фәтвасын сөйләп җибәрә иде. Ш. Мәр-җанинең тоткан юлы шәригатьнең, мөселманлыкның нигезенә таяну иде. Шунлыктан Ш. Мәрҗанинец биргән хөкемнәре кайвакыт теге муллаларның биргән хөкемнәренә каршы булып чыга һәм тагын да турырак булганлыгы беленә иде. Бу йөздәй Ш. Мәрҗани белән башка муллаларның арасы бозылып китә иде.

2. Ш. Мәрҗани үз вакытындагы уку, укыту эшләренең заманга җәпләшкә булмаганын күрә, моны төзәтергә тели иде. Мәдрәсәләребезгә күп яңа фәннәрне кертергә, булганнарын арттырырга уйлый, бик күп фәннәрне шәригатьчә дә кирәк таба иде. Европада булган фән һом һөнәрләрне татарларның да белүе тиеш дип төшенә иде. Рәсәйдә яшәгән бар халык өчен урысча белү кирәк — важии, ди иде! Татарларны тизрәк алга таба җибәрер өчен ислам динен яхшы белгән, урысчаны да өйрәнгән муллалар җитештерергә тиешлебез, дип уйлый иде. Үзе дә урысчаны яхшы аңлый, профессор Казембек, атаклы Көчыгыш белгечләреннән В. В. Радлов, Готвальдлар ш белән күрешә, аңлаша иде. Иске әсәрләр җәмгыятендә[122] алар белән бергә эшли торган бер мучә иде. Ш. Мәрҗанинең бу затлар белән күрешеп йөрешүен теге муллалар бер дә яхшы күрмиләр, урысча кирәкле дип белүне, урыслар белән бер җәмгыятьтә эш күрүне аның бозык төшенчәле, дине зәгыйфь булганлыктан кilә дип уйлыйлар иде. Бөтен боларның өстенә Бохарапың дин мәдрәсәләрен сирпалап, аларны кимсетүе кара халыкның бер дә хушына китми, надан муллаларның нәфрәтен кузгата иде. Шунлыктан бу муллалар һәм кара халык Ш. Мәрҗанинең бөтен төшенчәләренә каршы иделәр.

3. Ш. Мәрҗанинең халык арасында танылган һәм укыган кайбер китапларын һәм халкының хөрмәт иткән кайбер муллаларын бер дә хәтер[123] санамыйча, төртеп тишкәндәй кату сирпалавы (тәнкыйде) аңа бик күп кешеләрне дошман итә иде. Чыннан торып Ш. Мәрҗани үзе туры дип белгәненнән кыл хәтле аерылмаган, туры төшенчәләрендә бик каты торган, ачык сүзле, башкаларга охшамаса да, туры юлыннан аерылмаган, күпче-леккә каршы булса да, кире дөнмәгән, үзсүзле бер кеше иде. Бик күн халык аңа: зур остазларга тел озайта; үзеннән башкаларны сана санамый; башкаларның төшенчәләрен хөрмәт итми; үзен данлыклы итәргә тырышкан бик һавалы бер адәм дип карыйлар иде. Бу турыда Ш. Мәрҗанинең дуслары да шулайрак төшенеп, әгәр Мәрҗани бераз түбәнчелек белән үзеннән яшьлерәк, карт остазларга көләч йөз белән якынлаша алган булса, бик туп-туры китмичә, бераз юлданрак йөреп сәясәт күрсәтә алса, күп муллаларны үзенә тизрәк йөрткән булыр иде, диләр икән.

Рихлате Мәрҗани. Казан, 1998.

## Искәрмәләр

[1] Рәкәяать — намазның аягүрә тору, иелү башны җиргә куюны алган өлеше.

[2] Әһле сөннәт вә эл-җәмәгате мәзһәб — иманлы кешеләр вә җәмәгать юлы, сөннәт әһелләр (дини кагыйдәләрне үтәүчеләр) һәм дин юлындагы кешеләр.

[3] «Гакаиде нәфисә» — китап исеме.

[4] «Тәбара» — сүрә исеме.

[5] «Тәһзип» (Тәһзиб) — китап исеме, «Төзәтү» мәгънәсендә.

[6] «Әлхамдүл илляһ» (Әлхәмдү лилләһи) — Аллага мактау, дан мәгънәсендә.

[7] «Һамд баһси» — «Хәмед (Хамид)» бәхәсе1.

[8] «Әлләзи һәдана» — ?

[9] «Һидаят баһси» — дөрес юл эзләү бәхәсе.

[10] «Фәһаза гайете мантикый вә эл кәләм» — Мантыйк вә бәхәс гыйлеме.

[11] «Ишарар баһси» — читләп әйтү юлы белон бәхәс.

[12] «Мишкатүл» (мишкятүл) — китап исеме: «Яктырткычлар тота торган урыннар».

[13] «Бәйзави» — китап исеме.

[14] «Фикъһе» — Ислам дине мәсьәләләре буенча гыйлем, ислам юриспруденциясе.

[15] Мәзһәп (мәзһәб) — дини юнәлеш.

[16] Иттимат (Игътимад)2 — таяну, ышану.

[17] «Тәһзибүл мантыйк вәлкаләм» (Тәһзибүл мантыйк вәл-кәләм) — логика һәм сүз көче белән төзәтү, тәрбияләү.

[18] Итикат (игътикат) — саклык күрсәтү.

[19] Мөтәгаллимин — өйрәнгән, укыган.

[20] Тафтазани — Сәгъдуддин Мәсгәд ибн Гомәр ат-Тафтазани (1322-1389) — гарәп философы, юристы, Идел-Болгар илендә вә Алтын Урда да булган.

[21] Фәхреттин Рази — Әр-Рази Фәзретдин Габдуллаһ бин Мөхәммәд (1149-1209) — күренекле ислам философы.

[22] «Мөкабәлә» — ике әйберне чагыштыру, каршы тору.

[23] «Һәйәт».— биредә «Күк җисемнәре хәрәкәте турындагы гыйлем» мәгънәсендә.

[24] Гакъли — акылга, логикага бәйләнешле.

[25] Нәкъли — күчерелмә, ишетеп сөйләү.

[26] «Имам Газали» — Аль Газали Әбү Хәмид Мөхәммәд (1058 яки 1059-1111), күренекле мөселман философы, дин белгече.

[27] «Гыйлем каләм» (Гыйльме каләм) — китап исеме.

[28] «Тәнбиһи әбнаүәлгасир битәнзиһи әнбау Әбуннасыйр» — Курсавины яклап язылган әсәр, гарәп телендә.

[29] Ибн Фадланның «Рисалә»се — Ибн Фазлан Әхмәд — Багдад хәлифе Мөктадар (Мөктадир)ның Бөек Болгар иленә җибәрелгән илчелегенең секретаре; 921-922 елларда биредә булуы турында «Риса-лә» язып калдырган.

[30] Һиҗаз — (Һиҗас, Хиҗас) — Согуд Гарәбстанындагы шәһәр һәм өлкә исеме.

[31] Һәндәсә — геометрия.

[32] Иҗазатнамә — рөхсәт язуы.

[33] Ригаять — игътибар итү, илтифат.

[34] Рия (Рыя) — икейөзле.

[36] Нифак — ялган, икейөзлелек.

[36] Моназәрэ — бәхәс.

[37] Хашия — китап читләренә язылган искәрмәләр.

[38] Изен — рөхсәт, ризалык.

[39] Тәфсир — аңлатып сөйләү.

[40] Иттикады (Игътикад) — кара: № 18.

[41] Радлов — Радлов В. В. (Фридрих Вилъям) — 1837-1918 Россиядә эшләгән күренекле немец галиме, татар мәгърифәте и фольклористикасы буенча хезмәтләр күрсәткән галим.

[42] Бу әсәр «Мөстәфадел әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» исеме белән дә билгеле.

[43] Бу әсәр «Гөффәт ол-хәваким лигарһәт ал-хавакин» исеме белән дә билгеле. 1864 елда Казанда басыла.

[44] Жилдд — том, кисәк.

[45] Сәхап (Сахаб) — Мөхәммәд пәйгамбәрнең яраннары.

[46] Низам (Низамнамә) — кабул ителгән тәртип кагыйдәләре.

[47] Мөхәммәд пәйгамбәрнең сүзләре.

[48] «Хикмәте кадимә» — китап исеме, «Борынгылар фәлсәфәсе».

[49] Сәйяра — планеталар.

[50] «Мөкаддимә» — сүз авторның «Мөкаддимәте китабе вафиятел-әслаф вә тәхийател әхлаф» турында.

[51-52] «Тәфсир» буенча мәдрәсәләрдә төрле әсәрләр өйрәтелгән. Биредә сүз шул китапларның исемнәре турында бара: «Казый Бәйзави» тәфсире, «Мәдарик» тәфсире, «Кәшшаф» тәфсире.

[54-55] Хәдис буенча да төрле әсәрләр булган. «Саһиһе (Сахихе) Бохари», «Мишкатүл (Мишкятүл) мәсабих»та шул сериядән.

[56] Бәлагат (Балагат) — үсеп җитешү, сүздә матур сөйләү.

[57] «Тәлһис» — бәлагат буенча дәрес китабы.

[58] «Сәяри Нәби» (Сәйяре Нәби) — пәйгамбәрнең тормышы.

[59] Казембек — Казембек Александр Касимович (1802-1870) — Казан университеты профессоры, азәрбайҗанлы.

[60] «Мифтаху гәнеҗел Корьән» (Мифтахе гәнҗел-Корьән — Корьән хәзинәләренә ачкыч. Корьәндә сүзләр, фактларга күрсәткеч. Бу хезмәтне А. К. Казембек Петербург университетында эшләгән вакытта башкара, ләкин ул бу хезмәтне хәзерләгәндә Х. Фәезхановның зур хезмәтең атлап кына, әйтми генә диярлек узып китә.

[61] Фуад Туктар — Фуад Туктаров (1882-1943) — күренекле татар сәяси эшлеклесе, публицист педагог, журналист.

[62] «Кодури» — фикъһе буенча бер әсәр исеме.

[63] «Гакаиде Тзһави» — игътикаттан уку китабы исеме.

[64] «Мөхтасар Хисами» — фикъһедән уку китабы исеме.

[65] Фәраиз — мирасы бүлү кагыйдәләре.

[66] Һаруннуррәшид — Һарун әр-Рәшид (763 яки 766-809) — Габбасилар династиясе хәлифәләреннән.

[67] Әлмаэмүн (Әл-Маэмүн) — хәлифә исеме.

[68] «Җәбер» — алгебра.

[69] «Мукабәлә» (Мөкабәлә) — ике әйберне чагыштырып өйрәнү.

[70] Фәлаеат — исе китми, игътибарсыз.

[71] «Игътикад» — кара: №18.

[72] Шәкәлтмәсе — һәр кисәге.

[73] Каһвә — кофе.

[74] Чирү (Чәри) — гаскәри, солдат.

[75] Искәндәрия — Мисырның Урта диңгез буендагы портлы шәһәре. Мәрҗани биредә Мисыр галимнәре белән очрашуын яза, ләкин үзенең китапларын анда кемгә булса да бүләк итүе турында аскә алмый. Безнең милләттәшебез, Искәндәрия консерваториясендә музыка укытучы, Искәндәрия университетында

төрек телләре укытучы, филология фәннәре докторы Рәшидә ханым Рәхим әл-Сабрути Искәндәрия университеты китапханәсендә Ш. Мәрҗани китаплары саклануын сөйләде. Миңа калса, Ш. Мәрҗани аларны Искәндәрнядә вакытта бүләк иткән булса кирәк.

[76] «Иннә әгътайна» — Коръән аятеннән.

[77] «Колһу Аллаһ» (Кул һүә Аллаһу) — Коръәннең «Ихлас» сүрәсе.

[78] Сөннәт — гадәти, гадәткә кергән.

[79] Ихгияги зәһәр — тиешле саклык.

[80] Бидгать — ярамый торган гамәл, яңа эш.

[81] Рәсүлуллаһ — Мөхәммәд пәйгамбәр.

[82] Шаех Шамил — Дагстан, Төньяк Кавказ халыкларының урыс басып алучыларына каршы алып барган азатлык өчен сугышның бөек полководецы Шамил (1797-1871). Вафаты — Мәдинәдә.

[83] Шам — Сүриянең борынгы исеме.

[84] Зөлхәләф — шул исемдәге хәлиф исеменә бәйле урын.

[85] Ихрам — хаҗилар өстенә кия торган япма.

[86] «Кәгъбатулла» — Алла йорты, Кәгъбә ташы куелган корыша.

[87] Рәкәгать — кара: №1

[88] Икенде — көн кичкә авышканнан башлап кояш тәмам батканчы

[89] «Тәравих» — уразада кич укыла торган намаз.

[90] Шәгъбан — Ай елы циклында сигезенче ай исеме.

[91] Назүрә — телескоп.

[92] Жәридә — гәзит, досье мәгънәсендә.

[93] «Устуани китабы» (Өстуани китабы) — Дамаск шәһәрендә яшәгән Мөхәммәд Өстуани (1607-1662) язган әсәр, татарлар арасында популяр китап.

[94] Тәгълиммөсаллат — зур белемле, белем өйрәтүче.

[95] «Гакаид», «Кодури» — китаплар исеме.

[96] «Мөхтасарел викая» (Мөхтасар әл-викая) — мөселман кануннары буенча кыскартылган курс. 1845 елда Казанда А. К. Казембек редакциясендә аерым басма булып дөнья күрә.

[97] «Гайнел гыйлем» (Гайнел гыйлем) — «Белем чишмәсе» исемле дин китабы.

[98] «Әнмүзәщ» — китап исеме грамматика буенча әсәр.

[99] «Игътикад» — кара: №18.

[100-107] Игътикад буенча уку өчен «Шәхри (шәрхе) гакаид», мантыйк буенча «Шәмсия», «Шәрхи Фәразаи Сираҗия», «Хөлосәтел хисап», «Тәүзих», хәдис буенча «Мишкател-әл хисап» «Мишкател-хисап»), тәфсир буенча «Бәйзави», «Мәдарик» исемле китаплар исемнәре.

[108] Маэман — куркынычсыз, кирәкле.

[109] Юнан — борынгы греклар,

[110] Иҗазатнамә — рөхсәт язуы.

[111] «Җәмигәррүмез» (Җәмигы-р-ромуз) — «Символлар тупланмасы» — Мөселман юриспруденциясе буенча Шәмсетдин Мөхәммәд Хөрасани (үлә — 1556) төзегән китап.

[112] Фәтва — нинди дә булса бер эшне эшләү дини яктан дөресме-түгелме икәнне күрсәтеп бирү.

[113] Шәфигый — Ислам динендә имам Шәфигь мәзһәбенә иярүче. Мәгътәзил (Мәгътюзил) — Урта гасыр ислам дине галиме.

[115] Рафизи — Уртә. гасыр ислам дине галиме Рафиз мәзһәбенә иярүче.

[116] Шигый — дүртенче хәлифә Гали һәм аның балаларының тарафдарлары. Ислам динеңдәге ике төрле юнәлешнең берсе.

[117] Зиндикъ (Зиндык) — Аллага ышанучы, динсез.

[118] Мөнафыйк — каршы, бе.р-берсенә охшамый.

[119] Зимәһшәри — «Тәфсире Кәшшаф» — Әз-Зимәһшәри Мәхмүд бин Гомәр Абул Касыйм (1075-1114) — дин белгече, филолог, аның бер әсәренең исеме. — Киор ара: № 51-53.

[120] Мәзһәп (Мәзһәб) — дини юнәлеш.

[121] Готвальд — Готвальд Йосыф Федорович (1813-1897) — Казан университетында эшләгән немец иалиме, шәрекъ белгече, татар китабы цензоры, университет типографиясе директоры.

[122] Иске әсәрләр э/дәмгыяте — Казан университеты каршында ачылган Археология, этнография пә тарих җәмгыяте.

[123] Хәтер санамыйча — хәтер сакламыйча.

## Сулейман Бакыргани
## (XI век – 1186)
## «Этот бренный мир»

Как это было принято у мусульман вплоть до начала XX века, известен лишь год ухода из жизни (1186) Сулеймана Бакыргани — составителя одной из популярнейших в средневековом (и не только) тюркоязычном исламском мире рукописных книг уроженца одноимённого кишлака под Бухарой. Так она и называлась — «Бакырган китабы» («Книга Бакыргана о конце света»). Второе прозвище автора — «Хаким ата», т.е. учёный, уважаемый человек. Причину долгой жизни книги видят, во-первых, в высоком поэтическом совершенстве стихов самого автора и других включённых в книгу поэтов. Вторая причина, на наш взгляд, в том, что, пропагандируя идеи ислама, он постоянно сопоставляет (вернее, противопоставляет) суету быстротечной жизни с её хлопотами и заботами необходимости следовать праведной жизни и неотвратимости наказания. А эта сквозная идея непосредственно связана с эсхатологией — мыслью в конце света — одной из сквозных тем Корана, хадисов — наказания за отступление от канонов веры. Таков финал каждого повествования о пророках. Такая перекличка, на наш взгляд, и стала причиной чрезвычайной популярности творчества Бакыргани. А стихотворная форма с, как уже сказано, повторяющимся рефреном — призывом к пробуждению, требование бессонницы — как бы микшируют, сглаживают идею обречённости и, по мнению ряда специалистов, вопреки общей идее пассивности приводят к утверждению противоположной идеи активности. Не случайно ко времени появления печатной национальной

книги — в конце XIX века и в периоды повышения активности масс — потребность в «Бакырган китабы» резко возрастает. Известно, что имеется 26 изданий. И лишь с появлением антиутопии, с присущим ей острым социальным содержанием и сатирическим изображением потустороннего мира, популярность «Бакырган китабы» несколько ослабевает.

Бу дөньядин кем кичкәй,
Арада гыйшк булмаса?
Оҗмах капугын кем ачкай,
Арада гыйшк булмаса?

Рухыңы гыйза алмас,
Җаның мәза булмаса,
Көбәр вә нифак арынмас,
Арада гыйшк булмаса.

Дөньяны тәрк кылыбан,
Гыйз вә җиһанны салыбән,
Кем терелгәй үлебән,
Арада гыйшк булмаса.

Дар вә дәрман булынмас,
Үзе утдин йолынмас,
Фәсад эшдин арылмас,
Арада гыйшк булмаса.

Тәкъва берлә төрелмәс,
Заһид үзен карылмас,
Көфер вә иман беленмәс,
Арада гыйшк булмаса.

Суфи сумгадин чыкар,
Габид мәсҗедне егар,
Мөнбәрне утка якар,
Арада гыйшк булмаса.

Мең ел гыйбадәт кылсаң,
Тагать эчендә калсаң,
Мохалдер Хакны белсәң,
Арада гыйшк булмаса.

Тәсбихың зоннар булыр,
Сәҗадең мордар булыр,
Барчасы агйар булыр,
Арада гыйшк булмаса.

Адәм килмәгән ирде,
Мәрсәл тугмагай ирде,
Рәхмәт иңмәгәй ирде,
Арада гыйшк булмаса.

Наданнарның нишаны,
Белмәсләр гыйшк нишаны,
Корылмас, дин дигәне,
Арада гыйшк нишаны булмаса.

Гыйшк ачар эч күзеңне,
Хәким, аңла сүзеңне,
Тигермәссең үзеңне,
Арада гыйшк булмаса.

XII-XIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре.
(Текстны Ф. Яхин әзерләде). Казан, 2000.

## Ахмад Ясави
## (конец XI век — 1116)
## «Скажу, Аллах»

Уроженец поселения Яса, ставшего его тахаллусом — псевдонимом, выдающийся поэт-суфий, певец Всевышнего в мире тюркских поэтов, жил и творил в городе Бухара, а затем Туркестане, где он и был похоронен. Его могила стала местом поклонения. Его хикметы — краткие стихотворения, по пафосу совпавшие с эсхатологическими мотивами «Книги пророков» — «Кисса-аль-анбия», получили широкое распространение в огромном ареале и оказали мощное влияние на творчество татарских и башкирских поэтов суфийской ориентации М. Кулыя, Х. Салихова, Ш. Заки… Книга Ясави, включающая около 150 хикметов, многократно издаётся в последнюю четверть XIX века. Основной пафос его творчества — идея бренности окружающего мира и необходимость преклонения перед Аллахом.

### Литература

Антология татарской поэзии. Кн. 1. Казань, 1992.
*Яхин, Ф.* Литература средних веков. Казань, 2003.

1. Тапмаен, хәзрәтендә: «Аллаһ!» — дисәм,
Зар иңрәп, закир булып: «Раббы!» — дисәм
Кол булып, коллыкында буен сынсам,
Бу эш берлә, йа Раб, сәңе тапкаймы мин?

2. Зәкәрия[1] тик бу башымга әрри куйсам,

Әйүп[2] тик бу тәнемгә кортны куйсам,
Муса кеби Тур тагыда тагать кылсам,
Бу эш илә, йа Раб, сәне тапкаймы мин?

3. Юныс[3] дик дәрья эчрә балык булсам,
Йосыф[4] дик кодык эчрә төн-көн калсам,
Ягъкуб[5] дик Йосыф өчен зар иңрәсәм,
Бу эш илә, йа Раб, сәне тапкаймы мин?

4. Шәбләй[6] дик сәмаг гашыйк булып орсам,
Байазит[7] дик төн-көн тынмай Кәгъбә барсам
Кәгъбәгә йөзем сөртеп, зар иңрәсәм,
Бу эш илә, йа Раб, сәне тапкаймы мин?

5. Мәгъруф[8] дик ошбу юлга кадәм куйсам,
Мансур[9] дик җандин кичеп, дарда кунсам
Дар үзерә сокланып Хакны әйтсәм,
Бу эш илә, йа Раб, сәне тапкаймы мин?

6. Кол сәр Әхмәт, коллык эчрә забит улсам,
Зикер әйтеп, закир булып, Раббы, дисәм,
Зикередә шәвкъланып-көеп янсам,
Бу эш берлә, йа Раб, сәне тапкаймы мин?

**Аңлатмалар**

[1] Зәкәрия пәйгамбәр. — Кяферләрдән качып барганда агач эченә яшерелә. Аны шунда килеш пычкы белән кисеп үтерәләр.

[2] Әйүп пәйгамбәр. — Тәнен кортлар тере хәлендә ашыйлар. Шул газапларга түзә. Хәтта тәнен ашаучы бер корт егылып төшкәч, аны яңадан тәненә куя. Библиядә ИОВ.

[3] Юныс пәйгамбәр, балык эчендә яшәве турында сөйләнә.

[4] Йосыф пәйгамбәрне абыйлары үтерер өчен, коега ташлыйлар.

[5] Ягъкуб пәйгамбәр, Йосыфның әтисе. Абыйлары аны сатып җибәргәч, елый-елый сукырая.

[6] Шәбләй — Багдадта яшәгән чиновник, соңыннан суфый.

[7] Баязит — суфый, олуг фикер иясе. Үзен алла белән тиңли дип яла ягып, күп газаплар кичергән.

[8] Мәгъруф — Баязит Бисталиның укучысы һәм мөриде.

[9] Мансур — суфый шагыйрь 921 елда, үзен алла белән тиңләүдә гаепләп, һәлак ителә.

Бакырган китабы: XII-XVIII йөз төрки-татар
шагыйрьләре әсәрләре. Казан, 2000.

**Кол Шариф**
**(? — 1552)**
**Хвала ему одному**

Видный представитель мусульманского духовенства, государственный деятель Казанского ханства, поэт. После кончины отца Мансура в знак признания ума, знаний в 1546 году избран главным имамом Казани. В русских летописях упоминается как опытный и мудрый дипломат; ряд писем и посланий Ивана Грозного направлены на его имя. Погиб 2 октября 1552 года, сражаясь вместе с соратниками — муллами и шакирдами на стенах Казани.

Как поэт суфийского толка считал своими учителями Ясави и Бакыргани.

1. Башың күтәр гафләтдин,
Гафил торма, «һу!» — тигел,
Күзен, ачкыл ойкыдин,
Гафил торма, «һу!» — тигел.

2. «Һу-һу!» — тию һу кошы,
Акар күзендин! яше,
Көеп эче һәм ташы,
Гафил торма, «һу!» — тигел.

3. Гашыйклары очарлар,
Гарш шахыга кунарлар.
«Һу-һу!» — диеп дидарлар,
Гафил торма, «һу!» тигел.

4. Йите икълим гизәрләр,
Андин күккә агарлар,
Бер кадәмдә ятарлар,
Гафил торма, «һу!» тигел.

5. «Һу!» бәхрегә чумарлар,
Гаувәс булып батарлар,
«Һу!» дирләрен дин тирләр,
Гафил йөрмә, «һу!» тигел.

6. Дәргәһ-капуг ачыктыр,
Рәхмәтләре аныктыр,
Күзең ачып, бакып күр,
Гафил йөрмә, «һу!» тигел.

7. И Колшәриф, тынмагыл,
Төннәр ятып оймагыл,
Хак зикрене куймагыл,
Гафил йөрмә, «һу!» тигел.

*Гафләтдин* — наданлыктан; *ойкыдин* — йокыдан; *тигел* — дип әйт*; гарш шахыга* — гарше ботагына; *ташы* — тышы.

Бакырган китабы. XII-XVIII йөз төрки-татар шагыйрьләре әсәрләре. Казан, 2000.

## Кол Гали
## (вторая половина XII — начало XIII вв.)
## «Кисса-и-Юсуф. Сказание о Юсуфе и Зулейхе»
## Пролог и эпилог

Автор выдающегося памятника тюркоязычной литературы Средневековья — поэмы «Кисса-и-Юсуф», ставшего фундаментом светского искусства слова народов тюркской группы. И неудивительно, что многие исследователи тюркоязычных литератур связывают его жизненный путь и творчество с историей слова своего народа.

Существуют разной убедительности версии о его происхождении (из рода айле на северо-востоке нынешней Башкирии; из состоятельной семьи недалеко от города Булгар; основываясь на том, что значительную часть жизни (более 45 лет) он провёл в Хорезме, его считают своим узбеки и таджики. Одним словом, жизнь и творчество Кол Гали — источник, который становится тем чище и прозрачнее, чем больше выбирают из него воду). Поэма «Кисса-и-Юсуф», опирающаяся в своей сюжетной основе на ближайший к нам источник — суру из «Корана» (соответствующие легенды имеются также в Библии, Евангелии и, как пишут специалисты, в древнейших текстах Вавилона), выдвинула её автора в ряд с выдающимися представителями мирового искусства слова. Он не только адаптировал кораническую фабулу к местным условиям и эпохе, в которую жил, но пронизал её присущими гуманистическим идеям ислама идеалами милосердия, добра, устройства жизни на разумных началах. Эти особенности нашли программное выражение во вступительной и заключительной частях поэмы, не говоря уже о её содержании. Сохранилось 150 списков произведения, получившего самое их широкое распространение на Урало-Поволжье как сказание о Юсуфе и Зулейхе.

### Литература


Древняя татарская литература. Казань, 1963.

*Гарей, Ю.* Где написана поэма «Юсуф и Зулейха»? // Агидель, 1981, № 1.

*Харисов, А.* Литературное наследие башкирского народа. Уфа, 1965; 2005.

*Хисамов, Н.* «Киса-и-Юсуф» Кул Гали. Анализ источников сюжета и авторского творчества. М.: Наука, 1979.


### Бисмиллаһир-рәхманир-рәхим
### КЕРЕШ

Мактаулар һәм күп шөкерләр Берденбергә,
Милке даим һәм мәңгелек бер тәңрегә,
Мөлкәтендә тиңдәше юк ул тәңрегә, —
Аны мәңге үлемсез дип белдек инде.

Аңардан соң аның дусты Мөхәммәдкә,
Нәбиләрнең[1] иң олугы ул Әхмәдкә[2],
Ике уклык урыны бар[3] ул Әхмәдкә,
Аңа бик күп сәлам-хөрмәт булсын инде.

Аңардан соң гъәр иясе Сиддикъ[4] бар ич,
Мостафага[5] гъәр эчендә булды ул иш,
Иш булуны үзенә гарь күрмәде һич,
Тугрылыгы һәркемнән дә артык инде.

Аңардан соң дәхи Гомәр Хәттаб угълы,
Бар галәмгә мәшһүр иде аның гъәдле[6],
Йөз мең ирдән артык иде аның фәзлы[7] —
Дүрт мең дүрт йөз мөчет бина кылган инде.

Аңардан соң изге Госман шәһиди бар,
Коръәнендә аны телгә алды Җәббар[8],
Зур төгәллек бүләк иткән аңа Гаффар[9] —
Тулы Коръән хатасызын төзгән инде.

Аннан Гали куркусызга мактау кирәк —
Йөз меңнәрчә гаскәрдән дә гайрәтлерәк.
Һич кылыч юк Зөлфекардән үткенерәк,
Галидән дә батыррак зат һич юк инде.

Аның үзәк өзгәннәре ике егет,
Дин юлында көрәшүче, канын түгеп,
Берсе — Хәсән, берсе — Хөсәен — ике шәһид,
Алар яшьли җөннәт әһле булган инде.

Аннан соңра ул дүрт тугры хәлифәгә,
Ул табигыйн[10] голәма һәм шәһидләргә,
Диндә булган бар әүлия шәхесләргә —
Барчасыннан тәңре разый булсын инде.

Аннан соңра ул бәхетле ирәннәргә,
Хакъның сөйгән Мостафасын күргәннәргә,
Киметүсез утыз өч мең ирәннәргә —
Барчасын да остаз диеп белик инде.

Аннан соңра бер ир чыкты — гыйлем тавы,
Аның белән күркәмләнде ислам даны,
Ачык, төгәл беләсезме икән аны —
Сабит угълы Ногман[11] диләр аңа инде.

Аннан соңра дин башлыгы булганнарга,
Иманга — көч, исламга — нур булганнарга,
Хакътан даим рәхмәт яусын һәм аларга,
Күп меңнәрчә афәриннәр булсын инде.

Рәхимле ул илаһыма сыенмыйммы,
Башым иеп, ярлыкавын сорамыйммы,
Бөегемнән ярдәм-дуслык теләмимме —
Максатларга ирештерә тик ул инде.

Мин бер зәгыйфь сиңа сыенам, изге иям,
Мин — йончыган синнән ярдәм өмет итәм,
Хәтеремне якты ит син, юмарт иям,
Кодрәтең киң — син бир яхшы зиһен инде.

Синнән ярдәм өмет итәм мин зәгыйфь кол,
Сине дәлил итүчеләр таба төз юл,
Әгәр ярдәм бирим дисәң — кодрәтең мул,
Бу бәндәңә дәлилем бул үзең инде.

Мин зәгыйфьне син хикмәткә таба яндыр,
Гыйбрәт-хикмәт сөйләттереп син куандыр,
Күкрәгемдә ярдәмеңнең шәмен яндыр,
Хәтеремне якты нурга балкыт инде.

Күңелемә фикер-зиһен яктысы бир,
Кодрәтеңнән миңа хикмәт балкышы бир,
Мин зәгыйфькә көчле илһам уңышы бир,
Кодрәтең бар, һәр әйткәнең була инде.

Хәтеремнән шик-хатаны чәчрәтеп бир,
Җанга хикмәт орлыкларын син чәчеп бир,
Миңа ярдәм капуыңны син ачып бир,
Гакълым туры, телем төзек яса инде.

Ярдәм бир син хикмәтләргә кайту өчен,
Гакыллылар аңын-зиһнен баету өчен,
Йосыф сәүче әхвәлләреи әйтү өчен, —
Гыйльмем камил, телем тезек яса инде.

Йосыфка күп хәлләр ничек килгәнлеген,
Кардәшләре Йосыфка ни кылганлыгын
Һәм Мисырда олы мәлик булганлыгын
Нәзым белән сезгә әйтеп бирим инде.

Бу жиһанга Йосыф нәби килгән иде;
Ә атасы Йагькуб хакның сөйгәне иде,
Ә бабасы Исхак — диннең табибе иде —
Алла дусты Ибраһимның угълы инде.

Моңардан соң мин хикмәткә күчәчәкмен,
Гөл һәм рәйхан, энҗе-мәрҗән сибәчәкмен,
Йосыф нәби хәлен сәйләп бирәчәкмен —
Мөэминнәргә бу файдалы, аңлаң инде.

Кыйссалардан, хикмәтләрдән матуррагы,
Ялыкмыйча тыңлау өчен татлырагы,
Коръәндә дә бу хәкта сүз булганлыгы,
Шушы кыйсса икәнлеге ачык инде.

## Аңлатмалар

[1] Нәби — пәйгамбәр.

[2] Әхмәд — Мөхәммәднең күктәге исеме.

[3] Мөхәммәднең ук атарлык ике ераклыктан торып алланы күрүе турындагы легенда күздә тотыла.

[4] Сиддикъ — тугры. Мөхәммәдтән соңгы беренче хәлиф Әбубәкер күздә тотыла.

[5] Мостафа — сайлап алынган. Мөхәммәдкә карата әйтелә.

[6] Гъәдлә — гаделлеге.

[7] Фәзлы — өстенлеге, камиллеге.

[8] Җәбрар — куәт, кодрәт иясе (илаһияткә карата әйтелә).

[9] Гаффар — шәфкатьле, гафу кылучан зат (илаһият күздә тотыла).

[10] Табигыйн — иярүчеләр, пәйгамбәрне күреп белүчеләр.

[11] Сабит угълы Ногман — ислам динендәге ортодоксаль дүрт мәзһәпнең берсенә нигез салучы Әбү Хәнифә.

## Хәтимә

Йосыф сәүче кыйссасын без тәмам иттек,
Гъәрәб-фарсы телләречә бәян иттек,
Уку өчен, тыңлау өчен ансат иттек,
Укыганнар безгә дога кылсын инде.
Йосыф сәүче кыйссасын тик акыллы укыр
Тыңлаучының күңле эрер, яше агар,

Әгъзасыннан языклары чәчлеп чыгар,
Рәхим аңа игелеген бирә инде.

Укымышлы бу нәзымны сәйләр булса,
Һәм гакыллы колак тотып тыңлар булса,
Сөйләүче һәм тыңлаучы бер дога кылса,
Кабулчы зат аны кабул кылыр инде.

Укыганнар, тыңлаганнар дога кылыр,
Бу зәгыйфь кол дога көтә, тәңре белер,
Дога белән күп гөнаһлы кичерелер,
Ярлыкауга алар лаек булыр инде.

Гәүһәрне таш дию белән ул — таш булмас,
Тикмә кеше гәүһәр кадрен белә алмас,
Бу нәзымның кадрен бары ахмак белмәс,
Гакыллылар тыңлар, аңлар, белер инде.

Ай-һай моны тикмә кеше төземәде,
Зиһене ким кеше моны язалмады,
Бу зәгыйфьнең шушы нәзмы аз булмады,
Робагые үлчәмендә торсын инде.

Аты — Гали моны төзгән зәгыйфь колның,
Егерме дүрт изнек итеп тезде юлын,
Ярлыка син, йа рәхим, мин — гасый колың,
Рәхмәтеңдән әлеш өмет итәм инде.

Өмет тота бу гөнаһлы син мәүләгә,
Син юмарт, син рәхимле һәм син изгегә,
Мәрхәмәт кыл, йа рәхим, ул Кол Галигә, —
Кайгылы бу күңлемне син шат кыл инде.

Йа ходам, бу кол хаж,әте сиңа мәгълүм,
Мин зарлының мөнаҗәте сиңа мәгълүм,
Йа рәхмәтлем, йа шәфкъәтлем, кылма мәхрүм, —
Ахыр тында миңа иман син бир инде.

Ул мәүләдән ярдәм, ж,иңү килгән көндә,
Изге рәҗәп аеның нәкъ утызында,
Һәм тарихның нәкъ алты йөз утызында,
Бу зәгыйфь кол бу китапны төзде инде.

Булышлык һәм зиһен көче хактан алдым,
Илһам бүләк итүенә шөкер кылдым,

Бу вакытта бу китапны тәмам кылдым,
Сезгә, безгә ул файдалы булсын инде.

Кол Гали Кыйссаи Йосыф китабыннан.
Казан, 1989. Нурмөхәмәт Хисамов тәрҗемәсе.

## Аңлатмалар

[1] Ялавачлар — илчеләр, яучылар.
[2] Хыта — Кытай, кытайлы.
[3] Руми — грек.
[4] Шаһе җиһан — донья шаһы.

## Дастан Джумжума, поэма XIV века

Эта поэма — один из образцов средневековой татарской литературы. Пронизанное Коранической идеей конечности мира, произведение посвящено воспеванию жизни, прелестей человеческого бытия. Гуманистический пафос поэмы даёт основание, по справедливому мнению публикатора М. Ахматзянова и ряда крупных филологов, ставить «Дастан Джумжума» рядом с великими произведениями Возрождения.

## «Җөмҗөмә дастаны» тәрҗемәсе

«Җөмҗөмә дастаны» — XIV гасыр татар әдәбиятының гүзәл бер үрнәге. Әсәр үзенең сәнгатьчә эшләнеше һәм эстетик кыйммәте ягыннан шул дәвердә иҗат ителгән бөек итальян шагыйре Дантеның «Илаһи комедия» әсәре белән янәшә тора ала. Бу фикерне тикшерүче галимнәр Җәвад Алмаз, Хатип Госман да беравыздан әйтәләр. Шунлыктан, эшләнгән тәрҗемә әсәрне укучыларга якынайту җәһәтеннән файдалы бер хезмәт булыр, дигән фикердә калам. Тәрҗемәче аның рухын — явызлыкка, гаделсезлеккә нәфрәткә өндәп язган идеясен — саклап калган һәм зур поэтик осталык күрсәткән.

Марсель Әхмәтҗанов.

Кем әгәр мәңге дисә бу дөньяны,
Дөньяның нинди эше белсен аны.
Бар галәм юкка чыгар бер көн килеп,
Һәм түгел бер җан иясе мәңгелек.
Бу шулай... һәм аңа күп билгеләр,
Һәр яшәп торган кеше бер көн үләр.
Күр әнә киткән кешеләрне, килеп,
Кайсы яхшы, кайсысы яман булып.
Кайда меңнәрчә пәйгамбәр, патшалар?
Һәм сарайлары аларның кайдалар?

Кайда Адәм?[1] Кайда Нух?[2] һәм барчалар?
Мәңге калмас бер ходайдан башкалар.
Кайда Сафун?[3] Кайда Җәмшид?[4] Чәһрәбад?[5]
Кайда Зөлкарнайин?[6] Шир Хөсрәү[7]дә Гад?[8]
Кайда Дикъянус?[9] Шәддад[10]ләгыйн?
Кайда Фәридун[11], яки Нәмруд[12] тагын?
Кайда ул Рөстәм[13], яки Әсфәндияр?[14]
Кайда Нәүширван[15] — мәһабәт шәһрияр?[16]
Кайда ул Газнә шаһы — Мәхмүд дигене?[17]
Ялтырап тыштан, эчтән «мин» дигәне?
Кайда Ибраһим[18], яки Әдһәм бөек?[19]
("Солтан иде, яшәде ярлы кебек.)
Кайда Чыңгыз?! Кайда ул?! Бит ул да юк!
(Язмышы бу залимнең да бит шул ук.)
Барсы да — бу дөньяны тоткан кеше.
Мондый булырмы аларның соң эше:
Яттылар җирдә кяфенгә чолганып,
Тәннәре үз каннарына болганып,
Калдырып ятларга бар байлыкларын,
Тәхте-бәхтен, мәмләкәтләрен барын.
Бу канун: килгәч китәргә син тиеш,
(бәс тырыш эшләргә һәрчак изге эш)[20].
Сак кына бас — җиргә басканда — кара!
Туфрак ул — чергән үлекләрдән тора.
Һәр адым куйганың җирнең өстенә,
Басмага мөмкин берәүнең битенә.
Күр чәчәк аткан әнә — нәргис үзе
Көнгә баккандай гашыйкларның күзе.
Бакчада үскән матур сөнбел, кара, —
Сөйгәнеңнең бөдрәсен искә сала,
Чөнки туфрактан үсеп чыккан алар.
Анда ятканнар эчендә бар да бар:
Кайсы солтан, кайсы кол, кайсы әмир,
Кайсы хуҗа, кайсы бай, кайсы фәкыйрь,
Кайсы яшь, кайсы карт (ул колларның
Тик белә Алла аларның саннарын).
Җил тараткан кайсысының туфрагын,
Һәм ачып киткән сөякләрен — барын.
Билгесез тик — ул сөякләр кемнеке?
Байныкымы? Колныкы? Әмирнеке?

* * *

Тыңласаң мин бер мәсәл әйтим моңа.
Ул мәсәл — татлы, гүя балдан гына:
Гайса пәйгамбәр, шулай, илләр гизеп,
Шамгача[21] бер көн барып җитте йөреп.

Үтте ул шунда яшел бер сахраны.
Ул — агар су! Әй, матур кош сайравы!
Шунда Гайса, су читендә утырып,
Бик озак торды карап — хайран булып...
Төште күзе: сахрада бер таш тора,
Ул таш өстендә коры бер баш тора.
Ни күзе, ни аузы аның, гәүдәсе,
Әгъзасыннан калмаган һич нәрсәсе.
Мәрьям углының күзе төшкәч аңа,
Таң калып торды, карап башка таба.
Уйлады эчтән: «Гаҗәп — бу нинди таш?
Күпме йөреп, күрмәдем мин мондый баш!
Карый, язылган сөяктә бер язу:
«Кем идең, Баш! Бу ничек монда яту?
Синдә дә бит бер вакыт җан бар иде,
Тормышың шәп, бер гаҗәп хәйран иде!»
Гайса пәйгамбәр гаҗәпләнде кабат
Һәм күтәрде кулларын күккә карап:
— Хак-тәгалә! Бер теләгем бар, — диде, —
Һәм аны зинһар өчен какма кире!
Иа хода! Башка кире кайтар телен!
Мин белим Башның үзеннән кемлеген.
Килде бойрык Җабраилгә[22]: «Син тиеш
Җиткерергә бу сүземне, тиз җитеш!
Гайсага әйт, Баш сөйләр, терлер кабат.
Тик бу хәлдәй халкына бирсен сабак!»
Инде шулчак Җабраил җир йөзенә,
Гайсага бу хакта әйтте үзенә.
Гайса шундук атлады Баш янына,
Һәм болай сүз ташлады Баш ягына:
— Әй коры Баш! Дөньяда син кем идең?
Бер хатынмы, әллә юкса ирмидең?
Колмы идең? Яшәдеңме кол биләп,
Бик вә солтанлыкта эшләрне көйләп?
Әллә юксылмы идең — бер ярлымы?
Йә үзең идеңме шушы ярлыны?
Бәдбәхет саранмы идең, йә юмарт?
Башкалар синнән ничек, булдымы шат?
Бу сорауга, тәңре фәрманы белән,
Булмаса да теле, Баш болай дигән:
— Тыңла инде, хәлемне әйтеп бирим.
Нәрсәләр кичте бу баштан — белдерим.
Дөньяда мин бер олы патша идем,
Һич хисапсыз күп иде милкем минем.
Җөмҗөмә солтан иде исмем йәнә,

Шөһрәтем чыккан иде җир әйләнә.
Башкалам чиксез, хисапсыз зур иде,
Туктамый йөрсәң чыгалмассың кире.
Иңгә өч һәм буйга биш көн ул шәһәр
Бар җәберләрдән азат иде мәгәр.
Мин тагын салган идем анда сарай,
Әйләнеп чыксаң, үтәр шиксез бер ай,
Башына күз ташласаң — тот бүркеңне!
Күрер идең әчтә җәннәт күркене.
Өстенә чыккан кеше башын ия,
Юкса торса, башы болытка тия.
Анда кырыклап вәзирем бар иде,
Тотып арыслан менәрлек һәрбере.
Унсигез мең бикләремнең барсы да,
Көндә ике рәт килеп хезмәт кыла.
Һәм тугыз йөз җитмеш ирләр-колларым,
Ауга чыксам, әзер иде һәрчагын.
Ун мең ашчы хезмәт итмәстән борын
Һич вакыт сузмас идем ашка кулым.
Сакый колның ун меңе ясый вәяна,
Уң меңе — башмакчылар, хезмәт кыла.
Ай кебек күркәм минем ун мең хатын;
Кызы иде һәрбере бер патшаның.
Ун мең иде җариям, өстәвенә,
Иң гүзәлләрнең гүзәлләре генә.
Һәм сатып алганда һәрберсен менә,
Мең жария биргән идем һәрберсенә.
Хур шикелле ул гүзәлнең һәрбере,
Бер күреп мине кочарга зар иде.
Уйный меңләп музыкантларның кулы:
Мең чәң, мең кубызда берьюлы,
Меңе найда, меңе өрә быргыга,
Меңе суга барабан, меңе — аргуга,
Меңе доф уйный, меңе чадгу чала,
Меңе җәмбәл суга, меңе кул чаба.
Мәҗлесем уза иде шау-гөр килеп,
Уйласам хәзер алар төштә кебек,
Гаскәремнең саны йөз меңгә җитә,
Бер сугышчым мең кешене өркетә.
Байлыгым сансыз, санаусыз, бихисап,
Ил, халык тук миндә, юк сыйга исәп.
Ул вакытта бер җегет мин, шәп кенә,
Гайрәтем зур, нәкъ арысландай менә.
Акылым камил, исемем Җөмҗөмә,
Саны юк ләгыль-якутка, энҗемә.

Әзер иде күп кешеләр, җан биреп,
Бер карап калыр өчен, булса күреп.
Күктәге айдан гүзәл иде йөзем,
Һәм галимнәрдән галим идем үзем.
Көч, бәхет, хөрмәт, гүзәллекне миңа
Берьюлы биргән иде ул бер Хода!
Бар иде тагын минем хуш гадәтем,
Һәм шуңа чыккан иде изге атым.
Кайда әсир, кайда гарип, ярлы бар, —
Килә иде миңа мискин ярлылар.
Көн дә меңләп килсә дә дәрвиш, ятим,
Алмыйча китми иде ат һәм кием.
Итә идем башка күп-куп яхшылык,
Дәртлегә дәрман бирергә ашкынып,
Миндә җәберләү, золым һич юк иде,
Көн дә туктаусыз килә халык иде.
Ит пешә, бер чак та тормый тукталып:
Куй, сыер, ат һәм дөя, кош-корт тагын,
Меңләгәнчә... һәм тула иткә табың.
Ул касәләр дә кымызга туп-тулы,
Һәр касә энҗе, якутка коршулы.
Дөньяга чыкты даным мең-мең кабат.
Килде үлем — булды шул чак шаһка мат!

**Искәрмәләр**

*(Җәвад Алмаз тарафыннан эшләнде)*

[1] Адәм — беренче кеше исеме (мифологик).
[2] Нух — пәйгамбәр исеме.
[3] Сафуан — гарәп батыры.
[4] Җәмшид — борынгы Иран падишасы.
[5] Чәһрәбад — Җәһрәбад — бу сүз текстларда бозылган.
[6] Зөлкарнайин — Александр Македонский.
[7] Шир Хөсрәү — Иран падишасы.
[8] Гад — борынгы мифик, залим падйша.
[9] Дикъянус — борынгы грек падишасы.
[10] Шәддад — (кульязмада изах юк).
[11] Фәридун — Иран падишасы.
[12] Нәмруд — борынгы залим падйша, Ибраһим пәйгамбәрне утка салдырган кеше.
[13] Рөстәм — «Шаһнамә»нец мәшһүр герое.
[14] Әсфәндияр — Иран падишасы.
[15] Нәүширван — Иран падишасы.
[16] Шәһрияр — император.
[17] Мәхмуд — Газнә шәһәренең солтаны.

[18] Ибраһим — пәйгамбәр.

[19] Әдһәм — юмартлыгы белән мәшһүр ярым легендар падиша.

[20] «Изге» сүзе дастанда «яхшы» мәгънәсендә генә кулланыла. Шул мәгънәдә ул «Ит изгелек, көт явызлык» мәкалендә сакланып калган.

[21] Шан — Дамаск шәһәре.

[22] Җабраил — илче фәрештә.

[23] Газраил — үлем китерүче фәрештә.

[24] Фәхре җиһан —дөнья мактанычы (Мвхәммәд пәйгамбәр эпитеты).

[25] Кирамән кятибин — ислам өйрәтүләренә караганда кешенең бер гомере буенча эшләгән эшен язып баручы фәрештәләр,

[26] Нәсрани — христианнар.

[27] Рибә — пене, ришвәт.

## Салима, дочь Кунакбая (Повесть о девушке, побывавшей на том свете)

«Повесть о девушке, побывавшей в том свете» извлечена нами из книги «Литературное наследие». Опубликованная впервые в 1881 году, она интересна как увлекательное повествование о потустороннем мире. Эта фабула в дальнейшем найдёт самое широкое распространение в татарско-башкирской литературе периода реформы ислама и связанного с этим критического осмысления приверженцев старометодного обучения и образа жизни.

## Кунакбай кызы Сәлимә Мәрткә киткән кызның вакыйгалары

Гүшәр өязенең Сәрдә иле авылының Кунакбай кызы Сәлимәнең мәрткә барып, оҗмах-тәмуг күрдегенең бәяне Аллаһы тәгаләнең әмере илән мөэмин-мөселманнарга, фасикъ-мөнафикъларга, кяфер вә мөшрикләргә бу күргәнлегеңне игълам кылгыл димәк мәүҗәбенчә бер-ике парә «Нәсихәт-намә» пәра-гәндә кылдык. Мин бәндә — Зыйфа-Кунакбай кызы Сәлимәнең бу хәлләрне белдермәгә сәбәп булды: Мин әүвәлдә ике мәрткә китеп, түбәндә зикер улыначак хәлләрне күргән идем. Адәмнәр минем сүземне инанмаслар, мәсхәрә итеп көлешерләр диеп фаш кылмадым. Янә өченче мәртәбә мәрткә бардыкда түбән[дә] яд улыначак кемсәләрнең: «И бәдбәхет, ни өчен Ходай тәгаләнең әмерен тотмыйсың күргән хәлләреңне адәмнәргә фаш итмисең, ягъни мәгълүм хәлләрем калмады. Шул сәбәптән: «Адәмнәр тотмаса тотмаслар, Ходай тәбарәк вә тәгаләнең боерыгын тотмак кирәк!» — диделәр. Үземнең күргән хәллә-ремне бәян кыламын. Адәмнәр мондин гыйбрәт алсыннар, гөнаһларыннан тәүбә вә истигъфар кылсыннар, фасикъ эшләрдән тыелсыннар дию «Нәсихәт-намә» яздым.

Нәсихәтем ошбудыр.

Рәбигыль-әүвәл аенда җомга кичәсендә йасигъ намазын ида кылганым бәгъдүндә тәһарәт берлән яткан идем, уягъ хәлемдә дүрт кеше килде, дәхи җиде

яшел кош килде. Ул кешеләр күк күкрәгән тик мәһабәт [тавыш] берлән тәкбир әйтеп килделәр вә һәм куркыттылар.

— Кяфер сән? — дип җавап сорадылар.

— Әлхәмделуллаһ, мөселманмын! — дип җавап бирдем. Андин соң иман шартыны беткәнчә тәмам укыттылар, моның соңында:

— И бәдбәхет, Аллаһы тәгаләнең әмерен ни өчен сөйләмәенчә яшереп торасың, — [дип] дүрт ягымнан таяк илә сuktылар. [Таякларның] икесе — ак, икесе — яшел. Соңында шул таяклары дүрт аждаһа булды. Дүртесе [дә] янымнан килеп йотарга тордылар, агызларыннан ут чәчелеп тора һәм күзләрендин янып торган ут шәкеле [күренеп] торадыр.

Янә шул дүрт кешеләр «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ», вә «Аллаһы әкбәр»не укыттылар, тәүбә иттерделәр. Янә шул дүрт кеше дүрт җиремдин тоттылар, икесе ике аягымдин, икесе ике кулымдин тоттылар.

Икесе ике аягымдин, икесе ике кулымдин тотып, җанымны алырга билемә китерделәр вә янә билемнән күкрәгемә китерделәр, күкрәгемдин тамак төбенә китерделәр. Янә шул кеше[ләрнең] берсе аягымдин килеп бугазлады, җанымны сыгып алдылар, үземә күрсәттеләр. Җаным актыр, күккә ашырдылар. Аннан соң оҗмахка илттеләр. Җан күзем илән оҗмахны күрдем.

Оҗмах җиргә дә, күккә дә җитми тора, һәм ул тик актыр, дәхи бик яктыдыр, кояш кебек балкып торадыр, карап булмый, күз чагыладыр. Вә һәм бүлмә-бүлмә сарайлар бар, хәтта күренмәйдер. Әлван-әлван нигъмәтләр, яшел-яшел табаклар илән яшел җимешләр, ак табаклар берлә ак җимешләр куйган һәм дөрре-якут ягъни чиксез. Дәхи һәртөрлек агачлар бар, бәгъзе-бәгъзе яшел яфраклар түгәрәк һәм ботакларында кошлар сайрашалар. Каю Мөхәммәт өммәтләре төнлә уйганып «салават шәриф» әйтәләр, шул «салават шәриф» савабыннан яратылдык без, дип әйтәләр. Шул «салават шәриф» әйткән кемсәне Ходай тәгаләдән ярлыка, дию телибез. И бари Ходая, бу колыңны ярлыка. Оҗмахта урын биргел, дип.

Янә оҗмахта озын буйлык егет һәм сылу-сылу кызлар. Барсының кигән киеме җитмеш кат, әгәр киемнәрен учка йомсаң, бер учка сыяр, шул кадәре юкадыр вә дәхи оҗмахның һәр ишегендә «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ» дип яшел хат язылган. Ул оҗмах агачының төбендә елгалар бар, һәр елгадан һәртөрле чишмә агып торадыр. Бәгъзесе шикәр тик, бәгъзесе сөт тик, вә гайре сыйфатлар берлә агадыр һәм көмеш савытлар бар. Бәһәм хур кызлары, вә һәм хур егетләре — сыйфат кылырга мөмкин түгел. Оҗмахның меңнән берен сөйләп бетерер хәл юк. Әгәр кем ирсә шик килтерсә бу эшләргә, кяфер булыр.

Андин соң җиде кат җирнең астына төшерделәр. Дүрт кеше дәхи җиде кош вә һәм гарасат мәйданына кергезделәр һәм мизан тәрәзүсенә кергезделәр. Тәмуг якасына өч адәмне якалап илтеп салдылар. Җаныма янә җитмеш аждаһа килтереп куйдылар. Агызларындин утлар чыкадыр. Күзләрендин ут тик янып торадыр. Озынлыклары һәм биеклекләре кырык аршин кадәре. Намаз укымаган кешеләр шул еланнар берлән газап кылса диеп әйтәләр. Шул еланнар минем берлән сүзләшә башладылар. Бу күргән хәлләрне мөэмин мөселманнарга, фасикъ-мөнафикълар, кяфер вә мөшрикләргә белдермәсәң вә сөйләшмәсәң, без сине йотармыз, дип әйтәләр. «Беремез йотармыз, беремез косармыз вә янә беремез йотармыз, тәмам йотып-косып бетергәч, янә җиде кат җир йотар, янә тәмуг төбенә

куяр. Мәгәр Аллаһы тәгалә боерыгын тотсаң, котылырсың», — диделәр. Шул кешеләр гуваһлык биреп, ант итеп, тәмуг якасында әйттеләр: «Ля Илаһи илла Аллаһи, Мөхәммәт рәсүл Аллаһы, валлаһи ант булсын, мин Хәзер пәйгамбәр булырмын, мине таныгыл», — диде. Янә икенчесе: «Ля Илаһи илла Аллаһы, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ, валлаһи ант булсын, мин Ибраһим пәйгамбәр булырмын, таныгыл», — диде. Янә өченчесе: «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ, валлаһи ант булсын, мин Гайсә пәйгамбәр булырмын, мине таныгыл», — диде. Дүртенчесе әйтте: «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ, валлаһи ант булсын, пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән салават Шәрифтән яратылган фәрештә торырмын, мине таныгыл», — диде.

Ул дүрт пәйгамбәр галәйһис-сәламнең кигән киемнәре икесе яшел, җидешәр кат кигәннәр, янә кошлары үтә бик яшел. Янә ул пәйгамбәр, яшел кошлар ошбу сүзләрен әйттеләр: «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ Дип вә дәхи Мөхәммәт өммәтенә хәбәр виргел», — диде.

Янә ул пәйгамбәр, җиде яшел кош ошбу сүзләрне әйттеләр: «Госел коенып, пакь тәһарәт алып өч көн ураза тотсыннар вә янә рас күңеле белән корбан чалсыннар, гел гөнаһлардин тәүбә вә истигъфар кылсыннар, картлар — картларга, яшьләр — яшьләргә, байлар — байларга вә дөнья малына алданмасыннар, вә барча языкларыннан тәүбә кылсыннар, вә барча гөнаһларыннан вә зина кылмакдин кайтсыннар, вә бозучыларга дошман булсыннар, егьлап, аһ-ваһ дип тәүбә кылсыннар, биш вакыт намазны куймасыннар, ошбу ахыр сулуда иман берлә үтмәклекне теләсеннәр вә гайре гөнаһ кылмакдин саклансыннар; ошбу әйткән сүзләрне ишетсеннәр. Күп адәмнәр имансыз калдылар, ахирәт хәленнән хәбәрсез булдылар, тәүбә кылмадылар, вә дәхи тизлек үзрә тәүбә кылмасалар, шиксез, тәүбә капугы бакланырга якындыр. Тәүбә капугы багланган соңында тәүбә булмас, һәрни кадәре дин тотучы вә тәкъва галимнәрнең вә ни кадәре теләкләре кабул була торган адәмнәрнең теләкләре кабул булмас вә садака-корбаннары кабул булмас, укыган намазлары вә тоткан уразалары кабул булмас»,— диделәр.

Имде барча Мөхәммәт өммәтләре, Аллаһы тәгаләне бер дип белгән вә Мөхәммәт пәйгамбәр галәйһис-сәламне хак дип белгәннәр вә барча гөнаһлардин кайтсыннар ашыгып, тизлек илән тәүбә белгәннәр вә барча гөнаһларыннан җиде кат җир астына җитмеш мең шайтаннарны ташлаган

диерләр. Җир йөзендә фәсикъ-фәсад күпдегендин, ягъни адәмнәрнең гөнаһ шомлыгындин берсе җитмеш мең чир-сырхауларга дару ошбудыр, инша Аллаһы тәгаләдән диделәр. Әүвәл «Кол агузе би Раббел-нас» сурәсене җиде мәртәбә өшкергәй, янә «Сурәи ясин шәриф»нең әүвәлеңнән ахырына җидешәр кат укып өргәй, шифа тапкай, җиде яшел кош дип әйткәнбез, җиде фәрештә, диделәр.

Ошбулар әйттеләр: «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ, ант итеп әйтәмез, — дип әйтәләр, — юкарыдагы әйтелгән сүзләргә вә һәм хәбәрләргә һәркем шик килтерсә, ышанмаса, шиксез кяфер улыр. Дөньядин имансыз китәр. «Агузе биллаһи мин шәррә зәликә» вә дәхи ихлас күңел берлән өч көн ураза тотып, корбан чалсыннар. Җитмеш мең бәлане, ягъни чир-сырхаунк китермәк өчен җитмеш мең шайтаннар багланыр өчен, — диделәр. — Вә һәм иман берлә үтмәкләренә сәбәп булгай вә нигъмәтләренә бәрәкәт биргәй, — диделәр. — Әмма

бу хәбәр нарасидә яшь углан вә утлагучы хайваннар өчен Аллаһы тәбарәк вә тәгаләнең үз сабырыдыр, колларына сөенеч өчен колларына иман илә генә тотыр өчендер», — диделәр.

Һәркем бу нигъмәт намәләрне илдин. илгә, мәчетдин мәчеткә йөртеп укып фаш кылсыннар. Ул йөрткуче кемсә өчен Ходай тәгалә бер фәрештә яратыр. Ул кемсәнәне кыяматкә дикең Ходай тәгаләдин ярлыкар теләймен. Бу хәбәр Кунакбай кызы Сәлимәнең хәбәредер һәм минем алгандыр, әмма хәбәр, ягъни күргән хәлләрем мәгълүм улына; җитмеш мең аждаһа йотармыз дип торалар. Бу хәбәр мәүҗәбенчә һәм дүрт пәйгамбәрнең куркытмаклары буенча мәгълүм улынадыр һәм шул дүрт кеше әйтәдер: «Бу хәбәр — Аллаһы тәбарәк вә тәгаләнең хәбәредер, безгә бездин, сезгә сездин барча Мөхәммәт өммәтенә Аллаһы тәгаләнең хәбәредер, безгә бездин, сезгә сездин барча Мөхәммәт өммәтенә Аллаһы тәгаләнең ахыргы хәбәредер. Мондин соң хәбәр булмас», — диделәр. Бу хәбәр өч елдан бирдедер, адәмнәр шикләнмидер. Тагать вә гыйбадәт кылмайлар, гөнаһдин тыелмыйлар, вәгазь вә нәсихәтне колакларына алмайлар, гыйбрәт алмайлар, галимнәр гыйлем илән гамәл кылмайлар, нәфсәнә арзусына ияргәләр, наданнары галимнәр сүзен тыңламыйлар, галимнәрне дошман тоталар. Кемдер вәгазь иәсихәт әйтер булса, аны кем хакарәт күрәләр, бер-берсен гайбәт кылмакны һәм сүз йөртмәкне һичнәрсәгә санамыйлар, ягъни сүзне сөйләшмәктә һич гөнаһ юк дип хисап кылалар, бу сүзне җиңел санамак берлә олуг гөнаһка баталар, ни үкенечтер. Ошбу миннәргә тәүбә-истигъфар кылмай дөньяда, ахирәтләрендә үкспмәк файда бирмәс. Янә шул дүрт кеше әйтә ант итеп: «Ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ, валлаһи ант булсын, Ходай тәгалә җитмеш мең фәрештәләр яратты вә дәхи өч елдан бирле әйткән хәбәрләрнең берседер. Дөньяда галамәт заһир кылды. Ул галамәт шулдыр — Ходай тәгалә күктә йолдыз яратты. Бер тарафы сачылып торды. Мәгърип тарафыннан тугып, төньягындин мәшрикъ тарафына барды. Адәмнәр күзе илән күрде. Хәвефләнмәделәр. Гыйбрәт алмадылар. Андин гайре гыйбрәтләр һәм чуктыр.

Шәйлә бәла вә каза, чир, сырхау тик вә кяферләрне ирек кылмак тик — ошбулар барсы адәмнәрнең шомлы-гындиндер, диделәр. Вә дәхи юкарыдагы зикер ителгән җитмеш мең фәрештә диңгез төбендә таш алып, җир өстендәге адәмнәрне таш илән һәлак кылаеп дисәләр һәм шәһәрләрен җил илән бер-берсен кырып харап кылаек, дип әйтәләр. Ходай тәгаләдән фәрман алып, мәгәр тыңлап, тәүфикъ табып, гөнаһлардин истигъфар кылсалар, тәүбә кылаек, дип әйтсеннәр. Ошбу бәла вә каза вә чир-сырхаулардин котылмак өчен намазларны укысыннар, өч көн ураза тотсыннар вә дәхи корбан чалсыннар. Инша Аллаһы тәгалә коткарса кирәктер. Мин Кунакбай кызы Сәлимәнең

өченче мәртәбә бармакы шул мәгърип тарафыннан йолдыз тугай елны дию мәгълүм улына. Шул юкарыдагы зикер улынган кешенең анты бәнем антымдыр, ля Илаһи илла Аллаһ, Мөхәммәт рәсүл Аллаһ, валлаһи ант булсын.

Бу китап «Мәрткә киткән кызның вакыйгалары бәянендә» исеме белән Казанда Кукубин табигъханәсендә 1881нче елда басылып чыккан. Авторы — Гүшәр өязенең Сәрдәкле авылыннан Кунакбай кызы Сәлимә. Бу хакта әсәрнең үзендә үк хәбәр китерелә, автор үзе әсәрен «Нәсихәт-намә» дип атый. Әмма нәшрият китапны алда күрсәтеп үтелгән исем белән чыгаруны кирәк тапкан.

Китап үзе уртача зурлыкта булып, нибарысы 16 биттән генә тора. Әдәби-тарихи әһәмияте ягыннан караганда борынгы әдәби стильдә язылган, эчтәлеге белән гаять тә кызыклы.

Фәрит Яхин.
Әдәби китап, өченче китап. Казан, 1996 ел.

**Аңлатмалар**

*Фасикъ-мөнафикъларга* — гөнаһлы-икейөзлеләргә, *Мөшрик* — мәҗүси, Аллага табынмаучы. *Игълам кылгыл* — белдер. *Мәүҗәбенчә* — сәбәбеңчә. *Парә* — бит. *Пәрагәндә кылдык* — тараттык. *Зикер улыначак* — искә алыначак. *Яд улыначак* — искә алыначак. *Истигъфар кылсыннар* — ярлыкау үтенсеннәр. *Рәбигыль-әүвәл* — март. *Иасигъ намазы*— йокы алды намазы. *Ида кылганым* — үтәвем. *Бәгъдүндә* — соңында. *Уягъ* — уяу. *Дәхи* — тагын да.

*Әлхәмделуллаһ.* — Аллага шөкер. *Шәкеле* — рәвеше. *Әлван-әлван* — төрле-төрле. *Дөрре-якут* — алтын-якут. *Бари* — юктан бар итүче.

*Мизан тәрәзүсенә* — үлчәү тәлинкәсенә. *Гүваһлык* — таныклык.

*Үзрә* — белән. *Капугы багланырга* — капкасы ябылырга. *Тәкъва* — диндар.

*Нарасидә* — күрсәткечендә. *Дикен* — тикле.

*Тагать* — дини йолаларны үтәү. *Нәфсәнә арзусына* — нәфес теләгенә. *Миннәргә* — мин-минлекләргә. *Заһир кылды* — ачыкланды, туды. *Чуктыр* — күптер. *Шәйлә* — шулай итеп.

**Батырша**
**(1709-1762)**
**Доношение императрице Елизавете Петровне**

Уроженец д. Карыш Сибирской даруги Бирского уезда (ныне Балтачевский район) в исторической литературе — Батырша Алеев, Гибадулла Магзялетдин, настоящее имя Габдулла Галиев. Псевдоним — тахаллус Батырша дан народами Урало-Поволжья за активную деятельность в качестве проповедника — учителя и судьи на основе законов шариата, а также агитационную работу по защите прав и свобод башкир и татар (мишарей), объединения их на основе канонов Ислама. Подготовил и возглавил восстание этих народов против насильственной христианизации, изъятия их земель. Заключён в Шлиссельбургскую крепость. На основе своих созданных ранее воззваний, увиденного и пережитого во время разъездов по краю написал «Доношение императрице Елизавете Петровне», ставшее, вместе с работами Н. Новикова, Д. Фонвизина и А. Радищева, выдающимся произведением российской общественно-политической, художественно-публицистической мысли II половины XVIII в.

Погиб при попытке бегства из крепости. Местонахождение могилы определено в последние годы.

Батырша повествует о народных бедствиях, свидетелем которые он стал во время разъездов по уездам и волостям края. По его мнению, они призваны объяснить причины восстания и оправдать, почему призванный проповедовать

покорность и смирение мулла стал идеологом и руководителем общенародного выступления. В приведённом отрывке читатель становится свидетелем народных страданий и постепенного перехода автора-повествователя на путь призыва к восстанию.

## Литература

*Соловьёв, С.М.* История России с древнейших времён. Кн. 22, тт. 23-24.

*Чулошников, М.А.* Восстание 1755 г. в Башкирии. М-Л., 1940.

*Хусаинов, Г.* Кровавый 1755. Уфа.

*Хусаинов, Г.* Письмо Батырши императрице // «Совет Башкортостаны», 1970, 17 декабрь.

*Амиров, Р.* Летопись современности. Уфа, 1985.

*Рәхимов, Җ.* Батырша. Казан, 1988.

*Алишев, С.* Тернистый путь борьбы за свободу. Казань, 1989.

*Шәйхәйдәров, Р.* Батырша. Казан, 2010.

1 б // Ғиззәтлү дәүләтлү падишаһымыз ғәзими хәзрәт-ләренә кем тәхет вилайәтендәдүр рус мәмләкәте вә һәм гәйреләр вә һәм ғәйреләр вә һәм ғәйреләр[1].

Бәян вә ғәян ҡыладур бәхре ғисъянда ғәрҡ улан хәҡир бәндәсе Оренбурх губирнасында үзендән хасил улан тағилык вә бағилык һәйәтле мажрилар ни сәбәбдән вә ни ғилләтдән садир улмаҡны. Бу рәсемлә бән фәҡир бәндә[2] Баһадиршаһ Ғәли уғлы ғилем тәхсил ҡылмаҡдан суң йыл ярым миҡдары Гәйнә иләүндә Илүш мулла ауылында тордым ғилемлекдә. Вә дәхи Исат правинчасында Мөслим ыстаршина ауылында тордым түрт йыл миҡдары ғилемлекдә. Андин суң үз еремә ҡайтуб Яныш камандасында Ҡарыш ауылында тордым алты йыл ҡәдәре. Бу яд ҡылунған ауылларда тордым имаматлык ҡылуб, мәдрәсә тотоб, уғланлар уҡутуб вә һәм халайыҡларға әмер мәғруф вә нәһимөнкирләр итүб. Бу тариҡа илә «Эй мөьминләр! Алланың фарманыны тотоңызлар вә фарызларуны әда кылынызлар! Кем үзүмезне юкдан вар идән вә барча ниғмәтләрне камиллек берлә вирән илаһымыздур. Вә дәхи пәйғәмбәрнең сөннәтенә лазым улыңыз кем динемезнең олуғыдур. Вә дәхи имамларымызның мәҙһәбенә мөтәҫәбәт улыңыз кем, анлар вәраҫатә әнбиялардур, дин эшләрендә ижтиһад идүб безләрне дин юлуна күндү-рәчеләрдүр. Вә дәхи «эй мөьминләр! Фарманбәрдар улыңызлар, заманымызнын падишаһына вә һәм барча мәртәбә вирүлән наибларына кем анлар дин вә донъя эшләремезгә мәдәдче-ләрдүр вә имен вә сәләмәтлек илә рузгәр кичурмәкемезә сәбәбчеләрдүр. Вә эй мөьминләр! Ошбу әуамиремәзкүрәләр безләрә лазымдур аятеҡөрьәниә илә нитак кем алла ғәзшанә ҡаләмендә бойормышдыр ҡуләтәгалә: «Әтиғу алләһо вә этиғу әлрәсүл вә әүәли әл-әмер мәнкем»[3] әльаят.

Бу аятда ҙекер идүлән «әүәли әл-әмер»дән морад мәҙһәб эйәсе имамлардур вә мәмләкәт биләгүче падишаһлардур вә мәртәбә вирүлән наиблардур. Вә бундин артуғырак һәм ни нәсихәттәр вә ни хөкөм вә тәһдидләр кәрәк булса, китабларымызда бойоролған вәжһечә мәйелсез туғрылык берлә ғәли ҡәдәр иләмкән әда ҡыламыз ирде. Вә халайыҡлар сәмғән вә тағәтән диүб ошбу нәсаих

мәҗкүрәне жан вә дил илә ҡабул идәләр ирделәр.[4] Бәс, шул кағидәй мәзбүрә илә ру рузгәр кичүрә торгач, халайыҡлар арасында ишетүлә башлады вә белүнә башлады егрәнечле//хәбәрләр вә яңы пәйда улан бозоҡ эшләр. Шундай егрәнечле бозоҡ эшләр кем, ислам әһеленен дин вә донъя торошына мәзәрәтләр вирүб бичара вә битакәт илиә[5].

Ул эшләрнең берсе[6] улдур кем, тарафлардакы диндәш-ләремезне, йәрни Ҡазан вә Оренбур вә Тубул губирнасындағы мөхәмәди мөьминләрне рус жәмағәтенең архәрайлары йәки поплары йәки үзгәләре таълим вә тәһдидләр илә вә хәйлә вә тәхәуифләр илә ничүкдүр кем мөмкин әүлә айларны жәбрән вә әкраһан[7] ислам динендән чыҡаруб рус диненә кейүрүб анларның ризалыҡы вә деламәке һәйәтенчә ғарызнамәләр язуб тамғаларуны салдылар. Вә дәхи ул мескенләр буйлә жәбер вә икраһ илмәк сәбәбле хөкөм эйәләренең ғәнденә варуб халләрүне ғарыз идүб кирү ислам динендә тормаҡны вә һәм ул икраһ ҡылғучы залимлар үзәренә хөкөм вә дад ҡылмаҡны эстәгән ваҡытларында айларның һич бер сүзләре тыңланмайуб, анлар әбәдел-әбәд мәхрүм вә мәғбүн улдылар.

Вә дәхи ул ислам динендән чыкарулынларның ясаҡларуны вә һәм үзгә хеҙмәтләрүне калган мосолманларның өстүнә салдылар. Ул мосолманларны үзләренең динләрендә сабит булуб торған өчөн айларны хур күрүб гәһед ҡәдимдә өстләрүнә лазым улмаган йөкләрне йөкләделәр, та кем айларның дин вә донъяларына тарлык вә ноксанлыклар итешсүн диб[8].

Вә дәхи улдур кем ҡәдими замандай бирү хаҡ жәл вә ғалә хәзрәтенең, хәзинәсендән тағлардан вә күлләрдән алуна торған тозлардан халайыҡларны мәнер идүб кәлтәләрдән сатуб алмаҡға көчләделәр[9]. Оренбург губирнасындагы олуғ вә кечек барча мосолманларнын ризалыҡлары юҡ икач, динен динчә көтмәгән, халыҡға киңәшүн тотмаған, үз рыялы ҡуштан түрт-биш ыстаршинанын ризалыкны барча губирна халкы үзаренә ризалык яздылар[10]. Вә ҡайсы ыстаршиналардур кем иҙгүлеккә вә әманлыҡға һиммәт идүб, халыҡ киңәшен тотоб барча мосол-манлар берлә ул мәнеғ ҡылыуға риза булмаған ирделәр. Шул ыстаршиналарны төрлөк хәйлә вә тәхәүифләр вә ыҙалар илә ул мәҗкүр ризалыҡ языуына ҡуллар ҡуярга вә тамғаларуны салурға көчләделәр. Вә ул ыстаршиналарның мөбәрәк вә камил жәуабны тыңламадылар[11]. Шул рәүешле жәуабдур кем, ул ыстаршиналар әйтделәр: «Эй, түрәләр, падишаһымыз хәзрәтләрендәй рәхимле уҡаз килде; уҡулды; ишутдук: «Эй ҡолларым, деләсәңез тозны тағлардан вә күлләрдән алуңыз вә деләсәңез ҡәлғәләрдән алуңыз», дию. Вә һәм шул уҡаз илә бергә үк янаралдан уҡаз килде; уҡулды; ишүтдүк: «Эй, халайыҡлар, тозны ҡәлғәләрдән аласы булуңыз», — диб. Имде падишаһымызның рәхимле уҡазы мужәбенчә тозны тағлардан вә күлләрдән аласы булдуҡ. Камандамыздағы олуғ вә кечек барча халайыҡларымыз илә вә риза булмаймыз, ҡәлғәләрдән алурға дию жәуаб бирделәр. Түрәләр ул жәуабны кабул итмәйүб. Ул ыстаршиналарны бәғзесен сүгүб, бәғзесен яңаҡға суғуб, бәғзесен саҡалын тарткалаб, бәғзесен ҡәлғәгә алдуруб вә өйөнә ҡайтаруб вә һәм алдуруб вә һәм ҡайтаруб вә һәм алдуруб вә һәм ҡайтаруб би маза йөрөттөләр берлә рәнжүтүб.//Айлардан ни ғәйебле эш вә ғәйебле сүз вә ғәйебле аңар табулур икән? Хәүфләнүб риза булурдар иде дию. Шул рәүешле халайыклар риза булмайунча[12] бер йәйне уздурдылар. Ахыр әламыркыш көне Оренбурдан Ҡотломәт мирза

Өфөгә килүб янарал уҡазын ҡеүәтләндереб ыстаршиналарга бойорды: «Риза булуңыз! Ахыр бу эш булмай ҡалмас, чара табмазсыз, тозны ҡәлғәләрдән алмайынча» диб. Вә һәм ҡуштан ыстаршиналар бу эшкә ярдамчы булуб әйтделәр: «Хәләл саҡалларыңызны йолҡдордыңыз, бара торғач бер ғәйебле сүзгә йәки ғәйебле эшкә төшәрсез, башыңызны һәләк идарсез, турәләр берләмү ҡаршулашуб торорға теләйсез, риза булуңыз» дию. Ахыр ул ыстаршиналар һәм бундин артук чара вә тәкәт тота алмайуб кәлтәләрдән алурга көчләнделәр[13].

Вә дәхи улдур кем, ҡәлғәләрдәге түрәләрнең залимлыҡы хәд вә ғәйәтдән кичде. һәр Хәдисәләрдә хөкем вә дад эстәмәккә ҡәлғәләргә бармаҡдан халайыҡларның өмидләре кисүлде[14]. Нитак кем Өфөдә вә Чиләбүдә түрәлекдә торган ике кенәзнең[15] ваҡытында анлар хозурына барған дәғүәчеләр вә һәм карыучылар бәгзесенә ун сумға, бәғзесенә утуз сумга, бәғзесенә илле сумға етүб чыкдылар[16]. Көндә бөтәр эшне айга, айда бөтәр эшне йылга суздылар мал алур өчөн[17]. Вә һәм иләүләрдәге бәғзе ыстаршиналар би ниһәйә залимлыҡлар илә халайыҡ-ларның малын йыйуб вә исерткүчләр эчүб вә әдәмиләрне ҡылыч берлә чабуб ҡулларны кисүб моның охшашлы хәдсез жәфалар ҡылдылар. Әлшә хөкөм эстәгән ваҡытда хөкөм эйәләре ул залимлар үзәренә хөкөм йөрөтмәделәр.

Вә дәхи улдур кем тарафларға узуб йөрөгуче юмушлы (йомошлы) руслар би ниһәйә жәфалар күргүзделәр ҡыйнамаҡ, суҡмаҡ вә алум алмаҡ вә уғырламак берлә. Вә һәм указдин тыш ылау бирмәймез диб ҡарыу иткән кешеләрне үлтүрмәк тик. Вә һәм ылау озатучы кешеләрне драгунлар ҡыйнап үлтүрмәк тик. Ҡайсы берне әйтүб тукатайун[18]. Һәр тарафларда вә һәр түбәләрдә золомлыклар хәд вә ғәйәтдән кичде. Мескен халайыҡларның таянуб вә иғтимад кылуб дад вә хөкөм эстәр чарасы булмады[19].

Ошбу яд ҡылунган яңы пәйда булган бозоҡ, егрәнечле эшләрнең[20] сәбәбендән халайыҡлар нәдәмәтләнүб вә зарлануб тора торғач ишетүлә башлады ғәуамәлнас арасында Нуғай юлы башҡортлары жәнк ҡоралларыны төзиләр, ғәйәт төзүмәк илә. Алла әғләм ни хал өчендер[21].

Вә һәм андин аз суңрак ишетүлә башлады: Себер юлы, Усы юлы башкортлар ҡорал төзиләр. Аллаһы ғәләм ни хал өчөндөр дию.

Андан сук бән фәҡир зан итдем: бу рәүешле атлы чаплы төзөнмәкдә бер хикмәт бардур, бу серне бән һәм аңламаҡ тейешледүр диб Себер юлына Исат правинчасына үзем әүүәл ғилемлекдә торған Мөслим ыстаршина ауылына миһманлыҡ вәсиләсе илә сәфәр әйләдем. Ул йәй көнендә миһманлыҡға өндәгәнләр ирде. Бу көндә өчөнче йәй тамам улды[22]. Ул Мөслим ауылынын жәмағәтләре бәнум миһманлыҡымны ғәнимәт күрүб ғиззәт вә икрамлар әйтделәр вә тикрәдәге ауыллардан меллаларны вә һәм ғәйреләрне өндәб[23] үзләренең сәхрәдәге йәйләү ауылларында//мәжлус хәлҡәсен ҡороб төрлөк ниғмәт вә әсбаблар илә халыҡны хөрмәтләделәр. Бән фәҡирнең хозурында тәүәзиғ тәмәллыклар илә диз чүгүб мөлләләр вә ғәйреләр һәр берсе үзенә хәжәтле мәсьәләне сөал әйдәделәр[24]. Бу фәҡир бәндә фәнүн ғилемдән үзенең хәзинәсендә варынча анлары жәуаб бирмәк илә сәмахат күстәреб анларны иршад вә делшад әйдәде[25]. Вә мәжлес халҡы ҡымыз эчүб, мәет улуб, шадлыҡ сүзләрен вә һәм юҡаруда яд ҡылунған, яңы пәйда улан фетнәләрнең рәнжусендән хәсрәтләнмәк

сүзләрен сөйлә-деләр[26]. Бер ходайымыздан ғәйер иғтимад кылур еремез юқдыр дию сөйләделәр. Мөнтәзар улдум, артуксы сүз булмады.

Ул ауылда ун көн ҡәдәре торғандин сук Салжуғут иләүенең башҡортлары мишәрләрне миһманлыҡҡа өндәделәр. Мишәрләр алтмыш, етмеш атлы кеше Салжуғут иләүенә бардуҡ, башҡортлар күб ауыллардан меллалары, тикүз халайыҡлары берлә күб халыҡ жыйылғанлар. Мәжлес халкәсен короб, кымыз илә халыкны хөрмәтләделәр[27]. Халайыҡлар мәетлек ралибулуб гаһ шадланыб, гаһ хәсрәтләнеб күб сүзләр сөйләделәр вә әйтделәр: «Мәнеғ ҡылунды эчә торған тозларымыз вә аулай торган сунарларымыз. Вә эй хәзрәт! Хараб итде кафыр рус иләүемездән күб мосолман туғанларымызны диндән чыкаруб чукундырыб вә һәм рәхим булмады түрәләремездән вә һәм[28] янаралдан. Хәд вә ғәйәтдән кичде фетнәләр вә жәфалар бу падишаһымызның заманында. Бәс, тәҡәт тотарлыҡымыз кал-мады. Бундан[29] яманыраҡ эш булурмы кем? Хаҡлыҡны иҡрар вә иғтиҡадидан хаҡ диндән чыҡаруб хаҡлыҡны иҡрар вә игтиҡад әйләмәгән дингә ғәкирүлә хал бу кем? һәр дин әһеленен үз дине үзенә сөйөклөдүр диделәр. Бәғзесе әйтде: «Диндән чыҡармаҡ уҡаз илә мәнеғ ҡылунған дию ишетүләдүр» диде. Бәғзесе әйтде: «Ул мәнеғ ҡылмаҡда безгә ни файда кем ғәделлек берлә камилланмаса? Шул рәүешле кем, ҡачан безнең мосолман-ларымыз бер ничә кеше русларны көчләб ислам диненә кейүрсәләр, чиркәүләрне хараб әйласа, андан суң падишаһ ул мосолман ҡолларының гонаһлы ғаҡыл тәразусының бер пәлләсенә салыб вә ғәделлек мыҙкалны тәразунын икенче пәлләсенә салса, ул мосолман ҡолларының гонаһы ғәделлек мыҫкалы тәҡабеленда ни миҡдар ағыр килүр вә ни хөкөм вә ни жәза лазым улурса, шунтик падишаһның рус бәндәләре мосолманларны дин сәбәбле көчләб, мәсжедләрне хараб иткән ваҡытыда шул мәҙкүр иғтибарча ғаҡыл тәразусында ғәделлек мыҫкалы илә үлчәб шул мәҙкүр иғтибарча хөкөмләр вә жәзалар лазым улмак тейешле ирде. Аның өчөн барчамыз падишаһның ҡолларымыз. Жан вә делемез илә падишаһымызның сәламәт-леген теләймез[30]. Вә барчалар падишаһымызның дәүләте вә Шәүкәтенең кәмаллиәты илә шад вә мәтәфәхер улармез вә барчаларымыз хур вә жәфалар, фетпо вә болалар вакытында падишаһымызга шикайәтләнәмез вә падишаһымызга сығына-мыз. Бәс, ҡачан падишаһ бәндәләренә рәхмәт назарын бәрабәр салмаса вә залимларның жасасын гомайынбәғи әда ҡылмаса вә һәм үзе илә диндәш улмаған сәбәбле рәғиәләренә хәҡарәт назар салуб, айларның дин вә донъясына тарлығлар бәрса аз фәһеме бар кем сәнә фәһем әйлар кем, «Ул эшнең ахыры нәтә ула» диде.//Бәғзесе әйтде: «Үз рәғиәсе берлә уйнаған, үз ҡулы астына золомлыҡ ҡылған йорт унмаз булур. Халыҡ теленә төшкән буш булмас, бу усаллыҡның ахыр бер ниһайәсе бардыр» диде. Бәғзесе әйтде: «Золомлыҡ түрәләремездә вә янарал-ларымыздадур, күрәсез кем. Ошбу мәлғүн би фәһем залим янарал падишаһға прибул итәйүм, падишаһға сүклү (сөйөклө) улайым вә бөйүк мәртәбә табайум, диб ҡул асты халайыҡларны булғатуб, төрле хәлләргә дүндүрүб, өстләренә ғәһед ҡәдимдә лазым улмайын йөкләрне йөкләмәккә көчләб, риза дәгүл-лекләрен ризалыҡға язуб тамғаларуны салурға көчләб, төрлөк хәйләләр берлә дин вә донъяларына тарлыҡлар бирүб, халайыҡларға тәхйыл вә тәнғирләр вирәдүр. Йәғни халайыҡ-ларны падишаһ хаҡында яман хыялға дөшөрөб, йөз дүндүрүб, ҡачмаҡлыкларына сәбәбче уладур, фәһеме етешмәйән күб ғәуамлар падишаһ хаҡында хыялға вә гөманға дөшөб кем,

бу барча фетнә вә җәфалар падишаһдандыр диб ҡачмаҡға һиммәт идәләр[31]. Бәс, ул мәлғүн би фәһем янарал падишаһға файда вә яҡшылыҡ итәмен, ди торғач үзенең ахмаҡлығы берлә падишаһға залимлыҡ вә жафилыҡ исемен йөкләб, падишаһның рәғиә-ләрене[32] качырмаҡға сәбәбче уладур вә падишаһны үз рәғиәләре арасында вә һәм үзгә өлкәләрдә залимлыҡ вә жафилыҡ исеме илә шөһрәтләндүрәдүр. Хак тәғәле тәҡдиренең, ахыры без нә ҡылайуҡ, анлардан узуб. Залим булсалар да, эш анлар ҡулында. Әгәр анлар угрыны туғры, туғрыны уғры, риза дәгүллекемезне риза дию падишаһ хәзрәтенә мәғлүм итсәләр, эш-сүз анлар дикәнчә уладур. Вә иллахәсса падишаһның үз җәнебендән һич дә золомлыҡ хәбәре ишетүлмәйдүр. Әгәр эшләремезнең хәкиҡәте гома һүәхаҡә падишаһымыз хәзрәтенә мәғлүм улунса иде, ләғәллә барча эшләремез хәйер улур иде, диде[33].

Бәғзесе әйтде: «Падишаһны залим димәймез, падишаһ ғаделдер, вә ләкин үз ҡуйынундан китмәгән, безгә килүб етмәгән ғаделлегендә безгә ни файда? Һәр кемнең ҡулы еткән ергә күзе етмәз булурму? Күрәсез кем, безнең ҡулумыз ҡысҡадур, йорт-кәртәмездән тышҡа узмайдур. Йортомыз эчендә бер ҡузының аяғын сынған күрсәк, аны бәйләймез. Шуның тик без һәм падишаһның ҡулы астындамыз. Әгәр хәкиҡәт падишаһлык тикшереүе илә тикшүрсә, күзе етмәзму булур иде? Вә илла без йортомыздан узмаған ҡысҡа ҡулымыз берлә түрәләр янараллар ашасындан эшемезне вә халларемезне качан падишаһ хозурына етештүрә алурмыз» диде.

Бәғзесе әйтде: «Әүүәл-әүәлдән ишүтә, күрә киләмез, залим түрәләрнең мондай хәд вә ғәйәтдин кичкән золомлыҡ[34] хәбәрләре вә һәм халайыҡларның бу кәдәр рәнжемәк хәбәрләре падишаһ хозурына мәғлүм улмаз, ул залимларнын үзләре эшләгән тик аңларга эшләмәйенчә[35]. Бәс, анлар безнең дине-мезне хурласалар, безне үз динләренә көчләсәләр, әүүәлге падишаһларымыз ғәһедендәге хеҙмәтләремезне үзгәр-түб[36],//малымызны, милкемезне тәләф итсәләр, безгә ни үфкә булур? Без һәм анларның динләрүне хурлаб, үз динемезгә өндәйүк, малларуны тәләф идәйүк, хәбәрләремез падишаһта ирүршүр, эшләремезнең вәжәһе камиллек вә ғәделлек берлә тикшүрүлүр. Әүүәл-әүүәлдән безнең башҡортларымыз урусдан бер җәфа күрмәйенчә, тибрәнмәй торган. Әүүәл-әүәлдән мондай эшләр булган вакытда падишаһдан рәхимле указ килә торған: «Башкорт колларым, сезне ярлыкадым, ул сезгә золомлыҡ ҡылған усаллар эт үлемендә үлделәр, сез йортоңозда әман тороңыз», — диб. Халайыҡлар фетнәләр(дән) ҡотолоб, йорт әман була торған иде», — диде.

Бәғзесе әйтде: «Безнең халемездән Нуғай юлы халҡының хале мөшкөлөрәкдүр. Янарал берлә мирза Оренбурға яҡын тора торған башҡортларның жанларуны алурға етүшәләр. Бөтөн йәйләй бүрәнә, дыранча, ҡабук ташутуб биләгән ерләренә, агачларына көчлек идуб[37]. Ул түбәдә уғын яза атмаған, аты ергә ятмаған данлы чаблы Алдар иде. Имде аның аймағы ҡачан кафырның бу фетнәләрүнә чыдасун», — диде.

Бәғзесе әйтде: «Кафырның бу фетнәләре вә бу зәхмәтләре башҡортларғамы үтмәде вә мишәрләргәме үтмәде? Бу зәһәрләр барчамызға үтде. Имде башларымызны бер айруб алсаҡ бу вафасыз залим кафырның ҡултуғына икенче ҡачан баш индүрүрмез? Ошбу күрдүкемез фетнәләр безгә етәрлүк ғибрәтләр дәгүлмедүр?» — диде.

Вә бундин башҡа һәм ҡайсы ыстаршиналарның камандасында иске вә яны ни фетнәләр пәйда булғандур, аны яд идүб сөйләделәр. Мәжлес тамам булды; тордылар, көрәш майданы ҡордылар[38]. Пәһлүәнләрне көрәшдүрделәр. Үзләренең ҡағидәләренчә баһадирларға жөғәлләр бирделәр. Андин исәнләшүб китдүк. Бу мәжлесдәге сүзләрдән халайыҡлар райы нитаклеге бер аз мәфһүм улды.

## Искәрмәләр

[1] В рукописи: ғәйреләр.

[2] В третьем черновике: бән азәл алғибад (л. 117).

[3] Цитата из Корана: сура IV, стих 62.

[4] Во II черновике доношения: Әммә халайыҡлар нәсаих мәҙкүрәне жан вә дил илә рәуа күрсәләр дә вә ләкин нәжмән-нәжмән, йәғни йылдан-йыл, айдан-ай, көндән-көн ул нәсихәтләр мужәбәнчә ғәмәл итмәкдән тәҡсир вә тәҡәғәд күстәрмәкне ағаз ҡыла башладылар. Нәсихәтләрдән нәфрәт вә иғтираф итмәкне аңдырдылар вә буйлә әйләмәкләренә бер ничә мажараларны ғилләт тотдылар (л. 117).

[5] В III черновике доношения: Ишетүлә вә белүнә башлады әхбаре ҡәриһәләр вә хауадиҫе ҡабихәләр, йәғни егрәнечле хәбәрләр вә бозоҡ эшләр. Шундай ҡәриһәләр вә ҡәбихәләр кем сәбәб вә ғилләт әүлә халайыҡларның мәнеғләнмәкенә. Йәғни юҡаруда ҙекер ҡылунған нәсихәтләрнен бәғзесенә ҡабул итмәкдән мәнеғләнмәкенә.

[6] Во II черновике доношения: Ул ғиллотләрдән берсе (л. 117).

[7] Во II черновике доношения: жәбрән вә ҡәһран.

[8] Во II черновике доношения: Ул ислам динендән чыҡҡайларның ясак хезмәтләрүне ҡалған мосолманлар өстүнә салмаҡ хатта ул ҡалғанларны таҡәт улуб һәм динләрендән чыҡсунлар диү хатта кем хәуас вә ғәуам телендин жари улды кем, ҡадими падишаһларымыз заманында мундай хур вә жәфалар вә буйлә нәҡес ғәһедләр юк ирде. Мәхыз бу падишаһымыз заманында бу жәфалар вә бу ғәһедне нәҡес ҡылмаҡлыҡлар пәйда улды (л. 117).

В другом черновике эта фраза сохранена, но имеется следующее добавление: Ҡәрһәт һәҙа алламыр гәли минлә әдне тәьмел (л. 113).

[9] В черновике приведён тот же текст, но с добавлением в конце следуюших слов: Вә ул мәнеғ ҡылунмаҡның ғиуазына башҡорт жәмағәтләренең гәһди ҡадимдәй бер ғәрефчә өстләренә лазым итүб вә лазым ҡылуб түләй торған ясаҡларуны ташлатулдылар. Вә мишәрлардин һәм екерме бишәр тин түләй торран ясакларуны ташлатулдылар. Ул шундай ясаҡдур кем, бу тоз мәнеғләнмәк фетнәсендән ике йыл миҡдары борон ғәһде ҡәдимдә ул ясаҡ анлар өстүнә лазым дәғүл икач, ул ясаҡны түләмәкә көчләгәнләр ирде. Вә һәм жәмағәтләр өстүнә дә ошондағ уҡ артдурылған ирде (л. 113).

[10] В III черновике доношения: Ошбу мәҙкүр кем, мәнеғлеккә, йәғни тозларны ходай хәзинәсендән алыуны мәнеғ ҡылыуга барча мосолманлар — башҡортлар, мишәрләр, ясаҡлылар, — хәуас вә ғәуам риза булмадылар. Мәгәр бәғзе залим ыстаршиналар сотниклары берлә берүгүб, тикүз халайыҡларның киңәшүнә вә сүзенә илтифат итмәйүб, үзләре тик залим түрәләр берлә берүгүб

ризалыҡ языуны бирделәр, ҡуллар ҡуйуб, тамғалар салуб. Вә һәм ыстаршиналарның, сотникларның күберәге йорт ҡайғусин күрүб халайыҡларга яхшылыҡ, аманлыҡ вә әсанлыҡ булыуына һиммәт иткүчеләре риза булмайуб ҡәлғәләрдәге түрәләргә ризасызлыҡ жәуабын бирделәр (л. 113).

[11] В IV черновике доношения: йәғни падишаһ хәзрәтләренең ғадәләте вә мәрхәмәте бин әләнәм әғла(м) вә әғлан ҡылғудай жәуабны этнең бер ғеүләүе вә бер өрүе еренә ҡуймайуб шаһ ғадәләтне вә мәрхәмәтне мәхү вә мәстүр итмәк тик (л. 105 об.).

[12] В IV черновике доношения: Шул рәүешле фетнә вә хәйләләр ҡыла торғач (л. 105 об.).

[13] В III черновике доношения имеется добавление: хатта ки бу тоздан мәниғланмак фетнәсе халайыҡлар арасында олуг ҡәраһат вә олуғ нәфрәт вә олуғ ғауға улуб, барчалар зари тәзрих ҡылуб әйтүшделәр: «Эй, хәзрәт, эй ниғәмәт, нә ҡылайык вә кемгә зарланайыҡ вә кемдән дад теләйек. Ағаларымыз рәхимсез вә түрәләремез рәхимсез залим улдылар вә падишаһымыз жанубындан гелән рәхмәт йәғмурун өстүмезгә йәғдурмадылар. Һанузда падишаһымыз хәзрәтләренә баруб зарилыҡ ҡылуб мәрхәмәтләр, ғадел вә дадлар теләр ирдүк вә ләкин ул эш һәм мөмкин дәгүл. Аның өчөн кем ул рәхимсез залим ыстаршина вә түрәләр сезләрне ҡачан ебәрсүнләр, үзләренең эшләрүн ҡачан туздурсунлар (л. 111 об.).

[14] В IV черновике доношения: Һәр хәдисәләрдә халайыҡлар ғәдел вә дад эстәмәккә бармаҡдан өмидләре киселмәк, йортдағы залимларның залимлыҡ жәфасын чикмәк тик (л. 105 об.).

[15] В III черновике доношения: Ике бер тугма кенәзләрнең (л. III об.)

[16] В III черновике доношения: бәғзесендин илле-алтмыш сум вә нитак кем алмаҡ мөмкин булса алдылар. Байларның малы түкәнде, ярлылар бурычлы булдылар (л. III об.).

[17] В III черновике доношения добавлено: Алай булса да күбләр эше тамам ул-майуб өйәзгә солохлыҡға чыҡдылар. Паспурт алыучылардан һәм берәр-икешәр сум алдылар. Хатта алар хозурына баруб ғәдел вә дад эстәмәкдән халайыҡларның өмиде киселде (л. III об.).

В V черновике: Былайдә күп дәғүәчеләрнең эше тамам улмайуб өйәзгә солохлыҡҡа чыҡар улдылар.

[18] В III черновике доношения: Вә дәхи юкаруда яд кҡылунған өч гғилләт кә табығлар жөмләсендәндер ошбу кем тарафларға үзүб йөргуче юмушлы урусларнык бәғзеләре һәм халайыҡларга би хәд вә би ниһайәт жәфалар күргәзәләр, ҡыйнамаҡ, суҡмаҡ, алум алмаҡ берлә, малларны уғырламаҡ берлә вә һәм кешеләрне үлтүрмәк берлә. Яныш камандасында Туҡтар ауылынын Туҡтарны уҡаздан артуҡ ылау бирмәгән өчөн бер башлыҡ рус ағыулы шараб эчерүб ултүрде. Вә һәм Сөләйман камандасында Субай ауылынын бер кешене ылау озата барғанда юлда драгунлар ҡыйнаб үлтүргәнләр. Ҡайсыларны әйтүб тукатайун. Хатта ошбу юлымызда Өфө ҡәлгәсендән Оренбургға килгәндә Табун (это слово, ввиду отсутствия точек над и гюд буквами, можно читать также: батун, ятун, яйун, ҡайун и т.д.) күле дигән күл януна кич ҡунарга төшкән ирдүк. Оло юлдан бер башҡорт узуб барадур. Бер аруҡ ат арбаға еккән, ат өстүнә үзе атланған вә хатуны арбаға ултурған. Безнең туғрымызга еткән ирде, руслар баң ордылар. Ул

башҡортның өстүнә ике урус ат менуб чауыб бардылар. Башҡорт атын ҡамчылаб ҡачды. Әммә аты ғәйәт бик тәкәтсез аруҡ ирде. Ул ике уруснң берсе етде. Ул башҡортның арҡасына утыз миҡдары ҡамчы орды. Ошбу уземезне алуб килә торған капитан вә һәм парутчик вә һәм Өфө кәлтәсенең Ҡараклар (?) ҡарауыл сутниге барчалары бан оруб, ботлар чабуб көлешәләр, һич берсендә дин хәүефе юҡ вә донъя хәүефе. Ул мескен башҡортны бер олуг бәләгә зәхмәткә уғратдылар. Андин сун шул юлда ук «башҡорт, башҡорт» дию куб мәртәбә бан ордылар. Вә ләкин мәнем өстүм мәстүр иде. Күзем илә күрмәдем. Андин сук Саҡмар белә Оренбур арасында бер татар очрады. Бер ҡулында бер чиләк сыу, икенче ҡулы берлә атын тотоб барадур ирде. Драгунлар баруб сыу сурадылар, бирмәде. Көчләй башладылар. Ул татар әйтде: «Көчләмәгез, мин дә сезнен тик падишаһ хедмәтендә торамын, юлаучыларны ҡачан булдурурмын, муна төшәр еренез бер чакрум көчләмәнез, диде. Драгунлар биш кеше булуб тартҡалай башладылар, сыу түгүлде. Ҡамчы берлә ҡыйнай башладылар. Бер түрт суҡҡанлар ирде, тиз атына сикерүб менде, ҡачды. Ике драгун бер айча ер ҡыуды. Әммә аты сикертән икән, еткүзмәде. Мундаҡы үзгә ахмаклары ҡычкыручуб көлөшөб торалар, ҡайсы берен әйтүб туктатайын (л. 111).

[19] В IV черновике доношения: Золом вә жәфалар хәд вә ғәйәтдән кичкән мәртәбә энәләрендә һич дә ғаделлек ҡалмады. После этих слов в рукописи того же черновика имеется еще следующая зачеркнутая фраза «бу ҡәдәр мескен мосолманлар кем хозурында зарлануб ғәдел вә дад эстәсүнләр» (л. 105 об.).

[20] В IV черновике доношения: бозок эшләрнен сәбәбендән халайыклар дин донъясына мәгәзәтләр ирүшкүб (л. 105 об.).

[21] В III черновике доношения: Шайәд ки падишаһ хезмәтенә хазыр улуб торайыҡ, диб төзи торғандыр дию.

[22] В III черновике доношения зачёркнуто и заменено следующими словами: Хатта ки ул мәҙкүр ыстаршина Мөслим ауылына баруб етдем (л. 110 об.). Помимо этого, и зачёркнутая часть черновика не вполне совпадает с окончательным текстом. Так, последняя фраза, начинающаяся словами «Бу көндә «чәнче йәй тамам улды», передана также несколько в иной редакции: Миһманлыҡка өндәмәкләре һәм бар иде. Йортомны ташлаған йәйдән элгәрүге йәй ошбу йәй өчөнче йәй буладур (л. 110 об.).

[23] В III черновике доношения после этого имеется следующее зачёркнутое место: миһманлар ҡымызларның әҫәрендән вә хуш ауаз шағирлар шиғыр әйтүб вә шараб ләзиз мәтхир дел ауазның әсәрендән сәрхушлыҡлар хасил улуб шадлыҡлар ҡылдылар (л. 110 об.).

[24] В III черновике после этого имеется следующее зачёркнутое место: сөал әйдәделәр. Ғәбәдәтдин вә мөгәмләтдин вә тәхсир вә хәдиҫләрдин сарыф вә нәхү(дән) (л. 110 об.).

[25] В III черновике доношения после этого слова имеется следующее зачёркнутое место: Фи әлжәмлә бән фәҡир бәндәнең интизары ул ир дикәм ул мәғлүм. Гизлү серләрдән, йәғни тарафлардаҡы халайыҡларның ҡораллар төзөмәк серләрүн халайыҡларның раънта икән. Ҡораллар төзөмәк жәһәтендән ни сүз вә ни гизлү сер аныҡланур икән дию интизарланмаҡ иде. Вә ләкин ул тарафдан һич сүз сөйләнмәде мәгәр ки. Үзләренен рузгәр кичурмәклекләренен тарлыкларын

рәнжуб әйтүшделәр. Бәс, тора торғач анлар гонаһларымыз шомлығындан залимлар ғалиб улды, бола, фетнә күбәйде. Эчә торған тозларымыз мәнеғ кылунды. Бер-беремез арасында итә торган сатуларымыз мәнег кылунды. Бер-беремез арасында итә торған сатуларымыз мәнеғ кылунды. Ике тинлек нәрсәсе булса, ҡәлғәғә сатсын дию уҡаз уҡулды. Өстөмөзгә лазым улған жәбер хеҙмәтемездән башҡа ағыр эшләр берлә өшәндүк, ғәжез булдык. Әлхал тозларымыз вә табуш итәр сунарларымыз, ара-мызда бер-беремез илә итәр сатуларымыз мәнеғ кылунды. Әгәр сунарга барур булсаҡ, берәр сумға йәки артуғырак бүләк тотоб, паспурт аламыз, Билгүле ердә, үлчәүле көндә урус билә бергә йөримез. Атымызны арутыб, тунумызны туздыруб, һич нәрсәсез ҡайтамыз. Файда итәйүк ди торгач, зыян күрәмеэ. Ике тинлек бер сатлыҡ нәрсә булса ҡәлғәғә итүб сатарға вә һәм ҡәлғәдән алурга бойоролдыҡ (л. 110 об.).

[26] В IV черновике доношения к этому добавлено: һәр йылда уҡаз киләдур, чырү кешеләре пахутка, ҡарауылға чыҡсунлар диб. Әммә пахутка барған кешеләремезне ҡарауылдан башҡа бөтен йәйнен буйуна атлары, тунлары берлә уҡаз(дан) тыш эшләр эшләтүб, ҡайусын айлар йөрөтөб, атларын кәрәкмәз эшләргә, ылауға егүб вә бундан ғәйер эшләр берлә өшәндүрүб, күбүсенең атлары һәләк булуб, йәйәғ ҡайталар. Тарыкды дин, донъя торошымыз. Ике кешенең арасына мөназаға дөшөб, ҡәлғәғә барур булса, анларны күп чыҡышлы, зыянлы, бурычлы итәләр, йәкә анларны эшен ағыр, башын китәр диб ҡурҡутуб диндин чыҡаралар йәкә бурычлы кешеләрне чуҡындырыб, мал эйәсенен малны әбдан һәләк ҡылалар. Күб мишәрләремез(не) диндән чыҡардылар. Вә һәм йәнәшә күршүмездә Салжуғут иләүендән берәүен, Өюле башҡортларымызны әһел битләре илә диндән чыҡардылар. Бер тун уғырлаған вур(ны) попның баласы берлә Тубул архәрайына ебәрүб, күб жәфалар күргәзүб. Далее в рукописи зачеркнуты следуюшие слова: эссе пичләргә салуб (л. 110).

Ир үтәлмәҫ йылға юҡ, теләнмәгән мулла юҡ.
Иртә намаҙ, кис тә намаҙ — ҡаҡҡан ҡаҙыгың ҡалмаҫ.
Ишан сәлләһе аҫтында ат урларға югән бар.
Ишанға ҡул биргән — шайтанға юл биргән.
Йыландың тәпәйен күрмәҫһең, мулланың әпәйен күрмәҫһең.
Йәне көйгән тәңреһен ҡарғаған.
Кеҫәң бай булһа, муллаға кермә.
Көслө хоҙай менән алышыр, көсһөҙ эшен әхирәткә тапшырыр.
Көтмә алланан, көт балтанан.
Ҡабул булмаҫ доғаға амин тотма.
Ҡараҡ ҡаргана, мулла зарлана.
Ҡараҡ менән муллаға бары ла хәләл.
Ҡараҡ урлап, мулла юллап, түрә алдап ашай.
Ҡараҡ — әҙәм көлкөһө, мулла — ауыл төлкөһө.
Ҡараҡты ютәл, мулланы тамаҡ харап итә.
Ҡасҡан да «алла» тиер, ҡыуған да «алла» тиер.
Мал үлһә — ҡоҙғонға ем, әҙәм үлһә — муллаға ем.
Мин тигәнгә алла бар, туң тимергә балта бар.
Мулла аҙһа, мәхәлләгә ни һан?
Мулла аласағын онотмаҫ.
Мулла алыуын белер, биреүен белмәҫ.
Мулла белгәнен уҡый, тауыҡ күргәнен соҡой.
Мулла «бир» тигәнде ишетмәй, «мә» тигәнде ишетә.
Мулла ҡорһағы — хәйерсе ҡапсығы.
Мулла ҡунған — мул кергән.
Мулла менән дуҫ булһаң, саҙаҡаң кеҫәңдә булһын.
Мулла менән түрә ил өҫтөндә көн күрә.
Мулла менән һыйыр ашауҙан туймаҫ.
Мулла менән шайтан бер юлдан йөрөй.
Мулла мулланы һөймәҫ.
Мулла үҙе урлай, үҙе юллай.
Мулла үлеме тамаҡтан, эскесе үлеме ҡабаҡтан.
Муллаға — маҙар, сауҙагәргә — баҙар.
Муллаға тел тейҙерһәң — телең киҫелер,
Турәгә тел тейҙерһәң — ҡулың киҫелер.

Мулланан аҡыл һораһаң, аҡтыҡ атыңды һорар.
Муллапан — доға, мужиктән — дуға.
Мулланан мулла тыуа, юрғанан юрға тыуа.
Мулланың ҡорһағы — ҡырҡ ҡолас.
Муллапың ҡорһагы һигеҙ ҡуй тиреһенән тегелгән.
Муллапың нәфсеһе бер батман.
Мулланың әйткәнен тыңла, ҡылғанын ҡылма.
Мәзин мулланың үлгәнен теләр.
Наҙан мулланың сәлләһе ҙур булыр.
Насар арба юл боҙор,
Насар ҡуштан ил боҙор,
Насар мулла дин боҙор.
Суфый күп ерҙә шайтан күп.
Суфый һуган һөймәҫ, күрһә, ҡабығын да ҡуймаҫ.
Тинтәк мулла — тилергән үгеҙ.
Түрә барҙа «малым бар» тимә, мулла барҙа «ауырыуым бар» тимә.
Түрә приказ менән, мулла указ менән.
Тәңре эше фарман менәп, бәндәнеке — дарман менән.
Урманға барһаң, балтаңды, муллаға барһаң, ҡалтаңды онотма.
Ут утындан, куҙ ҡарауҙан, мулла береһенән дә туймаҫ.
Хайуан үлһә — ҡарға шат, әҙәм үлһә — мулла шат.
Халыҡ наҙан булһа, муллаға төшөм.
Хоҙайҙың биргәненән бирмәгәне күп.
Хоҙайҙың ҡөҙрәте киң.
Шәриғәт сей тире кеүек: күпме тартһаң да һуҙыла.
Шәриғәттә оят юҡ.
Ырымбурҙа арба күп, Ҡарғалыла мулла күп.
Этҡә һөйәк, муллаға ит бир.
Этһеҙ ауылда мулла таяҡһыҙ йөрөр.
Ярлы беләгенә, мулла теләгенә ышаныр.

* * *

Алланан йәйәү ҡасҡан — муллаға килеп ҡапҡан.
Аңҡау ауылға арамъя мулла.
Башы саллалы, аҡылы самалы.
Динем өсөн түгел, көнөм өсөн.
Кем үлһә лә үлһен, мәзингә фидия булһын.
Мулла ла алла түгел, беҙ ҙә хайуан түгел.
Таш мәсеткә ағас мәзин.
Тыштан сапан, эстән шайтан.
Уҡымай мулла булған, суҡымай ҡарға булған.

Башҡорт халыҡ ижады. Мәҡәлдәр һәм әйтемдәр.
Төҙөнө Ф. А. Надыршина, Өфө, 1980.

**Габделжаббар Кандалый**
**(1797-1860)**

Г. Кандалый вошёл в татарскую литературу как один из первых поэтов, положивших в основу своего творчества язык и способ мышления простого народа, стал писать стихи, «пахнущие мужицким навозом». Знаменательно, что даже значительно позже на упрёк, почему же при отличном владении родным татарским языком он пишет свои труды на фарси, арабском, Ш. Марджани ответил, что опасается потерять своего читателя — образованную духовную прослойку нации. Тем удивительнее, что через стихи также муллы-поэта в литературу вошёл простой человек со своими представлениями о прекрасном, со своими буднями, тревогами и заботами.

Так был сделан решающий шаг в сторону демократизации литературы, расширения читательской аудитории.

Родился будущий поэт в д. Старый Кандал (отсюда и тахаллус) Самарской губернии (ныне д. Иртуган Старо-Михайловского района Ульяновской области) и воспитывался в семье высокообразованного муллы в атмосфере знаний и творчества. Дав начальное образование сыну дома, отец отдаёт любознательного беспокойного сына в разные медресе своей округи. Судя по ранним стихам, сатирическая направленность которых стала основой его творчества, будущий поэт критически относился к царившим в этих учебных заведениях порядкам. Тем не менее он глубоко усваивает классическую арабскую и персидскую литературу, самостоятельно изучает русский, чувашский, мордовский языки.

В 27 лет он становится муллой в родной деревне, одним из первых заводит сад и огород, добивается проведения в деревне водопровода. Независимый, острый на язык, стремящийся к преобразованиям мулла-поэт вносит в своё окружение атмосферу беспокойства, стремления к знаниям.

Исследователи татарской литературы единодушно отмечают реформаторский пафос его поэзии, где, наряду с острой критикой самодовольства духовных лиц, Кандалый широко вводит в истинную лирику образы простых земных женщин, что также становится одним из важных проявлений демократизации литературы. Таковы его циклы «Сахибджамал», «Фархинур».

Гайнуллин М. Татар әдәбияты XIX йөз.
Гайнетдинов М. Казан, 1957.
Татар әдәбияты тарихы. Т. 2. Казан, 1985

**Габделҗаббар Кандалый**
**Мулла белән абыстай**

Тотынышып кулың кулга,
Үзең кергән сары тунга,
Кая киттең болай, хәзрәт,
Абыстайны салып уңга?

Үзең түргә утыргансың,

Ауызыңны тутыргансың,
Төгәл кәефне коргансың,
Абыстай утырып уңга.

Сәнең өчен тавык чалган,
Суган, балтырганын салган,
Сән әйткәч, чакырып алган,
Егермесен сатып унга.

Качырма сән бу форсатны,
Чәеңә сал бауырсакны,
Тутыр бик яхшы корсакны,
Икенче калмасын соңга.

Сәңа атап тавык суйгач,
Ашап-эчеп тамак туйгач,
Кесәгә ун тиен кунгач,
Чәй эчеп төн буе кунма.

Ләкин, мулла, онытма сән,
Бу ашларга кызыкма сән,
Ки алдыңа сызыкла сән;
Мужиклар да бизәр соңра.

Сауыт-саба ышылдамас,
Бу коймаклар чыжылдамас,
Дәхи хәлвә хышылдамас,
Ки акча юк, ди-ди, онга.

Абыстай да сөйми башлар,
Катаңны да өстеңә ташлар,
Чытык йөзләр, түбән кашлар,
Чакырмыйлар нигә шунда?

Торып иртә битең югач,
Ашык-пошык намаз кыйлгач,
Берәр ашка баруны сән
Узеңә зур бәхет сандың.

Абыстай берлә икәүләп,
Мужикның сыртып игәүләп,
Тавык, күркә, казын ашап,
Ки кайтып йокыга талдың.

Тавык төштә тары күрә,

Сәнең дә ашларың кирә,
Йокыңда сөйлисең нигә:
— «Абыстай, чык, кеше кирә!»

Чакыручы түгел икән,
Бу бары төш кенә икән
Күп ашап саташып шулай
Төшеңдә сөйлисең икән...

* * *

Катаң бозга катып беткән,
Ки чаңгыдай шуып киткән,
Абыстайны да сән сөйрәп
Кай арада барып җиткән?!

* * *

Агайга сән сада салдын,
— Өйдәме? — дип, хәбәр алдың.
Икәү бергә йөреп ашка,
Гомергә көлкегә калдың!

* * *

Үзеңне зур күреп, күрмә бәни хур,
Барымызны яраткан бер хода зур.

Өмид илән каләм алды бу әлем,
Ходауәндә, кабул әйлә теләгем!

Кабул күрмәй кире вирсәң хатымны,
Ходa каршыңда сорармын хакымны!

Әгәр мәхрүм куярсән бу куендин,
Агырдыр хәсрәтем дөнья утындин.

Җаныкаем, чиләнмә сән укырга,
Күңел төшде боны һәм туктатырга.

Мөбарәк исмеңез фәлян икәндер,
Тарафындин гыйшык йиле искәндер.

Сәнең гыйшкың белән ахир үләрмен,
Фиракъең утында әксәр күәрмен.

Сәне күрдем ике күзем нурытик,
Күренәсең бәңа оҗмах хурытик.

Йибәр яулык ике башын нәгышлап,
Дәхи бер көн кауышмакый багышлап.

Кабул күрмәй кире мәхрүм кыйларсән,
Гомри гъоссә белән мәхзүн кыйларсән.

Кешегә сүзләмәдем бу сүземне,
Сабыр берлән тыя тордым үземне.

Габделҗаббар Кандалый. Шигырьләр һәм поэмалар. Казан, 1988.

## Каюм Насыйри
## (1825-1902)

Просветитель, историк, этнограф, писатель, основоположник современного татарского литературного языка. Происходил из семьи образованных потомственных мулл. Уроженец д. В. Ширдани Свияжского уезда Казанской губернии (ныне д. М. Ширданы Зеленодольского района Татарстана).

Получив первоначальное образование в мектебе отца, обучался в медресе «Касимия» в Казани. Самостоятельно овладел русским языком, через некоторое время работы в медресе открыл свою русско-татарскую школу. С 1876 года занимался лишь литературой и научной деятельностью. Многие произведения опубликованы на татарском и русском языках.

### Литература

*Насыри, К.* Избранные произведения в 2-х томах, Казань, 1974-1975.

*Гайнуллин, М.* Каюм Насыри и просветительское движение среди татар. Казань, 1955.

Выдающийся просветитель-демократ Каюм Насыри: Сборник научных докладов. Казань, 1976.

### Җәваһирел хикәят

Ошбу китап остазларның остазы имам Сүюти разыйаллаһу ганһуның «Әнисел җәлис» китабыннан тасниф кыйлынды. Мөхиб вә мөхлисләремезгә тәзкирә өчен тасниф кыйлып, «Җәваһирел хикәят» тәсмия кыйлдым. Габделкаюм мелла Габденнасыйр углы әш-Шырдани әр-Рәззакый 1299 (1882) елда. Таки дусла-рымыз өчен ялгызлыкта якын дус вә сохбәттәш булгай. Укып файда алучыларның күкрәге нур илә тулгай. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә җәмигь мөэмин вә мөселманнар белән бергә барчамызны мәгърифәт кыйлгай. Амин, би хөрмәти сәйидил-мөрсәлин. Әмма бер дә колакка ишетелмәгән ят сүзләр гакыйлга муафыйк күренмәгәндәй булса, имам Сүютинең «Әнисел җәлис» китабына нәзар

салгайлар. Әгәр хата фәһемләп, хата тәрҗемә кыйлмыш булсам, ноксаныма икърарым[1] бар, гафу пәрдәсе пәрдәләсеннәр.

Инде, әй угыл! Аллаһы Тәгалә үзенең бәндәләренә кичә-көндез 24 сәгать эчендә биш вакыт намаз фарыз кыйлды ки, ул намаз — җәмигъ гыйбадәтләрнең башыдыр. Намаз белән җәмигъ хаҗәтләр үтәлер. Бәндәдән Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт-тер. Караңгы кабердә якты чырадыр. Биш намазын тәрк кыйлгучы бу файдалардан мәхрүмдер вә ике дөньяда хур вә зәбундыр[2]. Берәү, башка изге гамәлләрне кыйлып, намазны тәрк кыйлса, ул гамәлләренең намаздан башка зәррә[3] кадәр файдасы юктыр. Намаз — баш Мәнзилендәдер. Бәс, намазсыз башка гамәлләр башсыз тәнгә охшашлыдыр. Аллаһы Тәгалә үзенең Кәлямендә әйтте: әүвәл Нәбиләрдән соң килгән кавем фарыз намазны ташладылар. Вә нәфсе арзуларына табигъ булдылар. Тиздер, кем, алар җәзага мөләкый булырлар. Мәфһүм тыйбъян.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлынды ки: берәү, намазны сәһел нәрсәгә хисаплап, җәмәгать белән укырга ялкаулык кыйлса, Аллаһы Тәгалә аны 12 төрле җәза белән гыйкаб кыйлыр. Өчесе — дөньяда, өчесе — үлгән вакытта, өчесе — кабердә, өчесе — кыямәт көнендә. Инде дөньяда Аллаһы Тәгалә аның кәсебеннән бәрәкәтне алыр; йөзеннән изгеләр нуры китәр — мөселманнар күзенә мәхәббәтсез күренер. Янә үлгән вакытында гаять сусап үләр: бөтен дөньядагы суны эчеп бетерсә дә туймас. Җаны бик катылык белән алыныр. Дәхи дөньядан имансыз китмәгендә хәвеф бардыр. Әлгаязе биллаһ. Дәхи кабердә катылык белән сөаль кыйлыныр. Кабере гаять караңгы булыр. Кабере тар булыр. Кабыргалары аралашыр. Вә һәм кыямәт көнендә сөаль вә хисап каты булыр. Аллаһы Тәгалә газап кыйлыр. Ут белән мәгъзаб булыр.

«Хөласател фәтави» («Фәтвалар җыентыгы») китабында мәз-күрдер ки: берәү азан әйткәнне ишетсә, аңа җәмәгать намазын куймага рөхсәт юктыр. Чөнки җәмәгать намазы расланган сөннәттер. Шәйлә ки: әгәр бер төбәк әһеле яки бер карья әһеле җәмәгатьне тәрк кылсалар, алар белән сугыш ваҗибтыр. Әгәр бер кавемнән берәү җәмәгатьне тәрк кыйлса, җәза ваҗибтыр. Тәрикес салятның[4] шәһадәте мәкъбуль түгелдер. Тәрикес са-лятнын күршеләре — имам вә мәзин дәхи, әгәр сөкүт кылсалар, бергә гөнаһлы булырлар вә тәрикес салятның кәсафәте күршеләренә дә әсәр итәр. Тәрикес салят өчен тәгъзирнең иң азы — өч камчы сукмактыр. «Хөласател фәтави» иясе әйтте: «Мин бер шәригать галименнән ишеттем ки, тәрикес салятның малыннан җәримә[5] алып тәгьзир кыйлыныр. Чөнки адәмгә мал җәримәсе тән җәзасыннан читенрәктер. Бу җәзалар намазны җәмәгать белән укымаган кешегәдер. Әмма билкөллия намазны тәрк кыйлган кешегә ни җәза булыр, Аллаһы Тәгалә үзе белер».

Риваятьләрдә килмештер ки: бер адәм сахрада шайтан белән юлдаш булды. Беркөн йөрделәр. Бу кеше биш вакыт намазны укымады. Кич булды. Бер җирдә ятып йокламакчы булдылар. Бу кеше йокларга яткач, шайтан бу кешедән качып китте. Бу кеше әйтте: «Ник миннән качтың?» — диде. Шайтан әйтте: «Ник качмаска: мин гомеремдә бер мәртәбә Аллаһы Тәгаләгә гасый булдым, моның өчен Аллаһы Тәгалә мине мәрхәмәтеннән сөрде — мәлгунь булдым. Син беркөн Аллаһы Тәгаләгә биш мәртәбә гасый булдың! Инде куркамын ки, Аллаһы Тәгалә

сиңа газап кыйлса, синең гыйсъяның сәбәпле миңа да каһәре тияр», — диде. Инде, әй угыл, тәүбә кыйл: тәрикес саляттан шайтан да курка, имеш!

Риваять кыйлынмыштыр ки: пәйгамбәр галәйһиссәлам сәхабәләре белән утырып торганда, бер гарәп мәсҗет капусьща килеп егълады. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әй егет өчен егъларсың?». Егет әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, атам вафат булды. Кәфенлегем юк. Юарга кешем юк, фәкыйрьмен», — диде

Пәйгамбәр галәйһиссәлам Әбү Бәкер вә Гомәр разыйал-лаһу ганһу хәзрәтләренә боерды. Мәет янына бардылар, мәетне күрделәр: кара дуңгыз сурәтендә булмыш ятыр. Кайтып пәйгамбәр галәйһиссәламгә хәбәр бирделәр: «Йә Рәсүлуллаһ без анда мәетне күрмәдек, мәгәр бер кара дуңгыз ятыр күрдек» — диделәр.

Бәс, җеназасына пәйгамбәр галәйһиссәлам чыкты. Җеназа укыды. Күрделәр: мәет үз сурәтендәдер. Аннан соң, дәфен кыйлмага, мәетне ләхет авызына китерделәр. Мәет янә дуңгыз сурәтенә дүнмеш. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әй егет, атаң дөньяда ни явыз гамәл кыйлган иде?». Егет әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, атам дөньяда һич намаз укымады, җәмәгать намазына бармады», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә сәхабәләрем, күрегез, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә тәрикес салятны дуңгыз сурәтендә кубарса кирәктер», — диде.

Әбү Бәкер Ситдыйк разыйаллаһу ганһу заманында бер адәм вафат булып, халык моның җеназасына җыелдылар. Мәетнең кәфене кыймылдап-селкенеп торыр. «Бу ни хәл?!» — дип, кәфенне ачып карап күрделәр: бер елан мәетнең муенына чорналмыш. Мәетнең итен ашап, канын суырып ятыр. Бәс, бу еланны тотып үтермәгә касд кыйлдылар. Елан әйтте: «Лә иләһә иллә Аллаһү, Мүхәммәдүр рәсүлуллаһ, ни гөнаһым бар? Аллаһы Тәгалә миңа боерды: кыямәткәчә шәйлә бу мәетне газап кыйлсам кирәк», — диде. Әйттеләр: «Бу кешенең ни гөнаһысы бардыр?» Елан әйтте: «Бу кешенең өч төрле олуг гөнаһысы бардыр: әүвәл — азан ишетте, җәмәгать намазына бармады; икенче — малының зәкятен чыгармады; өченчесе — галимнәр вә вагыизлар сүзен тыңламады. Бәс, ошбу аның җәзасыдыр», — диде.

Инде, әй угыл, Аллаһы Тәгаләнең әмерен тотмаганнарга кыямәт көнендә күп куркынычлар бардыр. Әл-хәзәр, әл-хәзәр.[6]

Мөҗәһид разыйаллаһу ганһудан риваять кыйлынды ки. «Ибн Габбас разыйаллаһу ганһу янына бер кеше килде, әйтте: «Йә Ибне Габбас, бер кеше кичләре уяу торды, көндезләре руза тотты. Әмма җомга намазына бармады, намазны җәмәгать белән әда кыйлмады. Шул хәл үзрә вафат булды. Инде бу кеше хакында ни әйтәсең?» — диде. Ибне Габбас әйтте: «Ул кеше шиксез тәмуглыктыр», — диде».

Олуг мәшаихлардан бер адәм сәфәр нияте белән чыгып, юлы дәрьяга тугыры килде. Дәрья сәфәре өчен көймәгә утырганда күрде: су хайваннары бер-берене тотып ашадылар. Бу шәехнең күңеленә килде ки: «Сөбханаллаһи, дәрьяда һәм ачлык була, имеш», — дип хәйран булды. Мәллахтан сорады: «Йә мәллах, бу ни хикмәт? Монда сер ни-нәрсәдер ки, су хайваннары бер-берсене ашадылар?» — диде. Мәллах әйтте: «Инде ун елдыр күрәмез: су хайваннары шәйләдер, бер-берсене ашарлар. Әмма ни хикмәт, ни сер бардыр, белмәдек», — диде.

Бәс, бу шәех, мөнәҗәт кыйлып, Аллаһы Тәгаләдән сорады, һатифтән бер аваз ишетелде ки: «Көннәрдән бер көн бер би-намаз, ошбу дәрьядан узганда, сусап, дәрья якасына килде. Дәрьядан су алып, авызына капты. Дәрья суы ачы, имеш, авызындагы суны яңадан дәрьяга түгеп ташлады. Бәс, бинамазның кәсафәте әсәр итеп, дәрьяда ачлык вакыйга булды. Хәтта балыклар бер-берсене ашамага башладылар», — диде.

Көннәрдән бер көн Гайсә галәйһиссәлам бер карьядән узганда күрде: гыймарәтләре төзек, агар сулары вә җимешләре күп вә нигъмәтләре мул. Вә карья әһле барчасы тагать вә гыйбадәт белән мәшгульләрдер. Маллары вә хайваннары күп. Әнваг нигъмәт белән мөнәгъгыймнәр. Гайсә галәйһиссәламне китереп, гыйззәт вә хөрмәт кыйлдылар. Вә малларын Гайсә галәйһиссәламгә гарыз кыйлдылар, әмма Гайсә галәйһиссәлам кабул итмәде, юлына китте. Аннан соң янә өч ел үткәч, Гайсә галәйһиссәлам ошбу карьягә килде, күрде: элгәреге бакчалары вә гыймарәтләре харап булмыш. Елгалары вә агар сулары корымыш. Маллары вә хайваннары юкка чыкмыш. Тагать вә гыйбадәт кыйлгучылары мәсҗетләреннән китмешләо. Йортла-рында һичкем юк. Бөтен карьяне гизде, һичберәүне күрмәде. Бу әхвәлне сорашырга кеше тапмагач, гаҗәпләнеп, Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Әйтте: «Илаһи Бер Ходая, әгәр синең каршында бу бәндәнең аз гына кадер вә гыйззәте булса да, бәян кьщлгыл: бу карья әһеленә ни булды? Гыймарәтләре вә бакчалары, вә халыклары кая китте? Агар сулары вә чишмәләре кая китте? Бер сахир юкка чыгардымы? Күз тидеме? Яки дошманнары һәлак кыйлдымы? Яки тагать вә гыйбадәтләрен ташладылармы?» — диде. Дәрхаль Җәбраил галәйһиссәлам иңде, әйтте: «Йә Гайсә, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды. Вә дәхи әйтеп ки, бу карья сихер сәбәпле, күз тйю сәбәпле, вә тагать-гыйбадәтне кую сәбәпле харап булмады, бәлки харап булды намазсыз кеше шомлыгыннан. Көннәрдән бер көн бу карьядән бер намазсыз кеше узып китте. Чишмә-суларында кулын юды вә суларын эчте. Бәс, шул намазсызның кәсафәте тиеп, бу карья һәлак булды», — диде.

Инде, әй угыл, кайчан ки намазсызларның кәсафәте дөнья гыймарәтләрен харап итсә, үзенең дин гыймарәте харап булып, кыямәт көнендә аңа булачак газап вә гокабаны Ходай Тәгаләдән гайре кем белер?

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: һәрбер булачак эшләр Ләү-хелмәхфүздә язылды. Каләм кипте. Кемнең гасый буласы, кемнең мотыйг буласы әзәлдә язылды. Бәс, әмер вә нәһинең вә ирсалның[7] ни файдасы бардыр, дисәң, әй угыл, бу мәсьәләдә күп вәҗеһләр вә күп гыйлемнәр бардыр. Кем белде, һидаять тапты. Вә кем белмәде, зәләләткә төште. Әгәр дә берәү «каләм кипте» дигән сүздән: «Аллаһы Тәгалә һәрбер нәрсәне яратып бушады», — дигән сүзне ирадә кыйлса, ул кеше яһүдиләр мәзһәбенә китте. Чөнки алар диләр ки: «Аллаһы Тәгалә дөньяны вә дөньяда булган нәрсәне — һәммәсен алты көндә яратты, җиденче көндә бушады», — диләр. Бу сүз — көфердер. Инде безнең җавабымыз будыр ки: бер заманда бер гамәл белән мәшгуль булып, бер заманда гамәлдән читтә булган һәрбер зат мәңге җумарт булмас. Аның өчен, әгәр дә шулай булса, ягъни бер заманда гамәлендә булып, бер заманда эштән бушаган булса, бәс, ул башка булды вә аның гамәленә башкалык керде ки, ул тәгъйиргамәл вә фәрәгатьтер вә замандыр. Бәс, Аллаһы Тәгалә тәгъйирдән вә тәбдилдән[8] ерактыр. Каләмне халк итмәседән элек ничек

иде, кипкәч тә, һаман шулайдыр. Аллаһы Тәгаләнең сыйфатында һич тәгъйир булмас. Аллаһы Тәгалә әбәдән[9] эштән фаригъ булганы юк. *«Күллү яумин һүвә фи шәэн»* — Коръән аяте моңа дәлилдер.

Бәс, белгел ки, әй угыл, һәрбер нәрсә Аллаһы Тәгаләнең ирадәсе белән вә теләмәке беләндер. Һичбер нәрсә, һичбер хөкем, һичбер әмер, һичбер гамәл Аллаһы Тәгаләнең Ирадасеннән вә сангыннан тыш булмас. Вә дәхи нитәкки Аллаһы Тәгаләнең заты һичбер мәхлук затына охшамас, эше-сәнгате, һичбер гамәле дәхи мәхлук эшенә вә мәхлук гамәленә охшамас. Мәхлук ни-нәрсә кыйлса, Аллаһы Тәгаләнең һәм эш-сәнгате аның гамәленә бәйледер. Ягъни бер нәрсәне эшләп, бәндәнең ул гамәленә вә ул фигаленә[10] мокабил вә мокарин икенче бер нәрсә иҗат кыйлыр. Хәлбуки ул нәрсәне эшләмәктән бәндә гаҗиздер. Аны эшләмәгән бәндә әбәдән кадир түгелдер. Мәсәлән, бәндә бер локмәне алып, авызына капмага вә чәйнәмәгә кадир. Әмма локмәгә ләззәт бирмәгә кадир түгелдер. Ягъни бәндәнең чәйнәмәгенә мокарин ләззәт бирмәк — Аллаһы Тәгаләнең эшедер. Вә дәхи бәндә үзенең хезмәтчесен сукмага кадир. Ләкин оялуны, үкенүне иҗат кыйлмак бәндә эше түгелдер. Бәндәнең сугуына үкенүне Аллаһы Тәгалә халк итәдер. Бәндә иген икмәккә, җиргә орлык сачмага кадирдыр. Әмма ул орлыкны ти-шелдермәгә вә үстермәгә кадир түгелдер. Вә дәхи бәндә җимаг кыйлмага кадирдыр. Әмма җимагда ләззәтне иҗат кыйлмага вә бала булдырмага кадир түгелдер. Бәс, бәндәнең һәрбер сангында Аллаһы Тәгалә сангының дәхеле бардыр. Хәлбуки бәндә андан гаҗиз иде.

Инде, әй угыл, бу бабта сүз күптер. Бу кадәресе кифая[11]. Вә дәхи Аллаһы Тәгаләнең сангы бәндә сангына охша-магынлыкы Нәмруд утында, вә дәхи корбан Исмәгыйльдә, вә гассаэ Мусада бик заһирдыр. Ягъни Нәмруд Ибраһим галәй-һиссәламне утка аткач, Аллаһы Тәгалә утның эсселеген алды, бакча кыйлды. Вә Ибраһим галәйһиссәлам углы Исмәгыйльне зәбех кыйлганда, Аллаһы Тәгалә пычакны кисмәс итте, кыйссасы мәшһүрдер. Вә дәхи Аллаһы Тәгаләнең сангыннандыр: тагатьтә — мәгъсыять вә мәгъсыятьтә мәгърифәт зоһур итәдер. Мәсәлән, иблис тагатьтә иде, тагате гыйсъянга монкалиб булды. Вә сихерчеләр Фиргавен гыйсъянда иделәр, Аллаһы. Тәгалә аларда бер мәгърифәт иҗат кыйлды: хаклыкны белделәр — Муса галәйһиссәламгә иман китерделәр.

Кайчан ки Муса галәйһиссәламгә «Тәүрат» инде. Муса галәйһиссәлам «Тәүрат»ны укыр иде вә «Тәүрат» белән Мөшәррәф булыр иде. Бәс, көннәрдән бер көн Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Йә Муса, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды вә Дәхи әмер кыйлды ки: Бәни Исраилне җыйгайсың вә минбәргә менгәйсең вә кауменңне вәгазь кыйлгайсың. Кауменңнән кем дә кем һидаятькә әһел булса, һидаять кыйлынып, рәхмәткә васыл булсыннар», — диде.

Бәс, Муса галәйһиссәлам минбәр куйды: Бәни Исраилны җәмгы калды. Менә берзаман сәясәт вә тәкәбберлек белән зиннәтле нәфис вә бизәлгән киемнәр киеп, вә хәзинә ачкычларын кырык тәвәгә йөкләп, вә дәхи алтын-көмеш белән мөзәййән атларга атланган өч мең коллары белән Муса галәйһиссәламнең вәгазь мәҗлесенә Карун килде. Нитәкки фәхраҗә галя каимиһи фи зиннәти — Коръәндә мәзкүрдер.

Инде, әй угыл, әгәр голяма мәҗлесенә бармак теләсәң, сиңаваҗибтыр ки, тыйнаклык вә түбәнчелек белән вә инкисаре калеб белән барырсың. Кем дә кем

голяма мәҗлесенә бу сыйфатта барса, Аллаһы Тәгаләдән мәгъфирәт[12] табар. Әгәр Карун сыйфатында тәкәбберлек өчен зиннәтләнеп барса, Аллаһы Тәгаләдән киселеп, җәзага улашыр. Нитәкки күрдеңме, Карун сәясәт, вә тәкәбберлек, вә зиннәт белән килде. Фәкать дөнья тереклеген ирадә кыйлгучылар аңа аяк үзрә тордылар вә аны тәгъзыим вә тәкрим кыилдылар. Бәс, Муса галәйһиссәлам аларны бу эштән мәныг кыйлды: «Бу ярамас гыйлем вә вәгазь мәҗлесендә шәйлә тәкәллафләнмәңез», — диде. Кемдер, Муса галәйһиссәламнең сүзен кабул итеп, Карунга аяк үзрә тормады, Муса белән бергә нәҗат тапты[13]. Карунга тәвазыйглык кыилып, тәгъзыим вә тәкрим кыйлганнар Карун белән бергә караңгы булдылар, ягъни Карун белән бергә барчасын җир йотты.

## Искәрмәләр

[1] Ноксаныма икъgraрым — кимчелекле булуын тануым.
[2] Зәбундыр — куәтсездер.
[3] Зәррә — бөртек.
[4] Тәрикес салятның — намаздан читләшүченең.
[5] Җәримә — штраф.
[6] Әл-хәзәр, әл-хәзәр! — сак бул!
[7] Ирсалның — язу җибәрүнең.
[8] Тәгъйирдән вә тәбдилдән — үзгәртүдән вә алмашынудан.
[9] Әбәдән — мәңге.
[10] Фигаленә — фигыльләренә, эшенә.
[11] Кифая — җитәр.
[12] Мәгъфирәт — ярлыкау.
[13] Нәҗат тапты — котылды.

## Каюм Насыйри турында истәлекләр

Татар халкының тарихчы галиме Габделбари Баттал «Йолдыз» газетасының 1912 ел 11 октябрь санында «Телебез» исемле зур мәкалә .бастыра. Мәкаләдә гомумхалыкка аңлаешлы әдәби тел булдыру кирәклеге күтәрелә. Бу юлда иң тырышып эшләгән галимебез итеп автор К. Насыйрины күрсәтә. «Үз арабыздан чыгып, үз телебезне тергезү нияте белән кулына каләм тоткан затларыбызның иң олугысы Габделкаюм әл-Насыйри абзыйдыр. Аның хезмәтләре татар теленең фән теле була алуына ышандыралар», — ди ул. Шушы олуг затка матбугат битләрендә игътибар булмавы, инде аның исемен татар милләте онытып баруы турында ачынып яза. Мәсәлән, «Шура» журналы һәр санында диярлек күренекле кешеләрнең тормыш юлларын яктырткан мәкаләләр биреп барса да, бу мөгътәбәр затны искә дә алмый, дип, редакция исеменә дә кисәтү ясый.

«Шура» мөхәррире Риза Фәхретдинов Г. Баттал мәкалә-сенә каршы язган аңлатмасында («Шура», 1912 ел, 21нче сан) моңа материал юклыгын сәбәп итеп куя. К. Насыйри турында мәгълүматлы кешеләр булса, журналга язып җибәрүләрен үтенә. Нәтиҗәдә, «Шура»ның 1912-1913 елгы саннарында бу мәгъ-

рифәтче галимебез турында байтак истәлекләр, биографиясе-шәҗәрәсе, туганнары турында мәкаләләр басыла.

Күрәсең, Г. Баттал мәкаләсе тын яткан матбугатны кузга-тып җибәрә. Биредә шул истәлекләрнең берничәсен тәкъдим итәбез.

Шунысы игътибарга лаек: истәлекләрнең күбесен хәзер биографияләре дә онытылган, Казаннан читтә яшәгән мөгал-лимнәр, муллалар язган. Алар Казанга килгәч, К. Насыйри янына махсус кереп, хәлен белеп, сөйләшеп утырганнар, яисә бәйләнеш тотканнар. Димәк, матбугатта яктыртылмаса да, галимнең исеме, үзе исән чакта ук, еракларга билгеле булган. Монда керми калган истәлекләрдә К. Насыйри исемен Төркиянең танылган язучысы Әхмәт Мидхәт искә алуы турында әйтелә. Кырымның атаклы җәдит мәдрәсәсе Зынҗырлы мөгаллимнәре дә аны телгә алып сөйли торган булганнар.

Һәр каләм иясевең иҗат җимеше өстенә шәхси тормышы да бар бит әле. Һәр кеше кабатланмас җанлы шәхес. К. Насыйри биографиясен, шәхесен беләбез дип булмый. Истәлекләрдә К. Насыйри кабатланмас шәхес буларак та, галим буларак та тулы ачыла. Бу язмалар мәдәни тарихыбыз өчен дә әйбәт кенә чыганак булырга лаек.

Кайбер талант ияләре, иҗат эшенә артык бирелеп китеп, көндәлек тормышларына, үзләренә бөтенләй диярлек игътибар итмиләр. Истәлекләрдән чыгып фикер йөрткәндә, бездә шундый ике талантны — Г. Тукай һәм К. Насыйрины күрсәтергә мөмкин. Әлеге истәлек авторлары, мәсәлән, К. Насыйриның өс-баш киемнәрен, фатирын, яшәү һәм эшләү рәвешләрен, тышкы портретын, холкын-фигылен җентекләп тасвирлыйлар. Аның үз шәхси тормышына игътибарсыз булып, фанатикларча фәкыйрь гомер кичерүен күреп бераз кызганалар да кебек. Шушы зур галим турында уз вакытында аз гына да кайгыртучанлык күрсәтмәгән татар халкына да үпкә сүзләре әйтелә.

Истәлекләр, гомумән, мактау, күпертеп күрсәтү тонында язылмаган. К. Насыйриның характер кимчелекләре, хезмәтлә-рендәге кайбер хаталары да искә алына, ул иҗат эшеннән башка бер нәрсә белән кызыксынмый. Кыскасы, истәлекләрдә аның галим булып өлгереп җиткән чоры яктыртыла. Туган халкын агарту юлында һәртөрле дөнья ләззәтләреннән ваз кичкән, «Мине алла китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», — днп фикер йөрткән кин белемле, ләкин фанатик галим күз алдына килә. К. Насыйриның дөнья күрми калган хезмәтләре дә булырга тиеш, — истәлекләрдән шул да аңлашыла.

Фатыйма Ибраһимова.

## Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләр

## I

1898нче сәнә, май урталарында остазымыз Фәйзелрах-ман хәзрәт илә (Өчбүлә карьясенең.)[1] Уфа, Ырынбур, Самар, Казан кеби урыннарыны сәяхәт итеп йөрдек. Казанга барып төшкәч тә беренче зиярәт иткән адәмемез Габделкаюм әфәнде Насыйри улды. Екатеринский урамда[2], сул якта, Аитов йортында[3], сул тарафта кечкенәрәк бер агач йортка кердек. Бер бүлмәне үтеп

икенче бүлмәгә кергәч, ике тарафта туп-тулы яңа табгыдан чыгып өелгән китап уртасыннан тар гына юл киткән. Аяк астына яшел үлән җәйгән мисалында төрле чәчкәләр тутырган дивар тузанлы, пакизә түгел. Түрдәрәк, урталыкта, борынгы мәдрәсәләрдә тотыла торган тәбәнәк өстәл, өстенә бер нәрсә дә җәймәгән. Өстәлдә ике касә вә бер такмак шикәр, бер телем арыш икмәге, самавыр бар. Ләкин самавыры җизме, бакырмы — беленерлек түгел, кап-кара керләнгән. Шул өстәл янында Бәләбәй өязе Бурангол башкорты рәвешендә киң якалы күк киндер күлмәк кигән, изүендә якасы бау белән бәйләнгән, башында балан каш кебек түбәтәй, аягын бөкләп утырган Габделкаюм әфәнде чәй эчәдер. Бер ягында ачылып куелган китап бар. Сәлам бирдек во барып күрештек. Галәйкем әс-сәлам — алды. Салкынрак рәвештә: «Сез кайдан буласыз?» — дия сорады. Остазымыз үземезне тәгъриф итте. «Утырыңыз!» Утырдык. «Чәй эчәсезме?» «Вакытымыз юк», — дия гозер күргәздек. Сүз юк. Янә бераздан соң әсәрләре хакында сүз кузгатып, бераз алырга ниятемез барлыгын белдердек. Шуннан соң бераз кәефе килеп, китапларыны үзе бастырырга көче йитмәгәнлегене, башка тарикъ илә кыйммәт төшеп, таралуы авыр булганлыгыны, нәширләр илтифат кылмаганлыгыны, безнең милләт уку эшене алга алмаганлыгыны, Казан — халкында хатын-кыз бозыклыгын, кием-салымда кыяфәт ал-маштыруларыны сөйләп зарланды. Казаң халкы тәкъдир кылмаса да, читтән килеп исигә төшерүчеләр бар, диеп сөйләп (җөпләп) куйды. Башкача бик хәтердә калырлык сүз чыкмады. Бераз рисаләләрен алып, исәнләшеп чыгып киттек.

Нуретдин Ишаев, Рабди

## II
## Габделкаюм әл-Насыйри

1879 елда әткәмнең өченче мәртәбә хаҗ сәфәрендә, актык мәртәбә пароход белән Казангача озата килеп, Шигай[1] мәдрәсәсенә кайта алмый калдым. Казан шәһәрендә булган мәдрәсәләрне әткәй белән йөреп, күреп беткәч, Насыйрига кердек. Ул заманда төтеннең бик тәмлесене йи-бәрә иде. Әмма каба торган сурәте генә килешсез булып, орчык юанлыгы башыннан кабып, шырпыны малае сызып йибәрәдер вә каймак кыздырган исләр чыгарадыр иде. Әткәйгә тәэлифләрнең төрлесеннән китерде. Атамның төтенгә чыдап утыруына тәгаҗҗеб иттем. Чөйгә эленгән бер скрипка вә балалайкасы да бар иде. Ишек төбендә бәләкәй генә чары, таяк һәм шар кыра торган станок — кораллары да бар иде. Әткәй: «Тәкъсир, горрәлек чыгарамыз»[2] дигәнсез, бәнем һәм «Горей-йе галәйһи вә мираэтел әлһиллә» исемле горәлекләрем бар иде, шуларны бастырыр өчен Бөре өязе Кучаш имамы Гайнулла мулла дигән кемсә Казанга алып килеп югалтты», — диде. Габделкаюм әфәнде: «Беләм, күргәнем дә бар, сезнең ул иҗтиһадыңызга бик тәхсин иттем, мәгәр, дибаҗәлен вә дибаҗәсене гарәпчеләп мәшәкатьләнмәсәңез икән, «Төрке барның күрке бар» дигәндәй, бән үзем саф төрки телен яратам», — диде. «Фәвакиһел җөләса»сен[3] шул вакытта ук яза башлаган иде. Өстәл астыннан алып бераз йирен укып та күрсәтте. Мәгәр, җөмлә саен теле пешкән сымак сулышын суырып ала иде*. Менә безнең төрки телендә дә фәсахәт бик шәп дип, мактанып та куйгалады. Әткәмездән «Рабигыл мөҗиб»[4] рисаләсене мәзкүр Кучаш

мулласы аркылы алдырган икән, анысы торып торсын әле, дип сорады. Өстәлендә үзе ясаган җәзбә (циркуль) бар иде. «Менә мин, алла теләсә, «Рабигыл мөҗиб»не төркичәгә әйләндереп, аукат хәмсәне вә фи зәвалне тәгъриф итмәкче буламын»[5], — диде.

Әткәйдән: «Бу угылыңызны кем мәдрәсәсендә калдыра-сыз?» — дип сорагач, әткәй: «Белмим, шәкертләр Казанда йоклый төшәләр икән»,— диде. Чөнки без иртә намаздан чыгып, шул мәхәлләнең[6] мәдрәсәсенә бара торган идек, ул вакытта кояш чыга иде, әмма шәкертләрнең бик азы гына, сөлгеләрен муеннарына элеп, таһәрәт алырга йөргәне күренә иделәр. Әткәмез буннан бик нәфрәтләнгән иде. йитмәсә, мәдрәсә капусыннан чыкканда, ашханәдән пошкырган тавышлар ише-телеп кала иде. Әткәй Габделкаюм әфәндегә боларны сөйләде. Габделкаюм әфәнде: «Шулай шул, безнең Казан халкы, шәкерте булсын, сәүдәгәре булсын, хәтта голямәсе дә аннан хали түгел. Икенче җенестән бер зат күрсә, кирәк голямә булсын, аны истиһза кыла төшәләр», — диде. Әл-хасил, үзен һичбер милләткә хәкыйрь күз белән карауны җаиз күрмәгән икенчелеген бик яхшы белдерде.

«Улыңыз ничә яшьтә?» — дигәч, әткәмез: «Уналтысы тулып унҗидегә чыкты», — диде. «Ник Учительский школага бирмәдеңез?» — диде. «Бик сорадылар, ләкин бирә алмадык инде», — дигәч: «Мулла итмәкчесездер, ләкин имам булып милләткә хезмәт күрсәтмәк мөшкелдер», — диде. Моның соңында: «Сезнең шигырьләреңез, тәхрирләреңез бик матур, мәгәр бастырырга кирәк иде», — диде.

Әткәмезне хаҗга озаттым. Буш көннәрем булдисә, Габделкаюм әфәндегә барыр булдым. Хәлемне сорашыр иде. Кайчагында курай уйнаган вакытына тугры килә идем. «Нихәл, башкорт, курай уйный beләмсең?» — дия иде. Ташаякта[7] сатыла торган агачтан ясалган кыска курай уйный иде. «Безнең башкортларның урманда үскән нугай курае озын була, яки җиздән була», — дия идем.

Бер янгын (пожар) да күп язулары янганын сөйләп, без кечкенә булсак та зарланып алыр иде. Бервакыт бер календарен урлап, икенче кемсә исеменә бастырганнар, дип зарланды. «Безнең Казанда шул әшәке гадәт бар, кешенең тәэлифене бик урлыйлар. Әнә шуларга бик рәнҗимен, калеб баласы сәлеб баласыннан да газизрәк»,— дия торган иде. Кайсы елгыдыр, хәтеремдә юк, бер календареның, нөсхәсе үзендә калма-ганлыгыннан: «Әгәр дә табып китерүче булса, бер сум бирер идем», — дигән иде.

Габделкаюм әфәндегә беркөн барып керүемдә: «Бик ябыккансың, әллә бик тырышасынмы?» — диде. «Тырышуын тырыша идем, сырхап яттым», — дидем. «Нишләп сырхадың?» — диде. «Шәкертләр ятып беткәч, таһәрәткә чыккан идем, ашханәдән ике шәкерт самавыр морҗасы белән бәргәләп, пошкырып, мырылдап куркыттылар. Шул куркудан сырхаула-дым», — дигәч, бик ачигъланды. «Әмма да тозсыз соң безнең Казан татары. Әгәр дә рус школасына кергән булсаң, көлү вә мәсхәрә ишетү кайда, бәлки үзеңне көйләп кенә йөртерләр иде», — диде.

Габделкаюм әфәнде башкортларны яратадыр вә аларны мәдех кыладыр һәм: «Әгәр дә Казан башкортлар кулында булган булса иде, Сөенбикәне ятларга сатмаган булырлар иде», — дип сөйлидер иде.

Мәрхүмнең байтак рисаләләрен биш ел мөддәттә, кайткан саен алып кайтып, сатып бирәдер идем. Ул заман Госманов мәсҗеденнән[8] бер-ике өй аша гына торган заманы иде. Ярты табак кәгазьгә туба агачы[9] рәвешендә үзләренең нәселләренә шәҗәрә[10] итеп бастырган иде. Шуны күпләп алып кайтып саткан идем.

Габделкаюм әфәнденең хәтеремдә беркадәр тәрҗемәи хәле ошбудыр. Төтен бәянын язмасагыз да ярый. Яныннан чыккач, эткәйдәй: «Тәкъсир дип әйтәсең, ул төтен ничек була?» — дип сораган идем, эти:«Истанбулдан алдыргандыр ахыры, зәгъфран исләре килә бит!» — диде. Бән: «Аны тарту дөрестме?» — дип сораган идем, эти: «Безнең монда дөрест түгел, әмма Истанбулда хәкимнәрнең иттифакы белән зарурият әчеп дөрестләгәннәрдер, чөнки анда һава бик бозык була һәм төрекләр үзләре чәчеп үстерәләр», — диде. Соңгы елларда Каюм әфәнде моны ташлаган иде.

Гарифулла ибн Гали Чокрый.

## III
## Габделкаюм Насыйри хакында хатирәләрем

Габделкаюм әфәнде илә тәкърар юлыктым. Бер мосахәбә-мездә үзенең «Исереклек боянында»[1] язган мәнзумәсен диварга куяр өчен дия бөтен табакка бастырган нөсхәсен күрсәтеп: «Бу рәвештә бастыруымның сәбәбе — халык китапны күп укымый, диварга куйганда ирексез укырлар, күзләре төшәр. Бер кеше угылыны укырга мәхәббәт куйдыра алмый гаҗиз улгач, бер бүлмә диварына дәресләр вә китаплар яздырып, угылыны шул бүлмәгә куйган. Бала бүлмәнең һәр тарафына караса, дәрес китаплары күргән вә ахырында укырга керешеп, шуннан уку юлына кереп киткән, дип сөйләгән иде. Янә бер мосахәбәдә, мәдрәсәләрдән зарланып, тәһзибе әхлак өчен тәэсис ителгән урыннар улырга тиеш булса да, безем мәдрәсәләр бөтенләй буңа хилафынча әхлак боза торган урыннар улып киткәннәр. Яхшы әхлаклы балалар мәдрәсәгә йөреп, әхлаксыз булып, әхлакларын бозып чыгалар. Бик тәэссеф хәл, дип, бик тәфсилләп сөйләгән вә зарланган иде. Янә бервакыт цензурга прошение формасын язып йибәрүен үтенеп язган хатыма каршы язган хатында байтак гыйбрәтле сүзләре бар иде. Ләкин ул хат кайдадыр заигъ улды. Бу хаттан хәтеремдә калганы бары шушы сүзләрдер: «Хатыңыздан бер тәңкә акча килеп чыкты. Бу акча миңа милек улып, бөтенләй кайтарып бирергә дә кул бармады». Мин прошение формасы йибәргән өчен аңа бер тәңкә йибәргән идем дә, шуның ни өчен хатка язмаганмын булырга кирәк.

Мөхәммәтнәҗип Түнтәри.

## IV
## Габделкаюм Насыйри әфәнде хакында

Атамыз Мөхәммәтҗан Мозаффари Габделкаюм әфәнде хакында буйлә сөйлидер:

Мин Шиһап хәзрәт мәдрәсәсендә[1] шәкерт вакытымда Габделкаюм әфәнде илә күп катыштым. Аның үз сүзенә караганда, уң күзенә кызамык илә ак төшкән

вә сул күзе тумыштан сукыр булган. Уң күзе яхшы күрә иде. Ләкин даим күк күзлек истигъмаль кылды. Аягында савырлы читек-кәвеш[2], өстенә ак көмеш тамгалы постау казаки, борынгы әйләнмә якасыз зәңгәр постау чикмән, зәңгәр постау чалбары кәвеш йөзенә төшеп тора иде. Башында бер карыш киңлегендә камчат бүрек[3], кулында җәйләрдә зонтик, кышын кыска таяк тота, төлке тамак толып[4] вә яхшы туннары һәм бар иде. Шырданда утыз-кырык баш умартасы булган, умартасы кырык баштан артмады, утыздан кимемәде, дип сөйли иде. Йөргәндә алдына гына карап йөри, һичкемнең кибетенә кереп сөйләшеп утырмый, урамда да сөйләшеп тормый, сөйләшергә теләүче булса: «Фатирыма бар, шунда сөйләшермез», — дия иде. Хатыннар Таифәсен вә айларның фигылен сөйми, «хатыннар мәкереннән алла сакласын» дигәнен тәкърар ишетем. «Адәм гомерен һәртөрле фетнә вә мәшәкать илә уздырыйм дисә,, хатын алсын!» — дия иде. Хәмер эчми, әмма аз гына дөхан чигә иде. Бервакыт Екатеринский урамында Ядкяр Шаһи йортының өст катында торды. Фатир хакы айга 6 сум, көнгә өч мәртәбә самавыр куеп бирәләр, әмма бер-кадак иттән аш пешереп бирсәләр, анысына 30 тиен хисап, ителә. Урамда сатып йөрүчеләрдән берсе һәркөн иртә илә бер булки кертеп, өстәленә куеп чыга, моны Габделкаюм, әфәнде дәфтәренә язып бара иде.

Габделкаюм әфәнде кеше белән катышмый, тәкърар күз күргән белеш кешесе илә дә бераз сөйләшкәнче ачылмый, салкын тора иде. Каһкаһә илә көлгәнен күрмәдем, тәбәссеме дә бик аз булгандыр. Әмма бер ачылып китсә, мәҗлес яхшы була вә «Әбүнаус[5] шөйлә дигән» дин шигырьләр укый иде.

Мәдрәсә шәкерте вакытында, русча укырга кызыгып, яшерен укыштыра башлаган. Бу эшен остазы Кәрим хәзрәт сизеп, бик ачуланган. (Бәнем аңлавымча, бу Кәрим хәзрәт мөтәгассиб кеше булырга кирәк, Сәйдәшев Әхмәтҗан да[6]: «Аның риза булмавы сәбәпле, русча укымый калдым», — дип язган иде. Шиһап хәзрәтнең истиляхатенәдә ул каршы булган дип беләм.) Аның Истанбулга мөҗаһир кылуы[7], мөхтәрәм Борһан Шәрәф[8] әфәнденең диде-кенчә, Русия тәрәкъкый кылудан өмид өзеп, булмаган тәрәкъкыйга нәфрәтләнеп булса кирәк, күңелгә килә, шулай да Габделкаюм әфәнде русча укудан туктамаган. Билахир, школга кереп укыган, соңра низамлы мәктәпләрнең, берсендә унике еллап мохтасар[9] кебиләрдән дәрес биргән..

1873 елда[10] Шиһап хәзрәт мәхәлләсендә ачылган ибтидаи Русский-татарский школга мөгаллим итеп тәгаен: кылынды. Айлык вазифасы 20 сум, фатир хөкүмәттән иде.

Ләкин анда озак тора алмады. Балаларга укыта торган бер рисалә хосусында Радлов илә килешә алмаенча, урынын ташлады.

Бу вакыт Габделкаюм әфәнденең фатирына кергән идем, русча үгрәнүче өч бала бар иде. Айга өчәр сум биреп, көнгә өч сәгать укыйлар. Шунда Габделкаюм әфәнде суыргыч вә көзге ясау тарикъларын язып утыра иде. Бән шунда берәр бит яздым. Бәнем язуны ошатып: «Каләмең ачык икән, бәңа язучы зарур иде. «Фәвакиһел җөләса»ны табып кылдырмакчы идем. Син язмассыңмы?» — диде. «Бән сиңа һәр көн чирек табак зурлы-гында сигез сәхифә язармын, син бәңа русча үгрәт», — дидем.

«Яхшы, бән сиңа көнгә өч сәгать үзрәтермен», — диде. Ике ай, сентябрь-үктәбрь шөгыльләндек. Бән яздым, ул укытты. Фатирында ишек янында бер өстәл, анда укучы балалар утыралар, залда дәхи бер зур өстәл, анда күп әсәрләр һәм үзенең язмалары ята. Бән шунда утырып яза идем. Шунда аның күп язуларын үземә дә күчереп алдым. Тәэссефкә каршы, бунларның күбесе, афәт ирешеп, кулымыздан китте.

Кышкардан[12] Казанга бардыкымда Габделкаюм әфәнде янына кергән идем. Бу вакытта ул Бәдигъ мәзин йортының[13] астында тора иде. Фатиры гадәтенчә бик тузанлы вә чүпле иде. Гадәтенчә караңгы чырай илә генә күреште. «Ни хәлең бар?» — дип сорагач: «Казалы булдым, күп язуларым янды, күп иҗтиһадларым заигъ булды», — диде. Янган нәрсәләр җөмлә-сеннән без күчереп алганнарның да бәгъзесен зикер кылды. Аңлар бәндә бар, дидекемдә, бик «өенде. «һай, дәхидә күбрәк язган булсакчы, инде шул язган кадәресен бәңа күчереп йибәрә күр», — диде. Мәхәлләмә кайткач, күчереп йибәрдем.

Габделкаюм әфәнде фәлән фәләнев диюне бер дә яратмый иде. «Бу нинди «ов», «ев», татар телендә «ов» булырмы, фәлән фәләни дияргә кирәк, безем телемезгә шул монасиб», — дия иде. «Татар үз телен үзе белми, үз телен үзе һәмишә боза гына бара, юкса, безем телемез бик фазыйль тел, ләкин аны белүче юк», — дип зарлана иде.

Бәгъзе әфәнделәрдән Каюм Насыйриның Радлов белән килешә алмаенча[14] шкулда мөгаллимлеген ташлавына, сурәт мәсьәләсе сәбәп булган, имеш, дия ишетәм. Ягъни Каюм әфәнде школга патша сурәтен куйдырырга разый булмаенча истигъфа кылган була. Бу ялгыш фикернең таралуыннан куркып бу тугрыда хакыйкатьне язарга мәҗбүр булдым.

Татар балалары өчен Шиһап хәзрәт мәхәлләсендә Ядкяр Шаһи йортында школ ачылып, анда Каюм әфәндене мөгаллим кылганнар. Бу йорт Шиһап хәзрәт мәхәлләсенә якын булган-лыктан, эткәмез үзенең танышы Каюм әфәнде янына кергәли икән. Бер кергәндә Радлов илә дә очрашканнар. Радлов, балаларның кенәгәләрен караганда, берәр җөмләне бозылган тапкан. Төрле баланың кенәгәсен караган, барында да бер төрле бозылганын күргән. Балалардан: «Моны кем бозды?» — дип сораган. Балалар: «Каюм абзый бозды», — дигәннәр. Каюм әфәндегә хитабә: «Ник болай бу сүзләрне боздың?» — дидекендә Каюм әфәнде: «Бән соңа «Кырык вәзир»не[15] тәрҗемә кылып укытыйк дидем, анда безем халык шикләнә торган сүз юк. Әмма бу җөмләләрдән бала аталары нәфрәтләнәләр, ничә бала шул сәбәпле укудан туктады», — дигән. Радлов: «Шушыны укыт, алай бозма», — дигән. Каюм: «Бән ул сүзләрне укыта алмыйм», — дигән. Радлов: «Укытмасаң, истигъфа кыл», — дигән. Каюм әфәнде: «Хәзердән истигъфа кылдым, бән укыта алмыйм», — дигән һәм шул көннән укытудан тукталган.

Сурәт алдыру мәсьәләсенә килсәк, Каюм әфәнденең аңа хилаф булмавы беленә. Ул үзе сурәтләр тоткан. Бервакыт эткәмезгә Шиһап хәзрәт сурәтен күрсәткән. Ләкин инкяр галәмәте бер дә беленмәгән.

*Атамызның сүзе бунда тәмам булды.*
*Аның рөхсәте илә «Шура»га дәрҗ кылыр өчен*
*язып йибәрдем. Мөхәммәтхәниф Мозаффар,*
*Кукмара станциясе, Казан губернасы,*

*Пычак карьясендә.*

## V
## Габделкаюм эл-Насыйри

Габделкаюм әл-Насыйри әфәнде, урта буйлы, зур башлы булып, чәчен җитүрәк йөртә иде. Борын вә авыз килешле, төсе ак түгел, бәлки богдай төсендәрәк, йөзе ачык түгел, караңгырак иде. Күзләре зәгыйфь булудан язуны күзенә бик якын китереп карый иде. Мыекны җитүрәк йөртә иде. Сакалы сирәк булып, артык озын йибәрми иде. Йөрүе экрен, алдына карап турырак басып йөри иде. Киемнәре артык кыска, озын да түгел иде. Хален белгән адәмнәр, элек русча укып йөргән вакытларында европачарак та киенеп йөргән, диләр.

1876-1877 нче елларда булырга кирәк, Шиһап хәзрәт мәхәлләсе булган Ядкяр Шаһи йортында, Приходский училищеда учитель булып торганда, без Күл буе мәдрәсәсеннән дүрт-биш шәкерт кич белән русча укый идек. Башка мәдрәсәләрдән дә укучылар бар иде. Көндез балалар укытып, кич зурракларны укыта иде. Ул вакытларда русча уку зур гаеп иде. Анда күпме учитель булып торуы хәтеремдә юк. Ул урыннан чыктымы, юкса чыгарылдымы, беленмәде. Учитель мәгашьләре киселгәч, каләмгә сарылып, календарьлар бастырып китаплар чыгарырга тотынды. Ул вакыт Казан муллалары арасында вә күп адәмнәр кашында игътибары юк иде. Бастырган китапларыны шәкертләр вә приказчиклардан гына күпләр яратып укыйлар иде. Борынгы басма китаплардан бик күп хәрефләрне алмаштырды вә күпләрен төшереп калдырды. Мөмкин булганда гарәп вә фарсы сүзләрен ташлап, алар урынына төркичә яза иде. Китаптан максуд белдерү булгач, беленсен, дия иде. Үзен Казан халкы күбесе яратмаган кеби, үзе дә Казан халкының күбесен яратмый иде. Элегрәк вакытларында Казан халкын тәнкыйть кылып «Җыен»[1] исемендә бит тә чыгармыш иде. Соңгы елларда басылды да бугай. Хасил, муллалар, байлар, хезмәткәрләр, икмәкче-күмәччеләр, дворникларның яшерен эшләрен күз алдыларына китереп күрсәтмеш иде. Ошбу бер бите хәтеремдә:

Бардыр бер нәугъ халык, син аны чухур ата,
Эше юктыр, ашы юктыр, торганы — суган сата.
Ошбу нәугъ кешеләрнең, урыныдыр Печән базар[2]
Бу кешеләргә иярсә суфи һәм мулла азар.

Мәҗлесләрдә булмый, булганда да сүз сөйләми, тик утыра иде. Сөйләгәндә кычкырмый, ашыкмый сөйләшә вә күп сүзле түгел иде.

Мактанмый вә үзен югары тотмый иде. Янына кереп, берәүләр: «Габделкаюм абзый, безгә хәзер русча лөгатъ китабы яки тыйб китабы, йә җәгърәфия кирәк», — дисәләр, шуларны игътибарга алып, вөҗүдкә чыгарырга тырыша иде.

Тыйб китапларында гарәпчә язылмыш дару исемнәрен белүдә дикъкатьле иде. Күбесен китапка мөрәҗәгать итми, русчасы менә болай, төркичәсе болай, дип иренми әйтә иде. Бәдигъ мәзин йортында торганда, күп мәртәбәләр янына кереп чыктым. Китапларын алып та чыгадыр идем, авылдан хат белән дә алдыра идем. 1880 елгы календаренда мөәзиннәр намаз вакытларын ригая итмиләр, кыйбла вә зәвал белергә кораллары юк, дип даирә һиндия рәвешен күрсәтмеш иде. Берәр

йирендә аңламаган урыным булдыгыннан, бер кергәндә, үзеннән сорадым. Бик ачык аңлатып, үзе ясаган даирә һиндияне күрсәтте. Шәмдәл кеби, уртасында каймасы җиздән ясалган, төбе җуан, очы бик очлы иде. Миңа: «Менә моны һәр кая тигез урын булганда куярга мөмкин», — диде. Китап төпләү, юынышу һөнәрләрен белүе әүвәлгедән мәгълүм иде. Бакыр, тимер һөнәрләрене бераз белүене дә даирә һиндиясен күрүемнән аңладым.

1899 ел июнендә Казанга баргач, Бәдигъ мәзин фатирына барып, янына кердем. Чәй эчеп утыра. Самавыр вә әсбаплары бик түбән. Тормышы бик начар, җүнле нәрсәләр күзгә күренми иде. Анда-монда китаплар ята, кәгазь чүпләре, струк йомычкалары җыелмый, себерелми иде. Зуррак, төпләнгән бер китабын алып карадым. Ул исә «Ысуле җәгърәфияи кәбир»[3] — Азия кыйтгасы, Африка кыйтгасы, җәзирә эл-гареб иде. Өчесен бергә бик матур итеп клеенка илә үзе тышлаган иде. «Бу ни хак?» — дип сорадым. «Ике сум», — диде. Мин: «Бер сум иллегә бирергә булмасмы?» — дип әйтүемә каршы: «Ул хакка биргәнче себерке итеп чабынырмын», — диде. Күрәсең, минем бирүемдә сумасы табылмаган булырга кирәк, чөнки күп бастыра алмый иде: Аз булгач кыйммәт төшәдер. Ул заманда укучылар да аз иде. Халкымызның укымаганлыгыннан зарланганыны күп ишеттем. Китаплар күп бастырырга да сума җыя алмаган булырга кирәк. Югарыда әйткәнемчә, тормышы бик түбән иде. Ашны хәрчүнәгә барын ашап, чәйне өйдә эчмәктә иде. Габделкаюм абзый «Ысуле җәгърәфияи кәбир» китабының Азия кыйтгасында 89нчы сәхифәсендә: «Казан ханлыгы заманында һиндстан халыклары Казанга сәүдә белән киләләр иде, Казан Диярендә һинд халкының күп нәселләре бар, хәтта бәгъзе карьяләр шул һинд исеме белән аталып калган. Мәсәлән, Кычмир авылы Кашмир шәһәреннән килгән кеше исеме белән, Әҗмир карьясе һиндтәге Әҗмир исеме белән аталмыштыр. Оры авылы да Орзирумиан килгәндер», — дидер. Ничә кәр-рәләр: «Сез моны кайдан алын яздыңыз?» — дип сорарга касд кылып барсам да, сорый алмадым. Алай үзеннән генә чыгарып язмаска кирәк иде.

Бервакыт күрүемдә, миңа рәсемеңезне һәдия кылсаңыз тәзкирә-ядкяр булыр иде, дидем. Җавабында: «Рәсем алдыр-мадым», — диде, бәлки: «Алай булса, сезгә менә,Тәзкирә», — дип, бәгъзесе хәдис[4], богъзесе хәкимнәр сүзеннән гыйбарәт сигез кисәк үз каләме илә язылган язуын бирде. Шул елларны бәгъзе бай балаларын хак алып укытканда, шул кәгазьләрне диварга ябыштырып куйган вә язуларыны язарга, каләмнәрене төзәтергә тырышкан булса кирәк.

Соң заманнарда мәгашьне мөселманнар тарафыннан хасил иткәнгә күрәдер, кыяфәт вә киемиәрене Азия формасына әйләпдермеш иде. Бервакыт бикасапны[5] тотып: «Менә бик яхшы, үзе йиңел, шелкывый»,— дип тә әйткән иде.

*Габдулла бине Таҗетдин нәл-Кәчмәри.*

## VI
## Мөхтәрәм Габделкаюм Насыйри белән мосахәбә

*(Хатирә дәфтәреннән)*

Казанга шәкерт булып килгән көннәремнән игътибарә миссионерларга сатылган, дин бозучы Сукыр Каюм исемле бер кешенең барлыгын ишетә килдем.

Тәүзихханнар, пишкадәмнәр вә олуг хәлфәлор агызыннан ишетелгән бу сүзләр миңа да суи тәэмир иҗраэ итми калмадылар. Минем кальбемдә К. Насыйри хәзрәтләренен үзенә дә, китапларына да нәфрәт хисе уяндырдылар. Шул суй тәэсиргә бирелеп булса кирәк, берничә еллар аның китапларын укудан мәхрүм калдым.

Соңгы елларда шәкертләр арасында мәдрәсәдә укылган дәрес, фән вә китаплардан ризасызлык [туды], хәтта Мөхәммәтгаяз Исхакый[1] дигән шәкерт* «Силме әл-голум», «Трабелгали»[2], «Тәһзиб»[3] вә башка берничә мантыйк китапларын мичкә тутырды, астларына чыралар куеп ут якты вә кисәү илә бутап-бутап яндырды.

Мәдрәсәләрдә метадавел булган китапларның эшкә, фәннәре тәгълимгә яраксызлыклары аңлашылгач, беркадәр шәкертләр госманлы телендә язылган фөнүн вә әдәбиятка сарылдылар. Пәнҗешәмбе вә җомга көннәрендә китапханәләрдә китап эзләп йөрүче шәкертләр шактый күбәйделәр.

Төрек телендә язылган китаплар илә бергә, бәгъзе фазыйльләремез тарафыннан язылган вә үземезнең Русиядә басылган китаплар да мәдрәсәдә күренгәли башладылар. Шул җөмләдән Каюм Насыйри хәзрәтләренең китаплары да мәдрәсәгә килеп керделәр вә сөелеп укыла башладылар. Мөхтәрәм Насыйриның китаплары күңелемдә булган борынгы нәфрәт урынына китапларына да мәхәббәт ирештерделәр.

Инде мин Насыйрины галибанә сурәттә чын күңелдән сөя вә үзене күрергә арзу итә башладым, фәкать нинди сәбәпләр тәэсире иләдер, бер-ике ел үтте исә дә барып күрергә җөрьәт итә алмадым.

Ниһаять, 1901-1902 нче уку елы килеп йитте. Казанда доһур иткән вә илле еллар микъдары Казанда торган үземезнең татар мөхәррирен күрми торуны, бер мәртәбә булсын зиярәт итми ятуны вөҗданым Җаиз күрми башлады. Шуңа күрә Мәхмүтфуад Туктаров**[4], Габделрәүф Ниязбаевлар[5] илә Насыйрины зиярәт өчен бер көн билгеләдек. 1902нче ел 9нчы январь, иртә сәгать 10да Насыйри җәнабләрене зиярәт өчен киттек. Бервакыт Гаяз әфәнде илә икәүләп урамнан барганда, Әби чиркәвеннән[6] барып, Екатеринский урамга кергәндә, сул чаттагы бер йортка ишарә кылып: «Менә шул йортта безнең милли мөхәрриремез Каюм Насыйри тора», — дигән иде. Шуңа күрә без тугры шул йортка бардык. Фәкать Насыйрины ул йортта таба алмадык, йорттагы агайлардан, хатыннардан мөхәррирне сорадык. Ләкин барысы да: «Сукыр Каюм буйдан күченде», — дип кенә җавап бирделәр. Мәэюс булып урамга чыктык, шундагы кибетчеләрдән мөхәррирнең яңа фатирын сораштык. Сораша торгач, бер кибетче: «Ул Галимҗан хәзрәт мәхәлләсенә[7] күченде, фатирын белмим», — диде. Җуялгаи киләпнең очын тапкан кеби булып, балаларча шатланыштык вә тугры Галимҗан хәзрәт мәсҗеде янына бардык. Узып баручы биш-алты кешедән мөхәррирнең фатирын сорадык, фәкать һаман «Белмим» җавабын алдык.

Ниһаять, чаттагы мәсҗед кибетеннән бөтен өсте, бите-башы күмергә буялган унөч-ундүрт яшьлек бер бала чыкты вә: «Мин беләм, әйдәгез»,— диде. Балага иярдек. Кыйбла тарафына сузылган урамда Галимҗан хәзрәт йортыннан өч-дүрт йорт үтеп, ике катлы бер йортның ишек алдына кердек. Бала өйнең өст

катында Бәдигъ мәзин, асткы катында безнең эзләп йөргән мөхәрриремез Каюм Насыйри торганын вә үзе аның хезмәткәре икәнен сөйләде.

Өйгә кердек. Ике зур бүлмәдән гыйбарәт бу өйнең алгы бүлмәсендә икенче бала керосин машинкасы илә аш пешереп тора. Эчке бүлмәнең сул касагыннан сузып урам як стенасына йирдән аршин 8 ярым югарыда беләк калынлыгында бер агач беркетелгән. Ишекнең сул ягында бер шкаф, эчендә китаплар, стенага бер пычкы эленгән, йирдә балта, өтерге, наструк вә башка кораллар, агач кисентеләре, кәгазь парчалары ята. Гомумән, өйнең эче тәмиз түгел, бәлки артык дәрәҗәдә нәзафәтсез иде. Өстәл артындагы каралып беткән диванга утырып, сул яңагын тәмам өстәлгә тигезгән, каләменең яза торган очына күзен якын китергән хәлдә, күркә каләм илә язып торган камчат бүрекле бер щәйхефани күрдек вә сәлам бирдек.

Шәйх башын күтәреп сәламемезне кайтарды һәм шундагы урындыкларга утырырга кушты. «Сез кемнәр буласыз?» — дип сорады.

Иптәшләрем үзләренең Учительская школа[9] шәкертләре идекләрене, мин дә Габделгаллә мәдрәсәсенең[10] бер шәкерте булуымны сөйләдек. Ул сүзгә башлап: «Габделгаллә мәдрәсәсендә мин бераз мөгаллим булып тордым, шул чакта ислам тарихына даир җәгърәфия хәтирәләре тәртип иттем, шул хәритәләр хәзер дә бармы?» — диде. Мин: «Безнең мәдрәсәдә андый хәритәләр юк», — дигәч, сүземдә дәвам итеп: «Нигә булмасын? Әхмәров[11], ул хәритәләр школа архивасында сакла-на, дигән иде, сез соң архивага бер дә кереп карамыйсызмыни?» — диде. Без дә: «Караганымыз юк шул», — дидек.

Бу сүздән соң без аның мәдрәсә илә школаны бергә бутаганын вә гакылына хали килә башлаганын аңладык. Безне алып килгән бала да бу фикеремезне таэкил итте.

Бундан соң: «Гади мәдрәсә шәкерте булып хәритәләр тәртип итәрлек кадәр мәгълүматны кайдан тәхсил иттеңез?» — дип соравымызга каршы: «Мин бит университетта укыдым[12], безнең заманда укучы бик кадерле иде. Хәзер укырга акча биреп керәләр, ә ул заманда укучыларга акча бирәләр иде. Казан университетына халыкның мәхәббәте юк вә шунлыктан анда шәкерт бик аз, шәкертләрне ялынып-ялварып кабул итәләр иде. Университет яучыларыннан берсе миңа да җитте. Электә укыган аз-маз русчам университетта дәвам итәргә ярады»*, — диде.

— Үзеңез карт, күзләреңез зәгыйфь булса да, язуыңызны дәвам итәсез икән, — дигәч, ул:

— Алла мине китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам, — диде.

— Бу көндә нинди китап язып мәшгуль буласыз? — дип сорагач, утырган диванының бер башыннан көрпәсен кайтарып, зур кулдан Коръән хәҗемендә тәхминнән җиде йөз илле сәхифәлек яңа кәгазьле, тышсыз кулъязма бер китап чыгарды вә, сүзендә дәвам итеп, диде:

— Буңа әле исем куйганым юк. Буның илә Коръән Кәримнең һәр аятен[13] вә һәр кәлимәсен табып булачак. Дөрест, бу хакта тәртибе зибл илә Америка миссионеры тарафыннан тәртип ителгән «Нөҗүм эл-форкан»[14] исемле китап бар. Фәкать анлар канәгатьләнерлек түгел, тәртибе зиба илә аятьнең баш кәлимәсен

белгән кеше генә файдалана ала. «Һөҗүм әл-форкан» илә файдаланыр өчен бик күп кәгазьләр актарырга вә әллә ничә йөзләр, бәлки меңнәр илә аятьләр санап торырга кирәк була. Аның өчен бу кәлимә әллә ничә йирдә зекер ителгән була. Менә минем язып торган бу китабым ул мәшәкатьләрнең барысын да бетерәчәк. Инша алла, тиз тәмам булыр һәм озакламый басылып та чыгагу**

Бу китап тәбииз ителгән вә бик гүзәл каләм илә язылган, бәгъзе сүзләрнең өстенә кызыл кара илә хаталары сызылган иде. Үзе актарып күп йирдән ачып-ачып караса да, безгә тәкъдим итмәде. Сорап алып карарлык җәзарәт бездә дә булмады.

— Идәндә чәчелеп яткан коралларның сезнең өчен ни әһәмияте бар? — диюмезгә җавабы:

— Һаман утырып хезмәт итү мине ялыктыра, каннар оеша башлый. Шунлыктан мин һәркөн бер-ике сәгать бу кораллар илә үземә кирәк нәрсәләрне ясап мәшгуль булам, — диде.

— Соң анлар илә иштигалеңез тәмам булгач, нигә бу балалардан корал вә йомычкаларыңызны җыештырмыйсыз? — диеп соравымызга:

— Анлар нәрсә куюның рәтен белмиләр. Кайда куйсалар, шунда оныталар, кирәк вакытта артларыннан табу мөшкел була. Идәндәге нәрсәләрне мин аягым илә басып та табам, йомычкалар илә балалар иртә мич кабызып йибәрәләр, — диде.

Өйнең һәр тарафы вә һәр нәрсәсе артык дәрәҗә нәзафәтсез булганга, өйдә хатын кулы юклыгы бик ачык беленеп тора иде. «Һәм Каюм әфәнде гомердә бер мәртәбә булсын өйләнгәне юк», — дип ишетелгәнгә күрә, өйләнүе хакында сораудан үземезне тыя алмадык.

— Бөтен хәятыңызда хосуса бу көнге кеби картлык заманыңызда тәрбия вә хезмәтен күрү өчен нигә берәр рәфика алмадыңыз? — дидек. Ул:

— Мин хатын алмадым түгел, алдым, хәтта икене алдым. Фәкать беренчесе илә мәхәбботемез булмады, өлфәт итә алмадык. Үзе аерылырга сорады да аердым. Бусы яшь вакытымда иде. Аннан соң тагын бер хатын алдым. Бусы илә яхшы ук мәхәббәтемез дә булды, ләкин минем язу хезмәтемә бик күп кимчелек китерә башлады, бик күп хезмәтләрем аның мәхәббәтенә корбан булдылар. Язу вә башка хезмәтләренә хали килмәсен өчен бунысын үзем талак иттем, — диде.

Бундан соң аңа сөальләр бирергә, мосахабәмезне сузарга имкян тапмадык. Милләтенә китап, әдәбият язар вә шулай итеп андарга рухани азык хәзерләр өчен рәфика Хәятыннан аерылып вә бөтен халыктан газел ителеп иҗтиһад кылуына-тәхсин иттек вә, рәхмәтләр укып, чыга башладык. Алгы бүлмәгә чыккач, балалардан эчке бүлмәнең аркылысына беркетелгән агачның хикмәтен сорадык. «Ул бәгъзән өйдә адашып китә дә кайда барырга белми, ул агач аның юл табуына, тышка чыгуына ярдәм итә», — диделәр.

Габделкаюм әфәнденең күзләре начар күргән кеби колаклары да бик аз ишетәләр иде. Шуңа күрә бик кычкырып сөйләргә мәҗбүр булдык. Бу мөхтәрәм Каюм Насыйрины зиярәттән яхшы тәэсир хасил итә алмадык. Бәхетсез татар милләтенең мөхәрриренә, аның хәл вә мәгыйшәтенә чын күңелемездән кайгырдык, ачындык. Милләтенә китаплар язып, аларны агартыр өчен бөтен рәхәттән вә сәгадәттән аерылган бер мөхәррирге «дин бозучы, Сукыр Каюм»

дигән «мөкяфәт»не бирүче татар милләтеннән өмидемезне тәмам кистек, истикъбальдә өмид вә тәрәкъкый булмаучылыгына канигъ булдык. Шулай да аның: «Мине алла китап язар өчен яраткан, бу көннән язмый утыру аның хөкеменә каршылык булыр дип куркам», — дигән сүзе калебем.езла,бер эз калдырды вә киләчәктә кулымызга тапшырылачак эшләрдә сәбәт вә мәтанет үзәрендә хезмәт итүнең имкянын ачык аңлатты.

*Насретдин әл-Хуҗаши,*
*Казан, 1902нче сәнә, 15 январь,*

## Аңлатмалар

*Зиярәт итү* — хәлен белергә бару. *Табгы* — басма. *Пакизә* — чиста. *Тәгъриф итте* — таныштырды. *Тарикъ* — ысул, юл.

*Тәэлиф* — хезмәт. Тәгажщеб итем — гаҗәпләндем.

*Замана зыялыларынча күтәренке тавыш белән укымады, абыстайлар тавыш чыгарып укый иде. *(Автор искәрмәсе.)* Тәхсин иттем — мактадым. *Дибаҗәлен* — бүлек исемнәрен. *Дибаҗәсене* — кереш сүзен. *Фәсахәт* — матурлык.

*Хали түгел* — азат түгел. *Истиһза* — мыскыл итә. *Хәкыйрь* — кимсетү. *Җаиз* — дөрес.

*Тәхрир* — язу рәвеше. *Калеб* — күңел. *Сәлеб баласы* — карында яткан бала. *Мәдех кыла* — мактый. *Мөддәт* — вакыт эчендә.

*Иттифак* — килешү. *Мосахәбә* — сөйләшеп утыру. *Тәһзибе әхлак* — әхлак төзәтү. *Тәэсис ителгән,* — билгеләнгән. *Хилафынча* — киресенчә. *Тәэссеф* — үкенечле. *Заигъ улды* — югалды.

*Истигъмаль кылды* — килде, кулланды. *Таифә* — даирә. *Дөхан чигә* — тәмәке тарта.

*Каһкаһә* — шаркылдап. *Тәбәссем* — елмаю, көлемсерәү. *Шәйлә* — шулай. *Мөтәгассиб* — фанатик, иске фикерле. *Истиляхат* — реформалар. *Мөщаһир* кылуы — күчеп китүе. *Билахир* — ахырда. *Низамлы* — махсус тәртипкә ия булган. *Ибтидаи* — башлангыч. Рисалә хосусында — китап мөнәсәбәтендә.

*Зикер кылды* — искә төшерде. *Монасиб* — ярашлы. *Фазыйль* — яхшы, камил. *Истигъфа кылу* — хезмәтеннән чыгарылу.

Инкяр галәмәте — кире кагу билгесе. Хилаф — каршы. Хитаб — эндәшү.

*Хәлен* — биографиясен, тормыш юлын. *Мәгашьләре* — тереклекләре. *Хасил* — нәтиҗә. *Нәугъ* — төр. *Чухур* — мещан.

*Лөгать* — сүзлек. Тыйб — медицина. *Ригая итмиләр* — белеп бетермиләр. *Зәвал* — кояшның төшлектән баюга таба авышуы. *Даирә һиндия* — компас. *«Ысуле җәгъръфияи кәбир»* — «Зур география ысулы». *Кыйга* — континент. *Җәзирә эл-гареб* — көнбагыш утраулары.

*Касд кылып* — ниятләп. *Һәдия* — бүләк. *Тәзкирә* — истәлек. *Каләмнәренә* — почеркларын.

*Мосахәбә* — сөйләшеп утыру. *Тәүзиххан* — мәдрәсәдә «Тәүзих» китабын укучылар сыйныфы шәкерте. *Суй тәэсир ижраэ итми* — кире тәэсир ясамый.

*Басылган әсәрләре аркасында бу зат бу көндә мәшһүр әдип вә мөхәррирләремездән саналадыр (Автор искәрмәсе).

*Мөтәдавел* — таралган, йөргән. *Фөнүн* — фәннәр. *Фазыйль* — белем иясе.

**Бу зат бу көндә Казан дарелфөнүне хокук шөгъбәсенең студентыдыр (Автор искәрмәсе).

*Зоһур иткән* — мәйданга чыккан. *Җаиз күрми* — кичерми. *Мәэюс булып* — өметне өзеп.

*Тәмиз* — чиста. *Нәзафәтсез* — арусыз, җыйнаксыз. *Шәйхефани* — бик картайган кеше. *Хали* — көч. *Таэкил итте* — куәтләде. *Тәхсил итү* — хасил итү.

*Ул университетны башка берәр мәктәп белән бутады булса кирәк, университет сүзен ялгышып кына сөйләде бугай (Автор искәрмәсе).

**Бу китапның, кем кулында калуы һәм басылуы безгә мәгълүм булмады (Автор искәрмәсе).

*Хәҗҗемендә* — зурлыгында. *Тәхминән* — якынча. *Тәртибе зиба* — Коръән сүзләрен алфавит тәртибендә язып чыгу. *Тәбйиз ителгән* — акка күчерелгән. *Җәзарәт* — батырчылык.

*Иштигаль* — шөгыль, эш. *Рәфика* — иптәш. *Өлфәт итә* — үзләшә. *Имкян* — мөмкинчелек.

*Газел ителеп* — читләшеп. *Тәхсин иттек* — мактау сүзләре әйттек. *Бәгъзән* — кайвакыт. *Мөкяфәт* — бүләк. *Истикъбаль* — киләчәк. *Канигъ булдык* — ышандык. *Сәбат* — ныклык. *Мәтанет* — карарга килү.

**I**

[1] Өчбүлә карьясы — башкорт авылы.

[2] Екатеринский урам — хәзерге Тукай урамы.

[3] Аитов йорты — Сөләйман Аитов, Казанның эре сәүдәгәре, йорты Татарстан белән Нәриман урамы кисешкән чатта булган, хәзер сүтелгән. К. Насыйри аның йортында да торган, балаларын укыткан. С. Аитов үзенең истәлегендә: “К. Насыйри минем йортта вафат булды”, — ди. Бу соңгысы дөреслеккә туры килми. Күпчелек истәлек авторлары галимнең соңгы фатиры итеп Бадигъ мәзин йортын күрсәтәләр.

**II**

[1] Шигай — башкорт авылы.

[2] Горрәлек чыгарамыз — сүз К. Насыйриның 1871-1896 елларда чыгып килгән “Казан календаре! Дигән журнал характерындагы хезмәтләре турында бара

[3] “Фәвакиһел җөләса фил әдәбият” (“Әдәбият турындагы мәҗлесләрнең җимеше”) исемле китабы 1884 елда Казанда басыла.

[4] “Рабигыл мөҗиб” (“Тиешле булган дүрт фарыз”) — мөселман кешесе үтәргә тиеш булган дүрт дини кагыйдә язылган китап.

[5] Аaукате хәмсәне вә фи зәвалне тәгъриф итмәкчк буламын — кояш йөрешенә бәйле хәлдә, биш вакыт намазның төгәл вакытларын аңлатып бирмәкче буламын.

[6] Мәхәлә — авылның яки шәһәрнең бер мәчеткә караган өлеше.

[7] Ташаяк — ярминкә исеме, һәр елны май аенда Казанның Кремльгә якын урынында, хәзерге В. И. Ульянов исемендәге Үзәк стадион каршында булган.

[8] Госманов мәсҗеде — 1867 елда Казанда сәүдәгәр Госманов акчасына төзелгән, Кызыл мәчет дип йөртелгән. Хәзерге Тукай урамы, 14нче йорт, манарасы торгызылды.

[9] Туба агачы — дини хорафат буенча җәннәттә үсә торган хуш исле агач.

[10] Шәҗәрә итеп бастырган — К. Насыйри үзенең нәсел шәҗәрәсен 1880 елда ташбасмада бастырып чыгара. (Шәҗәри Хөсния. Казан, Перов матбагасы. 1880). Төп нйсхәсе Санкт-Петербург Әдәбият һәм сәнгать дәүләт архивында саклана.

**III**

[1] «Исереклек бәянында» — «Исереклек хәлләре бәянында гыйбрәтнамә» исеме белән 1896 елда Казанда басылып чыга.

**IV**

[1] Шиһап хәзрәт мәдрәсәсе — татар халкының тарихчы галиме, мулла Шиһабетдин Мәрҗани (1818-1889) укыткан «Мәдрәсәи Мәрҗәния», 1875 елда ачылган, хәзерге Зәйни Солтанов урамы, 6 нчы йорт.

[2] Савырлы читек-кәвеш — төрле буяуларга буяп бозау тиресеннән тегелгән читек-кәвеш.

[3] Камчат бүрек — түбәсенә хәтфә, кырыена кондыз тиресе куеп тегелгән бүрек.

[4] Төлке тамак толып — төлкенең тамак асты тиресеннән тегелгән кыйммәтле толып.

[5] Әбүнаус — VIII йөз урталарында яшәгән талантлы гарәп шагыйре Хәсән ибн Ханиның яшерен имзасы.

[6] Сәйдәшев Әхмәтҗан — Әхмәтҗан Яхья улы Сәйдәшев (1840-1912) — Казан сәүдәгәре, «Бәянелхак» газетасының нашире һәм мөхәррире.

[7] Истанбулга мөҗәһир кылуы — Ш. Мәрҗани Төркиягә 1880 елда китә. Андагы мәдәниятны һәм укыту ысулларың өйрәнеп кайта.

[8] Борһан Шәрәф — Барһан Шәрәфетдин улы Шәрәф (1881-1938) — журналист.

[9] «Мөхтәсар», — ислам диненең хокук кануннары язылган китап, мәдрәсәнең югары сыйныфларында гарәп грамматикасын үткәннән сон укытылган.

[10] 1873 елда — дөресе — 1871 елда.

[11] Радлов — Василий Радлов (1837-1918) — Германиядән килгән галим, тюрколог, этнограф, археолог.

[12] Кышкар — Татарстанның Арча районына керә торган авыл.

[13] Бәдигъ мәзин йорты — хәзерге Париж Коммунасы урамы, 35нче йорт. К. Насыйри фатирын еш алмаштырган. Бу соңгы фатиры: 1902 елның 21 августында соңгы юлга шушы йорттан озатканнар.

[14] Радлов белән килешә алмаенча — бу истәлектә Радлов белән К. Насыйри арасында килеп чыккан каршылык ачык анлашылм К. Насыйри иҗатын өйрәнгән әдәбият галиме М. Гайнуллин аны болай аңлата: Радлов К. Насыйрига немец педагогикасы казанышларыннан файдаланып укытырга куша, ә ул моңа риза булмый, нәтиҗәдә укыту эшеннән китәргә мәҗбүр була.

[15] «Кырык вәзир» — 1868 елда «Кырык вәзир кыйссасы» исеме белән чыккан бу китабы Көнчыгыш әдәбиятыннан алып ирекле тәрҗемә иткән хикәятләрдән тора.

## V

[1] «Җыен», — бу хезмәтнең язмышы билгеле түгел.

[2] Печән базары — элекке Казанда хәзерге Киров һәм Париж Коммунасы урамнары чатын, Татарстан урамының бер өлешен эченә алган зур базар.

[3] «Ысулы җәгъръәфияи кәбир» («Зур география ысулы») — берни кисәктән торган бу хезмәт 1894, — 1899 елларда басылып чыга.

[4] Хәдис — динчеләр өйрәтүенчә, Мөхәммәт пәйгамбәр сөйләп калдырган хикмәтле сүзләр.

[5] Бикасап — буй-буй ярым ефәк тукымадан тегелгән камзул.

## VI

[1] Мөхәммәтгаяз Исхакый — Мөхәммәтгаяз Гыйлаҗетдин улы Исхаков (Г. Исхакый, 1878-1954) — күренекле татар язучысы, Октябрьдән соң чит илдә яши, кабере Истамбул зиратында.

[2] «Силме әл-голум», «Трабелгали» — иске мәдрәсәдә укыла торган мантыйк китаплары.

[3] Тәһзиб («Тәһзиб әл-мантыйк вә әл-Кәлам») — дин һәм законнар белгече, бохаралы Сәгадетдин Тофтазанинның XIV йөздә логика белән догматика буенча төзегән дәреслеге.

[4] Мәхмүтфуат Туктаров — Мәхмүтфуат Фәсах улы Туктаров (1882-1934) — публицист, сул эсер, Октябрьдән соң чит илдә яши.

[5] Габделрәүф Ниязбаев — Габделрәүф Хәкимбай улы Ниязбаев (1881-1934) — драматург, педагог, биш пьеса авторы.

[6] Әби чиркәве — Г. Камал белән Тукай урамнары чатында таш чиркәү, җимерелгән, хәрабәләре генә саклана.

[7] Галимҗан хәзрәт мәхәлләсе — дин галиме, мулла әл-Баруди (Галиев, 1859-1921) 1882 елда «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен ача (хәзерге Тукай урамы, 34 нче йорт, профессиональ техник училище бинасы), әлеге мәдрәсә тирәсендәге йортлар аның мәхәлләсенә кергән. Мәчете дә шул мәхәлләдә, 1801 елда сәүдәгәр М. И. Галиев акчасына төзелгән, хәзерге Тукай урамы, 40нчы йорт. Г. Барулиның йорты Тукай белән Коммунасы урамнары кисешкән чатта булган, хәзер сүтелгән.

[8] Аршин — метр системасы гамәлгә кертелгәнгә кадәрге озынлык үлчәү берәмлеге, 71 см. га тигез.

[9] Учительская школа — Казанда 1876 елда ачылган Татарская Татарская школа күздә тотыла. Монда татар мәктәпләре өчен урыс теле Уукытучылары әзерләнгән (хәзерге Тукай урамы, 73нче йорт).

[10] Габделгаллэм мәдрәсәсе — XIX йөзнең икенче яртысында ачылган, үз чорында зур мәдрәсәләрдән саналган Күл буе мәдрәсәсе, Башта мөдәррисе Галләм хәзрәт, ул үлгәч, Касыйм хәзрәт исеме белән йөргән (хәзерге Комсомольская урамы, 28нче йорт. Проект-техника институты урнашкан).

[11] Әхмәров — Шаһбазгәрәй Исмәгыйль улы Әхмәров (1853-1900) педагог, Татарская учительская школаның директоры.

[12] Университетта укыдым — К. Насыйри берара Казан университетында ирекле ирекле тыңлаучы булып йөри.

[13] Аять — Коръән сүрәләрендә билгеле бер мәгънәгә ия булган аерым җөмләләр.

[14] («Нөҗүм әл-форкан» «Коръән йолдызы») — 1902 елда Оренбургта басылган, Коръәндәге сүзләрне алфавит тәртибендә язып чыккан китап.

## Акмулла
## (1831-1895)

Один из ярких представителей тюркоязычного просветительства, поэт трёх народов — башкир, татар, казахов — Акмулла (Мифтахетдин сын Камалетдина) родился 27 декабря 1831 года в д. Туксанбай Белебеевского уезда Оренбургской губернии (ныне Миякинский район Башкортостана) в семье муллы. Получил начальное образование в родной деревне и медресе окрестных селений. Решающее значение в становлении поэта сыграло обучение в знаменитом медресе д. Стерлибаш, где он получил не только основательное духовное образование, но и уроки творчества у преподователя, авторитетнейшего поэта-суфи XIX в. Шамсутдина Заки (существует также версия, что первые уроки поэтического творчества у юноши Мифтахетдина получил также будущий Дэрдмэнд — Закир Рамиев). В медресе Оренбурга и Троицка наряду с дальнейшим обучением по установившейся традиции он давал уроки казахским ребятам.

Последовавшие затем скитания по дорогам Приуралья, казахским, уральским степям, активная пропаганда знаний посредством художественного слова превратили Мифтахетдина в Акмуллу — носителя света образования, защитника демократических низов. На долю Акмуллы выпала важная задача формирования отмеченной творческой индивидуальностью литературы и придания новой жизни каноническим жанрам книжной публицистики, смелого слияния их со стихией народного творчества. Отчётливо это проявилось в смелом смешении разных интонаций, жанров. Так, мадхия и марсия построены у Акмуллы не по образцам насыщенной арабизмами, фарсизмами увесистой книжной лексики А. Каргалый и М. Уметбаева, а по законам свободной эмоционально-метафорической стилизации. Шикаят-жалоба принимает у него форму словесного диспута — айтыша, а мадхия – улена. Во многие письма проникают элементы баита и толгау, кубаира, мадхии.

Этот жанровый синкретизм отчётливо проявился уже в первом напечатанном в Казани типографским способом произведении — «Марсии Шигабетдина Марджани» (1892). Марсия — элегия. Но элегические интонации по поводу кончины выдающегося религиозного деятеля — предшественника просвещения на Урало-Поволжье занимают место лишь в заключительной части объёмного произведения. В остальном — это гимн научному, гражданскому подвигу.

Создавая оду о великом сыне татарксого народа «на казахский лад», поэт-просветитель смело вводит в неё элементы устного творчества трёх народов и

разворачивает их в целостные системы грандиозного здания мадхии. Широко использована в структуре произведения поэтика Корана. Таков образ воды, воплощающий добытую смелым ныряльщиком-гаугас истину знания и просвещения. Образом Марджани Акмулла отстаивает просвещение, прославляет образованность и смело сражается с невежеством, отсталостью, сословной спесью, направляя против них острое жало сатиры. Воплощённые в посвящении Марджани идеалы нашли продолжение в творчестве Акмуллы последующих лет.

## Литература


*Харисов, А.* Литературное наследие башкирского народа. Уфа, 1965, на башкирском языке.

*Гайнуллин, М.* Татарская литература XIX в. Казань, 1986.

*Вильданов, А.* Певец света. Уфа, 1981, на башкирском языке.

*Вильданов А., Кунафин Г.* Башкирские просветители-демократы XIX в. М., 1981.


## Дамелла Шиһабетдин хәзрәт мәрсиясе

Казанда бер фазыйль[1] чыкты алмас булып,
Хаситләре[2] күбәйде, гам, хас булып[3].
Мәгани Җәваһирен[4] колга әйләнгән,
Хәкаикъ[5] диңгезендә гаувас[6] булып.
Мәйданда ул чыкарды артык гайрәт.
Мозмарда сабикълардан чыкты гасрәт[7].
Хәмде лиллаһ бу диарда[8] бездән чыкты.
Мәрҗани Шиһабетдин ахунд хәзрәт.
Караңгыда фанусны[9] кабызган ул,
Кайнар сөткә сары майны тамызган ул,
Янбугессәламәттән[10] юллар ачып,
Әнһарел хәкаекъны[11] агызган ул.
Сүз кузгар ул ир асыл кирәк җирдән,
Ходаем фәрасәтле[12] йөрәк биргән.
Мөһәндисләр[13] сизмәгән җирдән казып
Чыгарды татлы суны тирән җирдән.
Болагы[14] саф, чәйгә һәркем су алгандай,
Хаклыкка чүлләгәннәр[15] куангандай,
Дөррәсеннән канча бала сөткә туеп,
Башкалар була калды су алгандай...
Тәхкыйкьларын күргән адәм куангандай
Голямага сәрдар[16] булып туалгандай.
Мөбарис[17] мәйданына бу чыккансың
Батырлар була калды җугалгандай.
Аңнаусыз һич кем аңа тотынмас,
Анау-монау кеше имәс чобалгандай,

Палуаннардан[18] егылып бу күргән юк,
Бигене[19] берәү алса, бу алгандай.
Мөселманга каршуга лаек имәс,
Инсафлы урыс күрсә, инангандай.
Ул бер фэзыйль голяма[20] узган таптан
Хаззы[21] бар дәрәҗәи иҗтиһадтан.
Әгъласына[22] җан аямай каршы торып,
Аның өчен мөҗаһид[23] без алгы сафтан.
Дәкаекъта[24] мөшкил чишеп калдырган ул
Бишйөз елгы батырларны талдырган ул.
Мисленә әһле гасыр гадил[25] тапмай,
Йөрәген мөганитиен[26] яндырган ул.
Һәр йирдә сәндә[27] илә сүзе баһир[28]
Хәленә кала шаһит көндәй заһир[29].
Бу заманда туган юк аңа назыйр[30]
Мәгърифәтерриҗал[31] да мондай маһир.
Үтә алмайлар эзеннән басып анын
Китә алмайлар юлыннан ашып аның.
Хак нурын сүндерә алмай мөганитләр[32]
Күрә алмайлар галәмгә фашын аның.
Аһ дәрига![33] Баралмадым кашына аның
Сизенә артыкча мин гашыйк аның.

* * *

Мин үзем бер дәрдемәнд[35] диванамен,
Кайда бер тәхкыйк[36] күрсәм куанамын.
Бу затта гаҗәп тәхкыйк күргәннән соң
Биззарур[37] шул сәбәптән хуп аламын.
Мәҗлесенә карай гына гаугамыз бар,
Кодогына[38] карай гына каугамыз[39] бар,
Эрбет менән[40] Мәкәрҗәгә чама кайда,
Базарына карай гына сәүдәмез бар...
Абруем артык юк, эшем такыр.
Яшьтә җыйган бер буаз можмогым бар,
Аның һәм бәгъзы җире такыр-макыр.
Ул заман китап кайда бу замандай,
Йөримен тирән йирдәп су ала алмай.
Бер шәрик калын китап остан торса.
Кызыгып, мин фәкыйрьнең күзе аландай.
Үги ана кулында ятим калдым,
Аннан да бик эрәтем китеп калдым,
Өстемдә керле күлмәк, ертык дамбал[41]
Кайда мулла[42] бар дисә, җитеп бардым.
Фәкыйрьлектән артык фән күрә алмадык,
Шәһәр чыгып алыс якка йөрә алмадык,
Мәргәннәрне[43] таныйрлык хәлебез бар.

Шул сәбәптән сабыр кылып тора алмадык.
Аз гына дәресем бар кыш вакытта,
Китап карау гадәтемез буш вакытта.
Бездән дә фәез бабы[45] бикләнгән юк,
Аңлаймыз кәеф килгән хуш вакытта...

Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. Казан, 1979 ел.

## Аңлатмалар

[1] Фазыйль — олы, хөрмәтле.
[2] Хасит — көнчелек итүче.
[3] Гам, хас булып — төрле катлаулар арасында.
[4] Мәгани щәваһирен — акыл җәүһәрләрен.
[5] Хәкаикъ — хакыйкатьләр, чынлыклар.
[6] Гаувас — диңгездә чумучы (водолаз).
[7] Үзеннән элеккеләргә билгеле булмаганнарга төшенде.
[8] Диарда — мәмләкәттә, җирдә.
[9] Фанус — фонарь.
[10] Янбугессәламәттән — сәламәтлек чыганакларыннан.
[11] Әнһарел хәкаекъ — хаклык елгаларын.
[12] Фәрасәт — айлылык, зирәклек.
[13] Мөһәндисләр — инженерлар.
[14] Болагы — чишмәсе.
[15] Чүлләгәннәр — сусаганнар.
[16] Голямага сәрдар — галимнәргә баш.
[17] Мөбарис — ялгызы сугыш.
[18] Палуаннардан — пәһлеваннардан.
[19] Бигене — бәйгене, алдынгылыкны.
[20] Фәзыйль голяма — хөрмәтле, сирәк очрый торган галим.
[21] Хаззы — өлеше.
[22] Әгъдасына — дошманына.
[23] Мөҗаһид — тырышучы.
[24] Дәкаекъта — фикерләүдә читен.
[25] Әһле гасыр гадил — гасыр кешеләре ана тиндәш.
[26] Мөганитнең — каршы торучының.
[27] Сәнд — дәлил.
[28] Баһир — көчле.
[29] Заһир — ачык.
[30] Назыйр — тиндәш.
[31] Мәгърифәтерриҗал — укымышлы ирләр арасында.
[32] Меганитлар — дошманнар.
[33] Аһ дәрига — ничек аяныч.
[34] Дәрдемәнд — кайгылы, монлы.
[35] Тәхкыйк — дәреслек, хаклык.
[36] Биззарур — чарасыз, кирәк табып.

[37] Кодог — кое.
[38] Каугам — чиләк.
[39] Менән — белән.
[40] Дамбал — штан.
[41] Мулла — бу урында укымышлы кеше.
[42] Мәргән —төз атучы, бу урында оста шагыйрь.
[43] Фәез бабы — бәрәкәт ишеге, иҗат булдыклылыгы.

## Муса Акъегет
## (1864-1923)

Муса Акъегет (Муса Акзитов, сын Мухаметжана) родился 3 декабря 1864 г. в известном как родина русского литературного критика В. Белинского г. Чембаре Пензенской губернии в семье татарского чиновника средней руки. Край известен также как прародина татар-мишарей, переселившихся от насильственного в XVI-XVIII вв. крещения во множестве на Поволжье и Урал.

После окончания русской школы и гимназии в г. Пензе пытается поступить в университеты г.г. Петербурга и Москвы. Завершает образование в высшей школе Турции, готовящей служащих для государственных учреждений, и остаётся жить в этой стране. Преподаёт русский язык в училище для военных, издаёт газету, некоторое время служит главой уезда. С 1914 года — сотрудник Стамбульской научной библиотеки. Проводит большую работу по описанию русских изданий подаренной миссионером, учёным Н. Катановым библиотеки, публикует научные, публицистические трактаты на турецком языке. Один из предшественников и приверженцев джадидизма, автор первого татарского национального романа «Хисамутдин менла» (опубликован в 1886 г. в Казани также впервые на кириллице).

Через весь роман, находя отражение в расстановке действующих лиц, публицистических описаниях, отступлениях, проходит сквозная идея совершенствования Ислама, необходимости перемен, отстаивание роли и места передовых людей в жизни нации.

## Литература

*Мусин, Ф.* Муса Акъегет «История татарской литературы». Т. 2. Казань, 1985.

*Айди, Т.* Муса Акъегет в Турции. «Казан утлары», 1996, № 4.

## Хисаметдин менла
## (Милли роман яки хикәя)
## (1886)
## I

Россия уртасында Идел нәһереннән[1] озак дәгел бер татар авылы мәүҗүддер[2]. Карьянең әһалисе ике йөз кадәр өй булып, атьшы фаш итмәктән чикенәйөрез[3], анчак хикәябезне җиңел аңлатмак өчен, атыиы «Н» хәрефе илә ишарә итәбез. «Н» карьясенең ханәләре гади ханәләр кебе агачтан вә башлары бәгъзаи саламнан, бәгъзаи агачтан ясалмыштыр. «Н» авылында ике мәчет вар. Бер урамлы авыл булып, урамы озын вә киңдер. Урамы озаеп, кыйбла тарафындагы очында борылып, суга юл чыкадыр.

Әһалисенең башлыча мәгыйшәт өчен хезмәте игенчелек-тер. Ләкин чук халыклары башка шәһәрләрә, мәсәлән, Астра-хань, Ростов, Казан кебекләрә эш вә тиҗарәт өчен дагыларлар. Иштә «Н» көендә урта җамигъдан[4] ерак дәгел бер кечек ханә вар.

Бу ханә үзе кечек булса да, тактадан башы, анбары вә мөхкәм сарайлары сахибенең иҗтиһатлы вә хезмәт сәвән адәм идегене күрсәтерләр иде. Бу ханәдә менла кадыны тол Зөлхая вә угылы Хисаметдин менла атлы адәмнәр торырлар иде. Менла Хисаметдиннең мәрхүм атасы указный менла бул мыш исә дә, угылы атасының җәһәтенә мовәффәкъ уламады.

Ике-өч ел моннан Мокатдәм менла Хисаметдин госманлы җиреннән тәхсиле голүм илә ватаны «Н»гә кайтты. Хәзердә кәндүсе[5] ханәсенең икенче бүлмә чигендә сабыйларга дәрес вирер иде. Йонлыларның бәгъзылары Хисаметдин менлая рәгъбәт[6] (идәрләр иде, чөнки ике сәнә зарфында[7] язу язмак, хат танымак, гыйльме хисап, гыйльме хаЛь балаларына үгрәтте; әмма чук адәм менлаи яхшы белмәдекләреннән сәүмәзләр иде, мәсәлән, карьянең указный менласы карт Бикбулат менла әфәнде Әхмәтша угылы, хәсәдлек итеп[8], аны сәүмәер иде вә мәҗлесенә кәләннәрә дәер иде: «Ничөн бу диле җаһилә[9] балаларыгызны вирәсез, тәүфыйктан чыгарыр, китерегез бәнем үз мәдрәсәмә, ул иҗек угрәтмәс, тутрыдан-тугры сүрә укытыр, аның. ысулы тәдрисс җаиз дәгел[10], мәсәлән, аба укытыр, әмма әүвәл әлиф селтә босенбә кирәк». Вә бәйлә асылсыз сүзләр илә Хисаметдин менлаи хурлар иде. Чук халык карт менланың сүзенә шәригать сүзе кебек инаныр иде. Әмма Хисаметдин мәктәбендә укытмыш вә тәҗрибә итмеш кешеләр карт менланың буш сүзләренә инанмаеп, Хисаметдин меилая кәмал рәгъбәттә тотарлар иде. Хисаметдин менла исә дәгел нәхүләр, сарыфлар, хәтта гыйльме фикъһедән[11], хәтта «гыйльме хикмәттән» Истам-булда шәкертлектә тәмам хәбәрдар улды. Татар менлаларының бәгъзылары, үзләре аз белдекләрениэн, чук биләп башкалара хосәдлек итеп сәүмәдекләре мәгълүмдер.

Хисаметдин менла хәрәкәт вә кәсеп сәвән менла иде: ун дисәтинә кәндүсенең җире вар иде. Гәрчә бер хезмәтче тотса да вә чук дәфга яз вакыты иген эшендә башка хезмәтчеләр яллаcа да, эксәре[12] үзе дә кара иген эшене эшләер иде. Моннан бәйлә Хисаметдин менла рәхәт вә гайреләрә ихтыяҗсыз мәгыйшәт идәр иде. Хикәябез якындагы кочмеш заманнара мөтәгал-ликътыр[13]. Кыш якынлашмыш вакытлар. Җомга көн намаздан әүвәл Хисаметдин менла кәндү ханәсендә «Тәфсире бәйзави» китабыны моталага кылыр.

Йөзенә баксаң, бу егерме биш яшьлек егеткә тогаҗҗеп-ләнерсең. "Йөзе гүзәл ачык. Яңадан чыкмыш кечек сакалы вә мыеклары вә кечек чәче коңгырт рәңдә[14] улып, җәмаләтле йөзеннән гүзәллеген дәһа зиядәләштерерләр[15]. Нурлы вә

күк күзләре сәтра бәсотра сәхифәгә[16] йөгереп кәчәерләр. Башында бархат тәкъясының көмеш ае ялт-йолт ялтырар.

Тәфсири куйды. Бүлмәсендә гизәер. Йөзеннән тирән фикерә талдыгы беленер. Гизгәндә биек бусны вә ию кыяфәтене күрсәң, гашыйк улырсыц. Шул әсиадә[17] тирәзәдәи волостной идарәсе хезмәтчесенс күреп капуя[18] тугры варып: «һай кил-деме?» дию шатланып кычкырды. Мәркум[19] хезмәтче, «килде», диеп моңа бер кәгазь вирде. Кәгази алып, егет знядәсилә мәсрүр[20] булды. Мәзкүр кәгазь — Россия исламнарының сәла-мәтепе вә хөсне мәгыйшәтенсе мөхафәзә идән[21] «Тәрҗеман» җәридәсе[22] иде. Хисаметдин менла кәндү милләтеме, ягъни татарларны чук сәван адәм иде. ...Хәтта Бикбулат менла кәпдусене дошман күрсә дә, ул һич дошман күзе белән аңа-бакмаз иде. Чөнки яхшы белә иде ки, бу дошманлык хәсәдлектән кәлер. Хәсәдлек кеби бөек бәләя мөбтәлә улап адәми Хисаметдин менла дәгел дошман күрмәк, билгакес[23] аяр иде. Мәзкүр җәридәи ачып укымая башлады, вә шурасы[24] тәгаҗ-җептер ки, әшкярә укыймая башлады:

«Ушбу номер илә «Тәрҗеман»ның ярым еллыгы тәмам ула. Бу номерә алдыгымыз... вәдәһа вә дәһа... һәр нә кадәр мөшкилатле вә көч бер эш исә дә, күпнең файдасы мәэмүл[25] улыпып зәхмәтеннән...» ахырына дик бәнди бәйлә укыйер... «Бән улаем, сез улыңыз бер фәкыйрь, бер байгуш күрсәк, җанмыз агырып, кайгы хасил булыр. Бер хәстә, хәлсез күрсәк, ярдәм бирмәя гыйлаҗ вә чара үгрәтмәк морат идәрез; я үлем түшәгендә яткан бер кеше күрсәк, күземезә — яшь, күңелемезә мәрхәмәт кәлер, дәхи дәрдә мөбтәлә хайван күрсәк, аҗыеп[26] ах-вах идәмез дә, бер дәгел, биш дәгел, беңнәр илә дин вә дил кардәшләремезнең төрле дәрдә мөбтәлә улын, наданлык вә һөнәрсезлек кеби ике олуг вә гаддар[27] дошманың эленә[28] төшеп җан ташладыгыны күрмәсп, җаныбыз тоймаеп, күңелемез агламаеп, гакылымыз чаралар кыдырмаеп тордыгымыз чук язык, вә тәгаҗҗеп дәгелмәйдер». Шул җирдә Хисаметдин менла мөтәәссир улып туктады вә күзләре бераз суланды. Бер-ике фикердән соңра укымая дәвам итеп: «Әвәт, чук тәгаҗҗептер ки, бер адәмнең хәленә мәрхәмәт идәрез[29] дә, бер миллион адәмә — бер милләтә мәрхәмәтебез юктыр»... Бу җирдә үз-үзене тота алмаеп, менла агламага башлады вә укымая тәкате калмаеп, анҗак «Афәрин, Исмәгыйль кардәшем» сүзләрене дия белде.

Бөйлә ачы агламагы ишетеп, анасы ханәя керер.

— Нәхәл, угылым?

Хисаметдин кәндүсене забыт илә: «Аначыгым, бер шәй юк, атамый ядыяма алдым, кайгыландым», — дию җавапланды.

Хәлбуки, укучыларыбыз! Ул атасыны һич ядына алмады. Россиядә сакин[30] ун миллион ислам кардәшләрене ядына алды. Атасы нәя лазем[31]. Ул вафат, алла җәннәт вирсен. Әмма ун миллион мөселман тере калды. Аурупадан башка госманлылар вә мисырлылар, вә һиндлеләр безем наданлык вә гафләттән көләләр, һәйһат! Әмма мәгълүматлы улмак өчен нә лазем? Укымакны сәүмәк лазем дия фикерләнә-фикерләнә, Хисаметдин менла кинә утасында[32] гизмәя башлады. Суланимыш «Тәрҗеман»и исә сөфрәя быракты[33].

“Татар мәгърифәтчелек әдәбияты” китабыннан, Казан, 1979.

**Аңлатмалар**

[1] Нәһер — елга.
[2] Мәүҗүддер — бардыр.
[3] Чикенәйөрез — чигенәбез, тартынабыз.
[4] Җамигъдин — мәчеттән мәгънәсендә.
[5] Кәндүсе — үзе.
[6] Рәгъбәт — теләктәшлек.
[7] Ике сәнә зарфында — ике ел эчендә.
[8] Хәсәдлек итеп — көнчелек итен.
[9] Диле щаһилә — юләр наданга.
[10] Ысулы тәдрисе җаиз дәгел — укыту методы дөрес түгел.
[11] Фикъһедән — ислам дине мәсьәләләре турындагы белемнән.
[12] Әксәре — күп вакытта.
[13] Мөтәгалликътыр — карый, бәйләнгәндер.
[14] Рәңдә — төстә.
[15] Дәһа зиядәләштererләр—тагы да арттырырлар.
[16] Сәтра бәсәтра сәхифәгә — китап битенең юлыннан юлына.
[17] Әсна — вакыт, чак.
[18] Капуя — капкага.
[19] Мәркум — әлеге.
[20] Мәсрүр — шат.
[21] Хөсне мәгыйшәтене мөхафәзә идән — күркәм тормышын саклаган.
[22] Җәридә — газета.
[23] Билгакес — киресенчә.
[24] Шурасы — шунысы.
[25] Мәэмул — өмет ителгән,
[26] Ачыеп — ачынып.
[27] Гаддар — мәрхәмәтсез.
[28] Эленә — кулына.
[29] Идәрез — итәрбез.
[30] Сакин — торучы, яшәүче.
[31] Нәя лазем — нигә кирәк.
[32] Кинә утасында — янә бүлмәсендә.
[33] Сөфрәя бырактыы — өстәлга ташлады.

## Ризаэтдин Фахретдин

Убеждённый в возможности исправить нравы общества и людей силой знания и веры, писатель Р. Фахретдинов — джадид, стремится изображать своих героев открытыми наступающим на смену патриархату новым веяниям жизни. Человек в этих условиях предоставлен самому себе, и гарантом его стойкости перед испытаниями жизни является лишь вера и знание: только их единство способны стать ему опорой. Такова основная идея рассказа «Шакирд и студент»,

по объёму и проблематике близкого к характерному для поэтики просветительства повести-трактату.

## Бер шәкерт илә бер студент
## (Пароходта)
## (1900)

1900нче елда июнь аеның... нче көнендә, Казаннан Чистайга китмәк өчен, Каменский компаниясенең «Алексей» исемендәге пароходына кердем. Иртә белән сәгать 9 тирәлә-рендә пароход кузгалачак. Көн бик яхшы, бер яктан ялтырап кояш чыккан. Нәрсәләремне второй класска кертеп бер урынга куйгач, пароходның өстенә чыгып утырдым. Вә пристань халкыны сәер итәргә башладым.

Пароходка өлгермәк өчен ашыгып-ашыгып һәр яктан төрле-төрле кешеләр киләләр. Өсләренә-башларына бик яхшы нәрсәләр киенгән берничә руслар вә рус хатыннары пароходка утырмак өчен конторның күпереннән керәләр иде. Нәрсәләрене хезмәтчеләрдән күтәрткәннәр, үзләре арттан киләләр. Менә аларның артыннан бер-ике татар килеп җиттеләр. Икесенең дә берәр кулларында зур паласларга төреп җеп белән бәйләгән вә өсләренә берәр комган таккан нәрсәләре вә икенче кулларында калай чәйнекләре бар иде.

Берсенең башында бик керләнгән ак чалма, өстендә җиңнәре бик майланган вә төсе киткән яшел чапан. Икенчесенең башында авызы тар, түбәсе киң бер ак бурек, өстендә дә бик киң чабулы җилән иде. Ләкин ак җиләннең күкрәгендә берничә җирдәге кап-кара таплар бик ерактан аермачык күренеп торадыр иде. Мин бу тапларны коймак ашаганда тамган май таплары булса кирәк дип исәпләдем.

Болар бик ашыгып пароходка керәләр иде. Күпер өсте бик тыгызлык, кайсы керә, кайсы чыга. Ике ягында да тарак, шырпы, каеш, портмонет, лимон, әфлисун сата торган татарлар, сөт, булки сата торган руслар вә марҗалар утырганнар.

Ак җиләнлесе: — Мулла Г. абзый, әйдә тизрәк керик, пароход китә торгандыр, ахрысы, — дип, алдан вә чапанлысы арттан киләдер иде. Бераз килгәч тәмам пароходка кереп җитәр вакытта югарыда сөйләдегебез господаларның артларыннан җиттеләр, һәм дә бик ашыгып аларны узып киткән вакытта берсенең нәрсәсенең өстенә бәйләгән җиз комганы бнк яхшы киемле бер марҗаның кулына таянып керә торган бик кыйммәтле зонтигына бәрелде. Зонтик дәрхаль марҗаның кулыннан төшеп китте. Ак җиләнле адәм дә калын подметкалы кәвеше белә тәмам өстенә басты. Зонтик та шартлап икегә сынды.

Шуның җирендә сез булсагыз нишләр идегез? Кабахәтегез өчен туктап марҗадан гафумы сорар идегез? Юкса, һичбер нәрсәгә карамаенча вә полицейскийның туктатуын да хәтергә китермичә туры пароходкамы кереп китәр идегез? Сезне белмим, ләкин бу адәмнәр туры пароходка кереп китәчәк булдылар. Ак җиләнлесе, бик ашыгып, нәрсәсен дә кулыннан кулбашына күтәрде. Яшел чапанлысы моның артыннан килә. Бер Жандармский алдагысыны килеп туктатырга теләгән вакытта нәрсә өстенә бәйләгән комган жандармскийның башына бәрелмичә аз гына калды. Бөтен халык көлештеләр. Зонтигы сынган марҗа да ул адәмне туктатмыйча җибәрмәк өчен жандармскийга ишарәт итте.

Безнең ак җиләнле вә чапанлы кешеләр дә, атылган яшен ташлары кебек, пароходның эченә кереп киттеләр.

Арасы күп тә үтмәде, артта бер зур чалмалы вә озын җиңле буй-буй бикасәп чапан кигән бер адәм илә, башыңа кечкенә генә кара бүрек, өстенә бишбилле кара казаки кигән вә сәгать чылбырын да казакиның өстенә салып җибәргән башка Бер адәмнен пароходка кергәне күренде.

Бераздан пароход өченче свисток бирде. Чалмалы, ак бүрекле, чапанлы, озын җиләнле берничә адәмнәр пароходтан йөгерешә-йөгерешә чыктылар. Конторга чыккач та барысы да кулларыны баглап, бик тәгъзыйм[2] берлә пароходка борылып тордылар. Пароходка иң арттан кергән бикасәп чапанлы кеше зур бер ишан хәзрәт яисә бер мөдәррис вә коптордагылар аны озатырга төшкән меридләре булса кирәк дип исәпләдем. Минем бу исәбемнең тугры чыкдыгы бераздан сезгә дә мәгълүм булыр.

Пароход акрын-акрын кузгалып пристаньнан аерылды. Мин дә үземнең урыныма төштем. Второй класста миннән өч урын аркылы бая сейлодегем бикасәп чапанлы ишан хәзрәтнең кара бүрекле иптәше белән утыргаиыны күрдем. Ничек булса да бу хәзрәт белән танышып бер сөхбәт итәсем (сөйләшеп утырасы) килде. Локин ничек итеп күрешергә кирәк? һич тә белмәгән кешегә туп-туры барып: «Исәнме, хәзрәт?» димәк бик ошап бетми. Кисәктән хәтеремә бер фикер килде. Пароходка кергәндә комганы белә бәреп марҗаның зонтигын сындырган ак Җиләнле адәмне күреп сөйләшәем. Бәлки, ул берәр шәкерттер. Аның белән таиышмак җиңелрәк булыр. Аннан болариы да сорашып, кем булганнарын белермен дә, соңыннан күрешермен дидем. Второй класска бер кат күз салдым; безнең сахибелкомганнар[3] анда күренмәделәр. Өйлә исә алар өченче класста булырга кирәк дип анда чыктым. Пароходның койрыгына таба киттем. Менә бер җиргә халык җыелган. Сүгешкән, кычкырышкан тавышлар килә. Русларның кайсы көлә, кайсы кычкыра. Якынрак барып карасам, уртада ак җиләнле илә яшел чапанлы адәмнәребез утыралар. Алларына кызыл киҗедән суккан бер ашъяулык җәйгәннәр. Аның өстендә бер якта бер калай чәйнек берлә ике пар чынаяк, бер якта бик майланган бер ак капчыкның авызыннан ат казылыгының яртысы күренеп тора. Бер башыннан кисеп алып, кулъяулыкка бераз турап куйганнар. Ул да ашъяулык өстендә тора. Тирә-якларына руслар җыелган. Ак жиләнлесе алар белән кычкырыша башлаган. Бераздан уртага башка кешеләр кереп кычкырышуны бетерделәр. Үзем мин алардаң бик ерак түгел бер рус янына утырып бу низагның ни өчен чыктыгыны сорашырга башладым.

Рус әйтә: яшел халатлысы әнә шул калай чәйнек белән абдәстханәгә[4] китте. Анда бик озак торып чыкты. Аның кулыннан калай чәйнекне ак халатлысы алды да буфетка барып су алып килде. Чәй эчәргә башладылар. Аннан соң әнә шул ат итен чыгарьш ашарга башладылар. Куллары майланадыр. Аны аякларындагы читекләренә сөртәләр. Боларны карап тора торган — аларның янындагы руслар үз араларында сөйләнеп көлешә башладылар. Ак халатлысы: — Ник сез безнең динебезне мәсхәрә итәсез? — дип, аларга ачулана башлады. Руслар: — Без сезнең динегезне мәсхәрә итмибез, тик без абдәстханәгә кереп чыккан чәйнек белән чәй эчүе күңелне болгандырмый микән вә читеккә сөрткән майлар халатларга буялып кешене сасытмый микән, дип бер-беребездән сорашабыз. Без сезнең динегезне

белмибез. Бәлки, сезнең динегез алай кушмый да торгандыр, диләр. Моның өстенә низаг ачылды.

Алар чәйләрен эчәргә, ат казылыгын ашарга башладылар. Ашап-эчеп бетергәннәрен читтәрәк бераз көтеп тордым. Сонра яннарына барып сәлам биреп күрештем. Бер урын күрсәтеп утырырга ишарәт иттеләр. Утырыр-утырмас руслардан шикаять итәргә башладылар. Мин болардан акрын-акрын гына үзләренең кем булганнарын вә сәфәрләренең кая таба булганын сорашырга башладым.

Второй класстагы бикасәп чапаилысы Казаи тирәсендә мәшһүр бер мөдәррис вә ишан икән. Аның янындагы кара казакилесе дә аның Бер бай мөриде икән. Кызын кияүгә биргән дә ишан хәзрәтне туйга алып бара икән. Боларның да яшел чапанлысы ишан хәзрәтнең кияве вә үз янында иптәш мулласы, ак жиләнлесе бер пишкадәм[5] һәм шәкерте икән.

Аннан-моннан болар белән бераз сөйләшеп утыра идек. Кисәктән генә ак жиләнлесе: — Ә-ә-ә, менә... менә, мулла Г. абзый! Баягы сүзнең кайда икәне хәзер келт итеп хәтеремә төште, — дип сикереп торды. Букчасын чишеп бер китап чыгарды. Кәгазьләрен берәр-берәр актармага башлады. Китапның эчен күргәч тә ни китабы икәнен таныдым. Сөлләм казые икән. Хашияи дәһерене[6] ачып бер җирдән күрсәтте. Аз гына тыңлап торгач, үзләреннән сорамыйча да аңладым ки, бәхәсләре «хөдусе галәм»[7] үзәренә икән...

Әлхасыйл, сүз сүзне тартты: әлифламнын биш төрле мәгънәсе дә зикер ителде. Байтак сөйләштеләр. Мин дә тыңлап утырдым.

Алар бәхәснең нидән ачылганыны, сүзнең кайда киткәнен күптән оныттылар. Мин дә көчкә генә исәпләп таптым да үз-үземнән сорадым: — Я, менә безнең егерме ел укыган пишкадәмнәребезнең гыйлемнәре, бәхәсләре. Бу бәхәстән я дөнья, я ахирәт өчен үзләре никадәр файда иттеләр? Я исә мин бер сәгать гомер исраф итеп тыңлап утырдым. Ни файда иттем? (Мондаен сафсаталар белән гомер чертеп тә, дөнья вә ахирәт өчен файдалы гыйлемнәрне үгрәнмәгәнлегебез өчен милләте-безнең хәленә бик шитдәтле тәәссеф[8] иттем.

Алар кинә шунда сөйләшә калдылар. Мин дә торып киттем.

Второй класска кереп үз урыныма килдем. Хәзрәткә күз салдым. Хәзрәт Коръән укыйдыр иде. Укып бетергәнен көтеп тордым. Үземә калса бик әдәп вә тәрбия белән башымны иеп, күземне түбән карап, кулымны баглап, тавышымны нечкәртеп вә бераз калтыратып хәзрәтнең янына барып сәлам бирдем. Вәгаләйкем әссәлам, дип сәлам кайтарды. Бик бөгелеп кенә кулын үбеп күрештем. Үзе ишарәт иткәч, янындагы буш җиргә бик кысылып кына утырдым.

Тирә-яктан господалар бар да безне театр кебек сәер итеп торалар иде. Утыргач та ишан хәзрәт кул күтәреп бер дога кылды. Аннан соң, һичбер сүз сөйләмичә, күзләре белән башымнан аягыма кадәр бер мәртәбә сөзеп өстемә карады. Минем өстемдә дә кыска киемнәр иде. Боларны күргәч хәзрәтнең чырае бераз бозылыбрак: «Миндә ни йомышыгыз бар?» — дип сорады. «Тәкъсир, бер йомышым да юк, мәхез[9] сезнең, белән күрешмәк өчен килдем», — дидем.

Яхшы алай булса, алла истикамәт[10] насип әйләсен, диеп кулларын күтәреп тагын бер дога кылды. Хәзрәтләр вә ишаннар тирәсендә йөргән адәмнәргә мәгълүмдер ки, аларның бу икенче догалары «эшең бетте, бар, бар, кит инде»

дигән сүздер. Безгә дә торып китмәк лазем булды. Хальбуки минем хәзрәт берлән бераз сөйләшәсем киләдер иде. Ничек итеп янында тагын бераз утырып, аннан-моннан сүз ачыйм дип бер ләхза[11] эчендә исәпләп алдым. Хәтеремә бер тәдбир килде. Бик тиз генә кесәмнән портмонетымны чыгарып эченнән бераз акча алдым. Шул сәгать хәзрәтнең уң кулы кыймылдамага башлады. Мин акча тоткан кулымны хәзрәткә таба сузганчы хәзрәтнең, кулы мина таба сузылган иде. Чөнки ул тәбәррек куллар бу бабта бик мәләкә[12] хасил иткәннәрдер. Садаканы алгач ишан хәзрәт тагы бер дога кылды. Чырае бераз төзәлеп, түбән таба карап тора торган күзләрен бераз ачты, тавышын борыныннан чыгарып кына: «Сез кем буласыз?» — дип сорады. Дәрхаль җавап бирдем. Биргән җавабымны да хәзрәттән тагын ничә сөальләр соратырга юл хәзерләп сөйләдем. Ләкин сорамый. Нишләргә кирәк? Тагын сөхбәт бетә, торып китәргә кирәк була. Мин шулай аптырап торган чакта гына хәзрәт миңа: — Ник соң сип мондаен киемнәр киясен? — диде.— Сок, хәзрәт, нинди киемнәр кисәм яхшы булыр икән? — дидем. Хәзрәт миңа истихфаф[13] белән карап җылмаеп көлде дә: — Мөселман киеме кисәгез яхшы булыр, — диде. Мин: — Хәзрәт, берүк гафу итегез, безнең гыйлемебез бик аз. Без хәзергә чикле күргән, укыган китапларыбыздан аңладыгымыза күрә, иман вә исламны кием белән булмый, калеб белән була! Бер кеше аллаһның берлеген, Мөхәммәд галәйһиссәламнең хак пәйгамбәр икәнен тасдыйк итсә, өстенә, башына ни кисә дә, ул кеше халис мөэмин вә мөселман була; бинаән галәйһи киемдә мөселманлык вә гайре мөселманлык булмый дип беләдер идек. Аллаһ тәгалә, яисә пәйгамбәр галәйһиссәлам тарафыннан мөселманнарга махсус бер кием тәгысн ителдегеннән хәбәрем юк иде. Сәтре гаурәтнең[14] фарыз икәнен белсәм дә, аның җилән яисә бишбилле казаки белән булуы лаземдыр дип белмидер идем. Ак бүрек, сары читек, савырлы кәвешнең Хәдис яисә Фикъһе китапларында зикер улынган йиренә бер дә рас килмәдем. Әгәр болар сезгә мәгълүм булса, безгә дә бәян итсәгезлә, — дидем. Хәзрәтнең чырае тагы да бик бозылды. Мин сөйләп бетергәнче көчкә генә түзеп торганыны аңладым. Кулларын күтәрде, тагын бер дога кылды. Күп сөйләгәнем өчен гафу итмәсене рәҗа[15] итеп акрын гына торып киттем.

Хәзрәт белән күрешүдән минем максудым дөнья вә ахирәт өчен аннан файдалы сүзләр ишетмәк вә татлы бер мөсахәбәт итмәк иде. Ләкин ни чара! мөмкин түгел, һич мөнасәбәтсез вә лозумсыз җирдә кешенең өстендәге киеменә ябыша. Бераз эчем пошты, күрешкәнемә үкенә башладым: чөнки сөйләгән сүзләрем, бәлки, хәзрәткә каты да килгәндер. Фәкать үкенмәк файда бирмәс. Эш булды, бетте.

Пароходның, өстенә чыгып утырдым. Пароход Лаешка җитеп киләдер иде. Һава бик яхшы. Җил-фәлән юк. Суның өсте ашъяулык кебек тип-тигез. Ике якта ямь-яшел агачлар күренеп калалар. Шул чаклы хозур вә кәефле Ки — мондаен җирләрдә дөньяның бөтен кайгы вә хәсрәтләре онытылып, күңелләр ачылып китә.

Пароход Лаешка килеп җитте. Бәгъзылар керделәр, богъзылар чыктылар. Күп тормады — кузгалып китте. Мин югарыда бер утыргычка утырдым. Тирә-якны сәер итеп барам. Пароходның өстендә миннән башка берничә руслар вә марҗалар бар. Кайсы утырган — гәзит укый, кайсы карап бара, кайсы йөри.

Менә бераздан хәзрәт кияве белән пишкадәм югарыга менделәр. Шул сәгать һәр кешенең күзе ирекле-ирексез боларны бер сөзеп алды. Кайсы иптәше белән пыш-пыш сөйләшә башлады. Кайсы мыек астыннан җылмаеп көлә башлады. Кешедән көлгәннәре өчен әүвәл русларга ачуым килде. Ләкин бераз исәпләгәч, мондаен җирләрдә бу кыяфәтләр белән йөреп, мөселманлыкны мәсхәрә иттергәнлекләре өчен үзләренә ачуым килде. Минем янымдарак утыргычка килеп утырдылар. Бик кычкырып-кычкырып сөйләшергә башладылар. Хәзер бәхәсләре — шәйэ мотлак илә «мотлакы шәй» арасындагы фәрыкның[16] исбатында икәнен сүзләреннән аңладым.

Бераз сөйләшкәч, хәзрәт кияве, чапанының итәген ачып, кулын кесәсенә тыкты. Уртача гына зурлыкта бер шешә чыгарды. Эчендә борыч кебек кара нәрсә булганы күренәдер иде. Шешәнең авызын ачты, сул кулы белән тотып аударып уң кулының учына шешәнең эчендәге кара нәрсәдән бераз түкте. Хәкыйкатәң бу борыч кебек, яисә шомырт оны кебек кара вә салиб[17] бер нәрсә икән. Күзе бер мәртәбә тирә-якка карады. Чалманы азрак басып киде. Башын да Иделгә таба әйләндереп, авызын бераз югары күтәреп, зурайтып ачты да сул кулының учындагы кара нәрсәне кисоктән генә авызына салып җибәрде.

Ярабби ходаем! бу нишли икән дип торам. Авызын йомып, башын иеп, галәме мөракабәгә[18] киткән кешеләр кебек, бераз дөньядан бихәбәр булып утырды. Бераздан соңра урыныннан торып, пароходның бер бащынарак барып авызындагы нәрсәсең Иделгә төкерде. Янәдән иске урынына килеп утырды. Мин юкса бер дәва-фәлән йоттымы дин торадыр идем. Мәгәрсә, ул йотмаган икән, ялгыз авызының эчендә тоткан. Бохарадан тәхсиле голүм итеп кайткан кешеләр хакында эфьюн йотмак, тел астына тәмәке салып тормак кебек берничә хикәяләр ишеткәнем бар иде. Ахрысы, бу да анардан берсе булса кирәк, дип хисап иттем.

Утырган җиремнән мин боларның һәрбер хәрәкәтләренә дикъкать итеп торамын. Бәлки, миннән башка да дикъкать итүчеләр бардыр. Кем белер!

Хәзрәт кияве, пишкадәм янына килеп утыргач, бик кәефләнеп тагын сөйләргә башлады...

Аңлашыла ки: боларнын икесе дә бик күп мөталэга иткәннәр, гыйлем, мәгърифәткә бик зиядә[19] мәхәббәтләре бар. Чөнки пароходта да дөнья сүзе катыштырмыйча гел мантыйктан[20], хикмәттән бәхәс итеп баралар. Болар шулай сөйләшеп утырган вакытта пароходның өстендә яшь кенә бер рус бер баштан бер башка йөреп торадыр иде. Башында картус, картусының тирәсенә зәңгәр бер нәрсә тоткан. Өстендә әллә ниндәен җиз төймәле постау сюртугының да якасыны зәңгәр белән әйләндереп алган. Кулында бер китап бар. Ләкин безнең турыбыздан үтеп киткәндә аз-аз гына күренеп китә. Кулындагы китапның язулары мөселманча кебек, һәр үтеп киткәндә хәзрәт кияве берлән пишкадәмгә туры карап-карап китә. Бәгъзән тукталырга да тели. Тагын үтеп китә. Менә бераздан алар турысына җиткәч тукталды. Якынрак килеп бер кулы белән башындагы картусын алды да, чалмалысына карап: «Сабахекем билхәер, я шәех!»[21] — диде.

Мәхдүм бу ни әйтә икән дип пишкадәмнән сорады. Пишкадәм әйтте, ни дигәнене аңладым. Ләкин мәгънәсенә тиз генә исәпләп алып булмады. Ул безгә «Сабахекем билхәер» диде. Инде бу «сабах» ләфес «сабех» масдарыннан чыга торгандыр. «Сабах» таң вакыты дигән сүз. Ләкин «сабах»ның «кем» замиренә

изафәсе һәм дә «билхәер»нең «ба»сы ни өчен икән? Юкса тиз генә букчадан «Шәрхе мелла»ны алып меним микән дип торган чагында, рус тагы боларга карап: «Сәфәре кем богыйден?»[22] — диде. Болар тагып бер-берсенә караштылар.

Моның үзәренә рус янәдән: «Ма тәгърифүие лисанә пәбне-кем әлләзи онзәлә биһи олкоръан?»[23] — диде. Моңарга да җавап юк. Тик телсез кешеләр кебек тилмереп вә исләре китеп русның күзенә карыйлар. Рус: «Госманлы төрекчәсенә белермиседез?» — диде. «Җук, жук, белмибез», — диделәр. «Алай булса, мин сезнең телне дә беләмен. Шунда утырып сезнең белән әзрәк сөйләшергә рөхсәт итәрсезме?» — диде.

Утыр, утыр, дип урын бирделәр. Ләкин чырайлары бик бозылды. Икесе дә бер-берсенә караштылар... Әмма русның ике сүздән гыйбарәт гарәпчәсенә җавап бирә алмадылар. Җавап бирә алмау гына шулай торсын, ни дигәнне дә аңлый алмадылар. Голәмабызнын хәлен күреп шул дәрәҗәдә эчем пошты, күңелем нечкәрде ки, аулакта булсам, "һичшиксез, җылаган булыр идем.

Яннарына утыргач та, хәзрәт кияве рустан: — Син кем? Кая барасың, ник барасың, хәзер кайдан киләсең? — дип, бердән-бергә биш-алты сөаль сорады. Чөнки безнең татарларның гадәтедер ки, танымаган бер кешегә туры килделәрме, кем икәнен, кая барганын, ни өчен барганын бөтен төбе-тамыры белән сорашырга башлыйлар, һәм дә зурларга вә бихосус, тәгълим вә тәрбия күргән кешеләргә тәгъзим өчен җәмгы сигасе[24] белән дә «сез» дип сөйләүнең лазем икәненнән асла хәбәрләре дә юк. Филхәкыйкать Әхмәтҗан абзыйга, Мөхәммәтҗан кодага теләгәнчә «син» диеп сөйләргә ярый. Чөнки «син» берлән «сез» арасындагы фәрыктан[25] аның үзенең дә хәбәре юк. Әмма мәдәниятле кешеләргә күрә бу ике сүз арасында ул чаклы зур аерма бар ки: әгәр «сез» диеп хитап итү лазем булган бер адәмгә «син» диеп хитап итсәң, башына суккан кебек каты тоеладыр. Үзеңнең хатыныңа вә якын күргән дусларыңа, үзеңнән түбән кешеләргә тәкәллефсезлек берлә русча «ты», татарча «сии» дип әйтергә яраса да, пароходта, тимер юлда туры килгән образованный «мәдәниятле» кешеләргә «син» яисә «ты» дин әйтү зур кабахәт саналадыр. Хәзрәт киявенең сөаленә каршы рус: «Мин ориенталист буламын. Хәзер безнең каникул вакыты булдыгыннан кымыз эчәргә вә тәбдиле һава[26] итәргә барамын», — диде.

Бик яхшы, ләкин бу сүзләр эчендә ориенталист берлә каникул кәлимәләре бар. Болар «Хикмәтел-гаен»дә вә «Сөлләме казый»да асла очраган сүзләр түгел. Голямабыз кинә русның кем икәнен аңламыйча калдылар. Ориенталист әллә русның исеме микән, бәлки, боларга исемен сөйләгәндер. Алай булса, ахырында бер «ов» яисә «ич» улыр иде. Хөласаи: бер сүз дә сөйләмичә аптырашып русның күзенә туры карадылар, рус та бу сүзне аңламаганлыкларыны белде. Янадан башлап, ориен-талист берлә каникул кәлимәләрен аңлатырга башлады.

— Менә безнең мөдәррис белән пишкадәмебез рус студентының каршында торып та гомердә бер кәррә исемен ишетмәгән сүзләрдән дәрес ала башладылар...

Рус диде: менә безнең Россия вә Аурупада бер төрле мәктәпләр бар, ул мәктәпләргә гимназиядәге фәннәрне бетергән шәкертләрне кабул итәләр. Аларга шәрык халыклары, ягъни күбесе Азиядә булган милләтләрнең телләрен өйрәтәләр. Мәсәлән, безнең Петербургта вә Мәскәүдәге шундаен мәктәп-ләрдә: гарәпчә, фарсыча, госманлы төрекчәсе, азәрбайҗан төрекчәсе, чыгътайча, татарча,

һинд вә санскрит, кытай, япон, гыйбрани, сурияни телләре кебек төрле-төрле телләр үгрәтәләр. Ул мәктәпләрдәге шәкертләр берничә кыйсемгә[27] бүленәләр дә һәрбере шуларның арасыннан икешәр, өчәр төрле тел өйрәнәләр.

Менә шундаен телләрне өйрәтә торган мәктәпләргә русча «Восточный факультет», төрекчә «Әллисанәи шоркыя мәктә-бе»[28] диләр. Ул мәктәпләрдә укып, шул телләрдән берничәсен белгән адәмнәргә дә французча вә русчада «ориенталист», төрекчә «мөстәшрыйк» диләр. Мин дә Петербургта шундый мәктәптә гарәпчә, фарсыча, төрекчә, татарча өйрәнәмен. Мөселманнар күргән чакта, тел өйрәнергә файдасы булсын дип, һәрвакыт алар белән сөйләшәм. Аннан башка аларның гыйлемнәре, фикерләре ни дәрәҗәдә вә ысулы тәхсилләре[29] ничек булганын беләсем килә. Менә шуның өчен мин дә сезнең яныгызга килдем. «Каникул» дип тәгътыйль вакытына әйтәләр. Безнең мәктәпләрдә һәр ел ике-өч ай тәгътыйль ясап шәкертләргә истирахәт итәргә изен[30] бирәләр.

Һәр ел ике-өч ай буш торуга безнекеләрнең бик исләре китте, чөнки асыл яхшылап уку, биш елга тулмаса да, уку өчен һич туктамыйча унбиш-йигерме ел гомер кичерү бездә белмим кемнән гадәт булып калгандыр.

Әлхасыйл, аңлашылды ки: бу адәм лисане шәркыя мәктәбендә укый торган бер студент икән. Лисане шәркыя мәктәбендә барысы өч-дүрт ел укыйлар. Бу адәм тагын укып бетермәгән, безнең яшел чапан белән ак җиләннең берсе мөдәррис, берсе пишкадәм унбишәр-йигермешәр ел мәдрәсәдә, ягъни мөселман университетында (дарелфөнүн) ятып бөтен гомерләрене гыйльме тәхсил итәбез дип үткәргәннәр...

Бер мәртәбә студентның йөзенә, бер мәртәбә ак җиләнлеләрпең йөзенә карадым. Студентның вөҗүде симез, яңаклары кып-кызыл, күзе нурлы җирләре дә ут кебек янып торалар. Үзе кәефле, табигате тәрбияле вә ахлаклы, мәҗлесе сөхбәте[31] татлы, ничаклы сөйләшеп утырсаң да, ачуланышмак ихтималы юк. Мосахәбәсе[32] эчне поштыра торган түгел. Ни сөйләсә дә гыйбрәт алачак бер сүз сөйли.

Безнекеләрнең вөҗүдләреябык, өсләрендә ит, май беткән, коры сөякләре калган, кичә-көндез йокламыйча шәрехләр, Хашияләр[33], «кауле һу», «вәлә һу»ләр[34] карый-карый күзләрендә нур калмаган, чырайлары саргайган, кычкырып моназара кылыша-кылыша күкрәкләре бозылган, кырык-кырык йөткерәләр. Әхлактан вә әдәп, мосахәбәдән һич тә хәбәрләре юк. Алла тарафыннан яратылган табигый әхлаклары да бозылып беткән. Үзләре кебек бер кеше яннарына утырып сөйләшә башласа, ике сүзнең өченчесендә, син белмисең, мин беләм, дип низагь итәргә хәзер торалар. Мәҗлесләре эчне поштыра. Биш сәгать сөйләшеп утырсаң дөнья вә ахирәт өчен файдалы биш сүз ишетә алмазсың. Хәлебезгә мең кат тәэссеф!!!

Хәзрәт кияве студентка: — Тәзъейгы вакыт[35] итеп ул чаклы телләр өйрәнү ник кирәк? Кеше үз телен белсә җитмимени? — диде. Студент җавабында диде ки: — Безнең фикеребезчә, инсанның инсанлыгы нотык вә мөкяләмә саясендәдер[36]. Әгәр инсан үзенең максудын лисане белән аңлата белмәсә, ат, сыер кебек хайваннардан фәркы[37] калмас иде. Ул хәлдә бер кеше бер тел белсә, бер инсан саналыр, өч тел белсә өч инсан саналыр. Чөнки өч кешенең күрәчәге эшне ялгыз башына күрер, һәрбер милләтнең үзенә күрә бер мәдәнияте, гыйлеме,

мәгърифәте бар, әгәр төрле телләр белгән кешеләр булмаса, аларны безнең рус милләтенә кем тәрҗемә итеп бирер? Алар ничек хәбәрдар булырлар?

Хальбуки, дөньяда ничаклы мөгътәбәр милләт барисә, барысының теленнән дә кирәк китаплар русчага тәрҗемә ителгән вә һәр көн ителәдер. Мөселманчадан һәм күп тәрҗемә ителде. Мәсәлән, җөмләдән берсе сезгә бик мәгълүм булган «Һидая» китабыдыр. Моны русчага тәрҗемә иттеләр. Пәйгам-бәр: — «Әлгыйльме маләл мөэминен әхезиһа иннә вә җиддиһа этълибел-гыйлем вәләү биссыйпи[38]» дигән.

Бу көндә бу хәдисләр белән без сездән артыграк гамәл итәбез. Аннан башка, инсан дөньяда яшәгән мөддәттә мәгыйгаәтне хәзерләмәк өчен үзенә бер юл тотарга бурыч-лыдыр. Безнең бу мәктәптән укып чыккан кешеләрне кайсы телне укыган булса, шул тел белән сөйләшә торган якка хөкүмәт консул вә илчелек кебек мәэмүриятлоргә вә мәхкәмәләргә хакимлеккә, тәрҗеманлыкка тәгыен итеп бик күп мәгашләр бирәдер.

Мәсәлән, сез шул мәктәптән укып чыккан булса идегез, Истанбулдагы Россия сәфиренә катиб, яисә Ираида тәбриз, Һиндстанда Бумбай, Калькутта шәһәрләренә консул тәгыен ителеп, айда ике-өч йөз рубля мәгаш ала торган бер кеше булсагыз начармы булыр иде? Юкса шәригатегезме мондый эшләрдән тыядыр? Мин тыкмый дип беләмен».

Пишкадәм бу сүзләрне ишеткәч байтак дәртләнеп китте, студенттан тагы башка нәрсәләр дә сөйләтәсе килә башлады. Вә студентка карап: — Безнең бит андый мәктәпләрнең барлыгын да ишеткәнебез юк иде. Студент пишкадәмгә: — Бик яхшы, мондый мәктәпләрнең барлыгын ишеткәнегез юк икән, тыйб[39] гыйлеме укыла торган тыйббия мәктәпләренең барлыгын да ишеткәнегез юкмы? Тыйб мәктәбе татарларның иң күп җире булган Казанда да бар. Ул мәктәпләрдә сезнең татарлардан укучы я һич тә юк, яисә, булса да, юк дип әйтерлек аз. Хальбуки, пәйгамбәр: «Әлгыйльме гыйлман, эл әүвәле гыйльмел-әбдан сөммә гыйльмел-әдъян» дип, тыйб гыйлемен гыйбадәт гыйле-меннән әүвәл сөйләгән, — диде. Моңар каршы студентка пиш-кадәм болай дип җавап бирде: — Безнең бит андый гыйлем-нәрне укып маташырга вакытыбыз юк, шәригатебезне укырга вакыт бик күп кирәк.

Студент шәкерткә диде: — Әгәр сез шәригатегезне бер ысул вә тәртип белән укыса идегез, ул кадәр озын вакыт сарыф итмәк лазем булмас иде. Мин моннан әүвәл дә имтиханга-бара торган шулай сезнең кебек бер татар шәкерте белән пароходта туры килеп, сезнең мәдрәсәләрегезнең хәлләрен сорашкан идем.

Аңладыгыма күрә, сезнең мәдрәсә укулары бик-бик тәртипсез, низамсыз вә моннан мең ел әүвәлге, ысул белән булса кирәк. Заман алышындыкча һәр нәрсәнең низам вә тәртибе дә алышынадыр. Мәдрәсәләрегездә сез әүвәлән үз телегезнең сарыф, нәхүене укымыйча, белмичә, туп-туры гарәпчә сарыф, нәхү укырга башлыйсыз икән. Дөньяда моның кебек зур хата юктыр. Үз теленең сарыф, нәхүе кавагыйдене белмәгән кешегә башка ят бер телнең сарыф, нәхүене өйрәтү таштан су чыгарырга тырышу кебек бер нәүгы ахмаклыктыр. Үз теленең кавагыйдене белгән кеше гарәпчә, русча, французча кебек ят телләрне бер елда өйрәнсә, белмәгән кеше өчен һич юктан биш ел кирәктер.

Теләсәгез минем сүземне тәҗрибә итеп карагыз. Сез әүвәл бик яхшы итеп үзегезнең сарыф, нәхү кавагыйдене укыгыз, аннан соң мөнтәзам ысул вә тәртибе җәдид белән ике-өч елда гарәпчәнең сарыфыны, нәхүене тәтбикаты[40] илә укып, гарәп лисаныны әдәбияты илә тәмамән өйрәнсәгез, гарәпчәдән теләгән китабыңызны ачып мөталага итәр вә аңлар идеңез.

Сез мәдрәсәдә ике-өч ел укып чыгарга кергән бер мужик баласына да Габделгафур, Госам, Хыяли, Рамазан кебек хашияләр укытып сөякләре череп беткән демократистларның-фәләннәрнең җәүһәре фәрдене[41] мисалга китергән дәлилләрене өйрәтергә башлыйсыз икән. Хальбуки андаен адәмнәр, өч-дүрт елдан соң мәдрәсәдән чыгып атасы урынына мужик булгач, «ля нөсәллиме лимә ля яҗүз»[42] ләрнең барысын да онытып бетереп, татарча хат язарга да белми торган булып кала икән.

Чөнки татарча укырга, язарга өйрәнүдән әүвәл фарсыча: «ләфзан гамәле кәрд, мәгънән гамәле нәкәрд»[43] дип укытырга башлатканнар.

Сезнең мәдрәсәләрдә һич тә асылсыз, әсассыз дөнья вә ахирәткә файдасы вә шәригатькә лөзүме булмаган бәхәсләр белән вакыт кичереп тә, иске мөселманнарның хәлләрене укыган вә чыгарган гыйлемнәрене, һөнәрләрене бер дә белмиләр икән. Әүвәл дә миңа очраган шәкерт то шулай сезнең кебек бер хәлфә иде. Мин аннан әүвәлге мөселманнарның, гарәпләрнең тәрәкъкыяты Мәдәниясеннән вә мөселманнар тарафыннан чыгарылган гыйльме җәбер, гыйльме кимия, гыйльме җәгърафия кебек вә аларның һәрбер мәдрәсәләрендә укылган гыйльме хәйванат, гыйльме нәбатат, гыйльме һәндәсә, гыйльме табәка-теларз[44], гыйльме музыка, гыйльме тарих кебек фәннәрдән сораштым. Ләкин мәгаттәәссеф[45] һичбереннән җавап ала алмадым.

Ул миңа без мәдрәсәләребездә мантыйк хикмәтне бик яхшы укыймыз, дигән иде. Мөселман философларыннан бөтен галәмдә мәшһүр ибне Рөшаднең, Фәхреразиның, ибне Синаның фәлсәфәләре хакында сүз ачтым. Алардан да хәбәре юк иде. Бу соң заманнарның Жан-Жак Руссо, Виктор Гюго, Вольтер, Шупингаур, Дарвин, Кант, Толстой кебек философларыңнан сорарга да хаҗәт күрмәдем.

Дикъкать итәсезме? Бу сүзләрне бер рус студенты сөйлидер иде. Студент боларны сөйләгән вакытта безнең яшел чапан белән ак җиләннең авызлары берәр карыш ачылып, утырган җирләрендә катып калдылар. Башында шапка, ләкин безнең Коръагшы да, шәригатьне дә, хәдисләрне дә белә вә пишкадәмнең йигерме ел укып, исемнәрен дә ишетмәгән фәннәрне дә белә, гарәпчә, фарсыча да белә, французча, алманча кебек Аурупа телләреннән до һич булмаса, бер-ике төрлесене белүендә һич шик-шөбһә юк. Ни өчен белмәсеннәр, әлбәттә, белерләр иде. Ләкин ысулы тәхсил[46] хәзерге заманга муафыйк, низам вә тәртип белән булырга кирәк.

Бабаларыбыз арба белон яисә җәяү йөргәннәр, безгә дә шулай булырга кирәк дип, Казаннан Мәскәүгә яисә Нижныйга берәү дә ат җигеп арба белән барган кеше юк. Әмма мәдрәсәләрне ислях итүдән вә монтазам[47] яңа мәктәпләр ачып, тиз бер заманда мөселманча вә русча укуның кирәк улдыгыннан сүз ачылса, бабаларыбыз заманында ничек булган исә безгә дә шулай торырга кирәк. Башка төрлесе бидгатьтер[48] дип, кара халыкны аздыра торган кешеләребез бик күп. Кара халыкта кабахәт юк. Чөнки алар җаһил. Аз гына укыган кеше аларга шәригать дип

ни сөйләсә дә ышаналар. Үзләре асыл шәригатьнең ничек икәнен белмиләр. Ишан хәзрәтнең сүзене хашан Коръан сүзе кебек тотарга тырышалар. Хальбуки ишаннар арасында ниндиләре юктыр.

Мәсәлән, Казан тирәсендә суфилык, тәкъвалык вә гыйлем илә мәшһүр бер ишан менә бодай дип нәсихәт итә икән: «Балаларыгызны ул җәдиде ысул[50] белән укытмагыз, миннән аслан рөхсәт юк. Кем укыттырса, бәддога итәрем, чөнки ул ысулы җәдидчеләр һәрнәрсәне татарчага тәрҗемә итеп үз телебездә укытмакчы булалар икән. Алар китә-китә Коръанны да тәрҗемә итәрләр! Соңра Коръанны һәр кеше үзе алып укып аңларга башласа, бер кешенең дә дингә мәхәббәте калмас».

Менә күрдегезме? Янына меңнәрчә мөрид җыеп, аларга туры юл күрсәтү идигасында булган ишан хәзрәтнең нәсихәтене; бераз яхшысынча исәпләп карасак, болар ни дигән сүз буладыр: «хәзергә кадәр Коръан вә шәригатемез гарәпчә иде, җаһил халык аларны укып аңлый алмаганнары өчен генә ышанып мөселман булып торалар иде. Әгәр алар татарчага тәрҗемә улынып та һәр кеше Коръанны вә шәригатьне үзе укып аңлый башласа, һичбер кеше мөселманлыкны тотмас, чөнки Коръанда вә шәригатьтә адәм ышанырлык нәрсә юктыр, җаһил халык тик алданып кына торалар» дигән сүз буладыр... Асыл бәхәскә киләлем: студент пишкадәмгә диде: «Менә зур шәһәрләрдә сәнәгать вә һөнәр мәктәпләре, зирагать, тиҗарәт вә багчуанлык мәктәпләре, гимназияләр бар. Бу мәктәпләрдә ниндәен гыйлем-нәр укылганыны вә укылган гыйлемнәрдән ни файдалар күрелгәнене вә ни өчен ул фәннәрне укыдыкларыны сезнен сорашып караганыгыз бармы?» Пишкадәм бәйлә җавап бирде: «Сорашканым жук жугын да, аларда шул инде дөнья гыйлемнәре укыла торгандыр».

Студент: — Сез хозер кайда торасыз? Дөньядамы, ахирәттәме?

Пишкадәм: — Әлбәттә, дөньяда торабыз. Студент: — Башка милләтләр дөньяда торганлыклары өчен ул гыйлемнәргә мохтаҗ булгач, сез ничек мохтаҗ булмыйсыз? Сез дә бит алар кебек кеше. Сезгә дә ашарга, эчәргә, кияргә, торырга кирәк. Хәзерге дөнья гыйлем дөньясыдыр. Гыйлемсез кеше канатсыз кош кебектер.

Хәзерге заманда хәмияте, миллияте вә әдәбиятны мөха-фәзә[51] өчен гыйлем вә һөнәр вә аларның Сәмәрәләре[52] улан сәрвәт вә икътидар лаземдыр. Әнә шул югарыда сөйләдекем мәктәпләрдә укып чыккан кешеләрнең ясаган пароходларына, тимер юлларына утырып йөреп акча бирәсез. Аның җиренә үзегез шундаен нәрсәләр ясап күп-күп акчалар җыеп, бай булсагыз, фөкарага ярдәм итсәгез, хаҗга барсагыз, мәсҗедләр, мәктәпләр салдырсагыз, ятимханәләр, дарелгаҗизиннар[53] бина иттерсәгез, тагын яхшы булмасмы иде?

Хәзер бит сезнең кулыгызда, фитра бирегез, гошер бирегез, зәкят бирегез дип, нәсихәт итүдән башка бер һөнәр юк. Алар гыйлемсез, һөнәрсез, барысы да ярлы булса зәкятны ничек бирсен? Гошерне кайдан алып бирсен? Ул үз тамагын туйдыра алмас, ул алар арасына һөнәр вә мәгърифәт кертергә, аларны тиҗарәт, сәнәгать, зирагатькә тәшвыйк итәргә кирәк, һөнәрле, мәгърифәтле булсыннар, баесыннар, аннан соң зәкят, фитра бирергә нәсихәт итәргә кирәк. Пишкадәм: — Алай итсәк яхшы булыр иде, ләкин без мулла булыр өчен шәригать укыйбыз. Андаен нәрсәләр белән маташырга вакытымыз үтте, диде.

Студент: — Мин боларны, сиңа үзең укымак өчен сөйлә-мимен. Син мулла булырсың, зур бер мөдәррис булырсың. Болар мәгълүм. Бәлки дә зур бер ишан булып тирә-ягыңа меңнәрчә мөрид җыярсың. Әгәр милләтегезгә аз гына шәфкать вә мәрхәмәтең бар исә, шул вакытларда аларны тугъры юлга күндер. Тугъры нәсихәт итеп, шәригатьтән дә үтеп тәкъвалык күрсәтергә тырышкан булып мөселманнарның сәфил[54] вә пришанлыгына сәбәп булма, дип сөйлимен.

Үзегезгә мәгълүм, падишаһымыз гадәләтле, низамымыз хәкъканиятледер. Үзегезгә мәктәпләр ачарга, китаплар язарга, газеталар бастырырга, җәмгыяте хәйрияләр ачарга, ятимханә-ләр салдырырга теләгәнчә рөхсәт биреләдер. Ләкин сез боларның файдаларыны аңлый белергә кирәк.

Сүзләр бу йиргә килгәндә, пароходымыз Мурзиха станция-сенә йиткән иде. Башына бик иске генә ак бүрек, өстенә биш-билле бишмәт кигән ак сакаллы карт кына бер адәм пароход конторының янында су буенда ком өстендә таһарәт алып торадыр иде. Кульъяулыгы белән бик тиз генә битене сөртте дә йөгерә-йөгерә конторга керде. Ләкин пароходка нәрсәләрене кертмәде. Безнең пароходтагы кешеләрдән: «Якимский» паро-ходы тиз киләме? Юлда күренмәдеме?» — дип сорады. Тугърысыны белмәсәм дә, үзлегемнән генә: бу адәм берәр авылның у мулласы булса кирәк, 97нче елгы перепись вакы-тында, динемезгә зарары булыр дип, исемнәрене яздырмаска халыкны котырткanлыгы өчен указы алынгандыр, вә моның өчен дә Уфага Духовный собраниегә бара торгандыр, дип хисап иттем.

Чөнки шул вакытта боның кебек эшләр бик күп булды. Переписьнең ни икәненнән хәбәрләре улмадыгы өчен, ай-һай, шулай микән, болай микән, дингә зарары булмас микән, шәригатькә ярар микән, яздырмый торсагыз ничек булыр икән? дип халыкны куркыткannары өчен байтак муллаларның указлары алынды. Алар да указ артыннан «инде нишләргә кирәк?» дип корыда калган балыклар кебек аптырашып йөрделәр.

Пароход Мурзихадан кузгалып китте. Мин дә үз урыныма төштем, бер чәй хәзерләтеп ишан хәзрәтне кияве, пишкадәме берлә чәй эчәргә чакырмакчы булдым. Чәй хәзерләтмәстән әүвәл хәзрәткә барып хәбәр бирим, рәхим итәргә вакытлары булырмы, дип хәзрәтнең янына киттем.

Бай мөрид белән икесе утырып тора иде.— Чәй хәзер-ләтсәм, бераздан чәй эчәргә рәхим итәрсез микән? — дип, мин хәзрәткә әйткәч, бай мөрид миңа карап әйтте: — Мин үзем жаркой пешерергә әйткән идем. Бераздан безнең ашау вакытыбыз буладыр — алай булса мин чәйне сезнең ашап бетерүгә хәзерләттерим, — дип китәргә торганда, хезмәтче ике тарелка, ике пычак, ике чәнечке китереп боларның өстәл өстенә куеп китте.

Ул киткәч тә бай мөрид русның китергән нәрсәләренә карап: — Бу чәнечке белән бу пычаклар нигә кирәк? Ходай биргән куллар белән ашау ник ярамаган? Бар да ахыр заман галәмәтләре! Дөньяга кирәкмәс нәрсәләр туладыр,— диде. Бераз дикъкать иттем, бай мөрид: ж, п, ч хәрефләрең аслан тәләффез итмидер[55]. Жаркой җиренә заркой дигән иде, хәзер дә чәнечке җиренә җонеҗке вә пычак җиренә быҗак дип әйтәдер. Бу адәм мотлакан казанлы мәшһүр дамелла Гарифулла хәзрәтнең «Китабел-мәгъҗәм»ен укыган булса кирәк заи иттем.

Арасы бераз үтте. Мин чәй хәзерләттем. Әүвәл хәзрәт кияве белән пишкадәмне чакырмак өчен пароходның өстенә мендем. Болар икесе генә сөйләшеп утыралар иде. Яннарыннан студент киткән.

— Студент белән Сөхбәтегез ахырында ничек булып калды? — дип сорадым. Пишкадәм: — Ничек булсын, андый кешеләрне аптырату безнең өчен бер нәрсә дә түгел бит, мин нәхүдән, мәхдүм абзый да Фикъһедән берәр сүз сораган идек, һичбер җавап бирә алмады. Тукталды калды, — диде. — Ниндәен сүзләр сорадыгыз? — дидем.

Пишкадәм: — Мин Лятәхшәнинең игьлалын, вә мәхдүм абзый да бер коега тычкан төшсә, ничә чиләк су түгәргә кирәк булганын сораган идек, минем эшем бар, җитәр инде, дип торып китте,— диде. Мин дә: — Бигрәк мөһим вә кирәкле сүзләр сорагансыз икән, баракәлла, машаалла, түбән безем янга чәй эчәргә рәхим итегез, — дидем.

Берлектә түбән төштек. Хәзрәт белән бай мөридкә дә хәбәр бирдек. Килделәр, утырдылар, һава бик яхшы булганга күрә, халыкның күбесе пароходның өстендә булганлыктан, безнең яныбызда тыгызлык түгел иде. Хәзрәт килеп утыргач та, кул күтәреп бер дога кылды. Бу дога ни өчен булганын, хәзрәтнең алладан ни сораганын белмәсәк тә, барыбыз да амин дидек. Чөнки хәзрәт яхшы кеше, әлбәттә, догасы да яхшылык өчең булыр. Хәзрәт башын күкрәгенә туры иеп, алдына карап утырды. Башкалары да моңар имтисал[56] иттеләр.

Мин өмит иткән идем ки: татлы бер мәсахәбә мәҗлесе булсын, хәзрәт безгә дөньябыз, ахирәтебез өчен шәригатьтән вә мәгыйшәттән носихәтләр, вәгазьләр бирер вә хикмәтле сүзләр сөйләр дип, ләкин мәгаттәәссеф, алай булмады. Бер-беренә ачуланышкан кешеләр кебек, һәрберсе үзенең алдына караган, башкасының йөзенә күз дә салмыйлар. Гәрчә әдәп вә тәрбия шулай икътиза[57] итәдер, олуг кешеләр янында күп сөйләргә тиеш түгел дисәләр дә, бу кадәр дә Ифратка китү тиеш микән соң? Олуг кешеләр дөнья вә ахирәт өчен кирәк нәрсәләр сөйләсәләр, кечек кешеләр дә белмәгәннәрен алардан сорап файдалансалар, миңа күрә тагы яхшы булыр иде. Мин дә башымны алар кебек иеп утырган идем. Муйным бик авырта башлагач, башымны күтәреп, алдыма гына карап тордым. Бу сурәтлә чәй әҗлесе тәмам булды. Хәзрәт тагын бер дога кылды.

Торып китә башладылар. Хәзрәт аз гына киткәч, бай мөрид арткарак калды да күкрәк кесәсеннән кечек бер китап чыгарып миңа туры сузды вә диде ки: — Синең өстең-башың бик шәригатьчә булмаса да, үзең яхшы кеше булырга охшыйсың. Чөнки бу тобәррек[58] хәзрәтләр тирәсендә әйләнәсең. Син дә безнең мозһәбтән булырга кирәк, менә синә бездән бер подарка булсын!

Китапны кулыма алып карадым: ни күрим? Гарифулла хәзрәтнең Китабел-мөгаҗҗәме, тәмам чиләгенә күрә капкачы, китабына күрә укучысы, — дидем. Бу китап нидән бәхәс итәдер, моны кайдан алдың? — дип бай мөридтән сорадым.

— Бу китапның исеме Китабел-мөгаҗҗәмдср; моны Казанның Гарифулла атлы бер хәзрәт язган. Казанның суфи вә тәкъва байлары үз акчалары белән бастырып биргәннәр. Инде хәзер бушлай тараталар, — диде. — Бу китапта ни сөйли икән соң? — дидем.— Инде үзең укып карарсың, алай булса да аңлатыйм: әнә шул берничә җирләрдә ысулы җәзизмедер, нидер, шайтан укытуы белән

укыта башладылар. Бу тауларны тыяр өчен язылган китап икән, — диде. — Үзегез укып чыкты-гызмы соң? — дидем. — Җук, жук, мин үзем укырга, язарга бел-мим, менә Казанда читекче Н. абзыйның приказчигының укы-ганын безнең номерчы М. абзыйның малае тыңлап торган. Ул кайтып безгә сөйләде дә, мин үзем бу китапны эзләп алдым, — диде.

Һәдия[59] булдыгы өчен бу китапны кабул итеп алам, ләкин син дә безнең мәзһәбтән булырга кирәк, дип әйттең. Бу сүзеңне кабул итә алмыйм. Әгәр син Гарифулла хәзрәт мәзһәбеннән исәң, мин аның мәзһәбеннән түгелмен. Мин хәзрәте Рәсулулла мәзһәбеннәнмен. Коръан вә хәдисне ташлап Китабел-мөгаҗ-җәмнәр-фәләннәр белән гамәл итәргә зәррә кадәр дә ниятем юктыр. Бу китапны синнән алгач та бер җеп белән бәйләп, китапларның астына салып бастырып куячакмын. Бездән илле ел, йөз ел соңра булган кешеләргә бер ядкяр булсын. Алар бу китапны укып, үзләренең бабалары эчендә никадәр фикерсез, мөтәгассыйб, фанатик адәмнәр булганын күрерләр. Инсаннарны тәрәкъкый иттермәк никадәр мөшкил вә авыр булдыгың истихраҗ итәрләр[60]. Бәлки, комедия ясап театрларда уйнарлар. Андаен кешеләр башка милләтләрдә дә булган. Мәсәлән, рус мөхәррирләреннән Фонвизинның яздыгы «Недоросль» исемен-дәге кечек бер театр китабы Китабел-мөгаҗҗәм мәзһәбендә булган кешеләрнең хәлләрен бик яхшы бәян итәдер, — дидем.

Шулай бераз сөйләшкәч, исәнләшеп бер-беребездән аерылдык. Ул хәзрәт артыннан үз урынына туры китте. Мин дә пароходның өстенә менеп утырдым. Үз-үземә шулай тирән бер фикергә төштем: башка милләтләр мәктәпләр ачканнар, файдалы вә кирәкле китаплар язганнар, укыганнар, белгәннәр, вә бу көнге көндә бай, ярлы, яшь, карт — барысы да гыйлем, мәгърифәт, һөнәр вә сәнгатькә дүрт кул белән ябышып ничек итеп тагын күбрәк, яхшырак белүнең чарасын эзлиләр. Гыйлем вә мәгърифәт, һөнәр вә сәнгать өчен иң зиядә әмер иткән шәригать: шәригате Исламиядер. Шулай була торып та безнең голяма исемен алган кешеләребез бәгъзысы: мөселманнар өчен уку кирәкме? Кирәкмәзме? Белү ярармы, ярамазмы? — дип, бер такым сафсата китаплар язып жаһил халыкның фикерен бозып, зиһеннәрен шашыртып торалар, һәркем өчен бик мәгълүм мәсьәләдер ки: шәригатебез укырга, белергә әмер итәдер. Әмма ысулы җәдидә беләнме? Ысулы кадимә беләнме? Анысын бәян итмидер. Әгәр җәнабе хакның максуды ысулы кадимә белән укыту булса, мотлак[61] Коръанда аның өчен дә бер-ике аяте кәримә зикер улынган булыр иде. Бу хосус өчен аятьтә вә хәдистә һичбер бәян юк. Моннан аңлашыла ки: ниндәен ысул белән вакыт, гомер, мал исраф итмәенчә, тиз заманда күп өйрәнү мөмкин булса, ул ысул илән укырга, өйрәнергә ярыйдыр. Нитәккем, бай кешегә хаҗ кылмак фарыз, әмма Мәккәй Мөкәррәмәгә арба беләнме, дәвә беләнме, тимер юл беләнме, пароход беләнме баруны шәригать бәян итмәгән вә ул җәһәтнең шәригатькә аслан тәгаллекы[62] да юк. Бинаән таләйһи: кайсы берлә баруда очсызлык, иминчелек, тизлек, җиңеллек булса, аның белән барырга ярыйдыр. Вә ишан хәзрәтләр дә кяфер ясаган пароход диптормыйлар, эченә утырып китәләр, укымага, язмага өйрәнүнең дә моннан асла фәркы юктыр, язу өйрәнгәндә, теләсәң кара такта өстенә ак бур белән, теләсәң ак таш өстенә күмер белән язып өйрән. Боларның шәригатькә тәгаллыкы (бәйләнеше) ни җәһәттәндер, гаҗоба? Әлбәттә, моның

кебек нәрсәләрнең; шәригатькә тәгаллыкы юктыр. Ул хәлдә голәмабыз ни өчен әсаслы нәрсәләрне хәтергә дә китермичә, мондаен буш нәрсәләр белән халыкның фикерен бозалар? Моның кебек бик күп нәрсәләр хәтеремә килде. Хәлебезгә чук тәоссеф иттем. Ләкин пароходның кычкырткан тавышына башымны күтәреп карадым. Рыбная Слобода станциясенә җиткәнбез икән. Бу станциядә дә пароход күп тормады, кузгалып китте. Өченче класска төшеп хәзрәт кияве белән пишкадәм янында бераз сөйләшеп утырдым. Пишкадәм безнең белән сөйләшсә дә, күңеле бер дә бездә түгел иде. Кулындагы Сөлләм казыеның кәгазьләрен актарып, аннан-моннан караштырып утырадыр иде.

Үзлегемнән генә: туй бик зур булырга кирәк, ахрысы, тирә-яктан башка мөдәррисләр вә пишкадәмнәр дә җыела торгандыр. Бу хәлфә дә алардан сорарга сүз хәзерли торгандыр, дип хисап иттем. Тагы өскә чыгып тирә-якны бераз сәер итеп бардым. Арасы күп тә үтмәде, Акъяр дигән бер борынны үттек, Чистай янындагы керасин фабрикларыиың трубалары күренмәгә башлады. Тагы бераздан Чистайның үзенә дә килеп җиттек. Чистай шәһәре төп-төз Бер җирдә, Кама нәһере[63] буенда бина иделмеш, гаять гүзәл бер өязни городтыр. Бина лары, урамнары яхшыча мөнтәзам[64]. Ашлык тиҗарәте бик рәваҗлыдыр[65]. Христианнарның берничә кәлисәлоре, начальной вә городской училищалары: ирләр вә хатыннарга махсус гимназия вә про гимназия мәктәпләре бардыр. Мөселманнарның да бөек вә гүзәл ике җамигъ Шәрифләре бардыр. Гомуми диния тәхсиленә махсус мәдрәсәи исламиясе һәр җирдә мәшһүр вә мөдәррис мәрхүм Мөхәммәдзакнр хәзрәтнең гайрәт вә һиммәте фазый-ланә[66]ләре саясендә бу мәдрәсәдә бер чук таләбә җитеш-мештер.

Татар мәгърифәтчелек әдәбияты. Казан, 1979 ел.

## Аңлатмалар

[1] Аз гына кыскартып алынды. Алар күп нокталар белән күрсәтеләләр. 24 б.
[2] Тәгъзыйм — олылау, хөрмәтләү.
[3] Сахибелкомганнар — комган ияләре.
[4] Абдэстханә — бәдрәф.
[5] Пишкадәм — алдынгы укучы.
[6] Хашияи дәһерене — заманны аңлаткан урынын.
[7] Хөдусе галәм — дөньяның барлыкка килүе.
[8] Шитдәтле тәәссеф — каты ачыну.
[9] Мәхез — махсус.
[10] Истикамәт — тугрылык.
[11] Ләхза — бик аз вакыт.
[12] Мәләкә — тәжрибә.
[13] Истихфаф — кимсетеп карау.
[14] Сәтре гаурәт — тәнне каплау.
[15] Рәҗа — үтенү, өмет.
[16] Шәйэ мотлак иле «мотлакы шәй» арасындагы фәрыкның — әйбернең чикләнмәгән булуы белән чикләнмәгән әйбер арасындагы аерма.
[17] Салиб — яраксыз.

[18] Галәме мөракабәгә — уй дөньясына.
[19] Зиядә — артык.
[20] Мантыйктан — логикадан.
[21] Сабахекем билхәер, я шәех! — И шәйхем, иртогез хәерле булсын!
[22] Сәфәре кем бәгыйден? — сәфәрегез-юлыгыз ераккамы?
[23] Матәгърифуне лисанә нябиекем әлләзи өнзәлә биһи әлкоръан — пәйгамбәрегез сөйләгән коръан телен белмисез!
[24] Җәмгы сигасе — күплек формасы.
[25] Фәрыктан — аермадан.
[26] Тәбдиле һава — һава алыштыру.
[27] Кыйсемгә — бүлеккә.
[28] Әллисанәи шоркыя — көнчыгыш телләре.
[29] Ысулы тәхсилләре — укыту тәртипләре.
[30] Истирахәт итәргә изен — ял итәргә рөхсәт.
[31] Мәҗлесе сөхбәте — сөйләшеп утыруы.
[32] Мосахәбәсе — сөйләгән сүзләре.
[33] Шәрехләр, хашияләр — китап читләренә язылган аңлатмалар.
[34] Кауле һу, вялә һу — юк-бар сүзләр.
[35] Тәзъейгы вакыт — вакыт әрәм.
[36] Нотык вә мөкяләмә саясендәдер — сөйләү һәм сөйләшүендә күренәләр.
[37] Фәркы — аермасы.
[38] Әлгыйльме маләл мөэминен әхезиһа иннә вә җиддиһа әтълибел-гыйлем вәләү биссыйни — гыйлемне кытайда булса да тырышып эзләп табыгыз.
[39] Тыйб — медицина.
[40] Әлгыйльме гыйлман, эл әүвәле гыйльмел-әбдан сөммә гыйльмел-әдъян — медицина белемен дини белемнән алдарак белү кирәклеге.
[41] Тәтбикаты — күнегүләре.
[42] Фәрдене — шәхесне.
[43] Ля нөсәллиме лимә ля яжүз — алай түгел, ник алай булмасын.
[44] Ләфзан гамәле кәрд, мәгънән гамәле әкәрд — сүзләрнең әйтелешен генә өйрәтеп, мәгънәсен белдермәгәннәр.
[45] Табәкателарз — геология.
[46] Мәгаттәәссеф — үкенечкә каршы.
[47] Тәхсил — гыйлем алу.
[48] Монтазам — тәртипкә салынган.
[49] Бидгать — элеккесенә каршы килә торган яна бер эш.
[50] Җәдиде ысул — яңа тәртип, метод.
[51] Мөхафәзә — саклау, яклау.
[52] Сәмәрә — нәтиҗә.
[53] Тәләффез итмидер — авызымнан чыгармыйдыр.
[54] Имтисал — анык төсле.
[55] Икътиза — таләп.
[56] Тәбәррек — һәркем өчен хөрмәтле.
[57] Һәдия — бүләк.
[58] Истихраҗ итәрләр — белерләр.

[59] Мотлак — ничек кенә булмасын.
[60] Тәгаллекъ — бәйләнеш.
[61] Әсас — нигез, төп.
[62] Нәһер — елга.
[63] Мөнтәзам — төзек.
[64] Рәвац — таралу, базарда
[65] Фазыйланә — яхшылык.

## Библиография

1. *Абуль-Гази*. Родословное древо тюрков / Перевод Г. Саблукова.

2. *Алисов, Г.* Мусульманский вопрос в России // Русская мысль, 1909, № 7.

3. *Ахмаров, Г.Н.* О языке и народности мишарей. Казань, 1903.

4. Архив общественных организаций РБ (Уфа).

5. Архив исторический РБ (Уфа).

6. Архив и музей Башкирского аграрного университета.

7. Архив Балтачевского района.

8. *Асфандияров, А.А.* Кантонное управление в Башкирии (1788-1865 гг.). Уфа, 2005.

9. *Амиров, Р.К.* Летопись современности. Уфа, 1985.

10. *Азаматов, Д.Д.* Оренбургское магометанское духовное собрание в конце XVIII-XIX вв. Уфа, 1996.

11. Административно-территориальное устройство РБ. Уфа, 2001.

12. Административно-территориальное деление БАССР. Уфа, 1981.

13. *Акбулатов, И.М.* Праздники в исламе. Уфа, 1992.

14. Алфавит волостей и селений Уфимской губернии. Уфа, 1902.

15. *Акимова, М. С.* Антропология древнего населения Приуралья. М., 1965.

16. *Асфандияров, А.С.* Ведомости башкирских и мишарских кантонных начальников // Южно-Уральский археографический сборник. Уфа, 1976.

17. *Аблязев, К.А.* Историческая судьба татар. В 2-х томах. Саратов, 2012.

18. *Абдуллин, Я.Х.* Татарская просветительская мысль. Казань, 2005.

19. *Азнабаев, Б.А.* Уфимское дворянство в конце XVI — первой половине XVIII вв. Уфа, 1999.

20. *Алишев, С.Х.* Исторические судьбы народов Среднего Поволжья XVI — начала XIX вв. М., 1990.

21. Алфавитный список родам потомственных дворян, внесённых в дворянскую родословную книгу Казанской губернии с обозначением имени и отчества тех из них, кои впервые записали свои роды в сию книгу и с обозначением времени их записи с 1787 по 1895 г. Казань, 1997.

22. *Асфандияров, А.З.* История сёл и деревень Башкортостана. Уфа, 1992-1997.

23. *Әхмәтҗанов, М.* Татар шәҗәрәләре. Казан, 1995.

24. *Әхмәтҗанов, М.* Татар теленең кыскача тарихи-этимологик сүзлеге. Казан, 2001.

25. *Баязитова, Ф.С.* Татар-мишәр рухи мирасы. Гаилә — көнкүреш, йола терминологиясе һәм фольклор. Саранск, 2003.

26. Башкирские шэжере. Уфа, 1960.

27. *Безертинов, Р.Н.* Татары, тюрки — потрясатели вселенной (История великих империй), т.т. I-III. Набережные Челны, 1997.

28. Библиография по башкирской литературе и литературоведению. Уфа, 1969.

29. *Бессонов, А.Г.* О значении названий татарских и башкирских имён Приуралья. Труды Оренбургского отделения императорского географического общества. Оренбург, 1880.
30. *Баскаков, И.А.* Русские фамилии тюркского происхождения. М., 1979.
31. Балтачевский район: время и люди. Уфа, 2001.
32. Башкирский край: сб. ст. Вып. 1, 2, 3.
33. *Валеев, Римзиль.* Татары у себя дома. Казань, 2007.
34. *Вагапов, М.В.* Ислам и семья. М., 1980.
35. *Вильданов, А.Х., Кунафин, Г.С.* Башкирские просветители-демократы XIX века. Москва: Наука, 1980.
36. *Владимирцев, П.Я.* Чингис-хан. СПб., 1922.
37. *Вернадский, Г.В.* Монгольское иго в русской истории (статьи в Евразийском временнике. У., 1927).
38. Ведомость о числе духовных лиц и приходов по Уфимской губернии.
39. *Гумилёв, Л.Н.* Тысячелетие вокруг Каспия. М., 1993.
40. *Гурвич, К.А.* Ярмарки. К истории ярмарок вообще и к статистике ярмарки в Уфимской губернии. Уфа, 1884.
41. *Гаязов, А.* Казанчылар иле. Уфа, 2007.
42. *Габдрафиков, И.М.* Региональные особенности становления российской нации: Республика Башкортостан (1990-2003 гг.) СПб., 2014.
43. Государственный архив Самарской области — ф. 131 Татарские дела, ф. 452 Уфимская провинциальная канцелярия, ф. 1173 Уфимская прказная изба.
44. *Габдуллин, И.Р.* От служилых татар к татарскому дворянству. Москва, 2006. (Китап күп татар морзаларының нәсел шәҗәрәләрен һәм бай тарихи-библиографик чыганакларны эченә алган).
45. Гражданская война в Поволжье. (1918-1920), Казань, 1979.
46. *Давлет, Н.* Развитие национального самосознания у татар в XX веке (об этнониме «Татар») // Панорама-форум, 1996, № 2. Казань.
47. *Давлетшина, З.М.* Татарское население Башкортостана. Уфа, 2001.
48. *Ден, В.* Население России по ревизии. М, 1902. Т. 1.
49. *Егоров, А.Л.* Историческая география Золотой Орды. М., 1985.
50. *Закиев, М.З.* Татары: проблемы истории и языка. Казань, 1995.
51. *Закиров, С.* Дипломатические отношения Золотой Орды с Египтом. М., Наука, 1966.
52. Записи императорской академии наук.
53. *Ибн-Фадлан.* Путешествие Ибн-Фадлана на Волгу.
54. *Исхаки Гаяз.* Идел-Урал, Казань, 1991.
55. История башкирской литературы. План-проспект. Уфа, 1978.
56. История башкирской литературы в 6-ти томах. 1989-2005.
57. История башкирской советской литературы. М., Наука, 1977.
58. История башкирских родов. Серия книг.
59. История башкирской литературы. Т.Т. 1-5.
60. История татарской литературы. Т.Т. 1-5.
61. *Иордан, М.В., Кузеев, Р.Г., Червонная, С.М.* Ислам в Евразии.
62. Итоги Всероссийской переписи 1920 г. М., 1921.

63. *Имакаев, М.* 1812 елда булып үткән Ватан сугышының тарихы. Казан. 1912.

64. Историко-статистические и экономические таблицы Автономной Башкирской ССР. Уфа, 1923.

65. Итоги всесоюзной переписи населения 1970 г. т.т. 1-7. М., 1972-1974 г.г.

66. *Исмагилов, Р.С.* Нуримановский район. Уфа, 1994.

67. Итоги Всероссийской переписи. Национальный состав. Уфа, 2013.

68. *Исхаков, Д., Мустафин, М., Биктимиров, Н.* Татары к 2025 году: демографический прогноз. Казань, 2007.

69. *Исхаков, Д.* Татарлар: халык исәбен алу һәм сәяхәт. Казан, 2010.

70. *Каримуллин, Ә.* Татар китабы. 1988.

71. *Киекбаев, Д.И.* Введение в урало-алтайское языкознание. Уфа, 1972.

72. Книга памяти жертв политических репрессий по РБ. Т.Т. 1-6. Уфа, 2005.

73. Крестьянские движения в России в 1796-1825 г.г. сб. док. М., 1961.

74. *Корбангулов, Рәис.* Буыннарга ядкарь. Благовар районы, 2002.

75. “Кызыл таң” республика гәзите – 1932 елдан башлап.

76. *Кобузан, В.М.* Народонаселение России в XVIII — в первую половину XIX вв. М., 1963.

77. Литературное наследие народов Урало-Поволжья и современность. Уфа, 1980.

78. *Лощенков, А.В.* Россия и Евразия. М., 2013.

79. Материалы по истории татарского народа. Казань, 1995.

80. Материалы по истории Башкирской АССР. Т.Т. 1-5.

81. Материалы подворной переписи 1917 г. Уфа.

82. Материалы по истории народов СССР. В 6-ти книгах. М., 1936.

83. Материалы научной конференции, посвящённой 400-летию добровольного вхождения Башкирии в Россию. Уфа, 1989.

84. *Мусаев, К.М.* Лексикология тюркских языков. М., 1984.

85. *Мухамедьяров, Ш.Ф.* Социально-экономический и государственный строй казанского ханства (XV — первая половина XVI вв.). Казань, 2012.

86. Национальный состав населения СССР. М., 1989.

87. Национальные окраины Российской империи: становление и развитие системы управления. М.: Славянский диалог, 1998.

88. *Нуртдинов, Р.Ф.* Язык приталыпских татар. Казань, 1998.

89. *Орлов, А.М.* Мещера, мещеряки, мишаре. Казань, 1992.

90. Оҗмах сезгә, дөнья безгә. Татар язучыларының дингә каршы әсәрләре. Казан, 1070.

91. Отдел рукописей Российской государственной библиотеки (Москва).

92. Оренбургское магометанское духовное собрание.

93. *Өммәти Зыя.* Башкорт типтәрләренең җыр вә бәетләре. Уфа, 1903.

94. Проблемы древних угров на Южном Урале. Уфа, 1988.

95. *Похлёбкин, В.В.* Татары и Русь. 360 лет отношений. 1238-1588. М., 2000.

96. Послевоенная перепись населения: сб. ст. 1957.

97. *Рашид ад-дин.* Сборник летописей. История монголов. История Чингисхана. Ч. 3. СПб., 1868.

98. *Рахматуллин, У.Х.* Население Башкирии в XV-XVIII вв. Вопросы формирования небашкирского населения. М., 1989.

99. *Рамазанова Дәрҗия*. Сайланма әсәрләр. Казан, 1991.

100. *Равил Амирхан, Вахит Имамов*. Отечественная война татар. Набережные Челны. 1993.

101. Религиозные объединения Республики Башкортостан. Уфа, 2014.

102. *Рычков, П.И.* Топография Оренбургской губернии. Уфа, 1999.

103. *Рыбаков, С.Г.* Музыка и песни уральских мусульман с очерками их быта.

104. *Саматова, У.Х.* Империя власти и татарская школа во второй половине XIX — в начале XX века. Казань, 2013.

105. *Сафин, М.Х., Мансуров, И.С.* Абсалям: страницы истории. Стерлитамак — Уфа, 2008.

106. *Сахратуллин, С.* Бирская старина. Бирск: Кн. 1, 1993; Кн. 2, 2000.

107. Список населённых мест Башреспублики. Уфа, 1926.

108. Список населённых мест Уфимской губернии, Уфа, 1906.

109. Словарь топонимов Башкирской АССР. Уфа, 1980.

110. *Сатаров, Г.Ф.* Татарстан АССРның антропотопони-микасы. К., 1993.

111. Средневековые тюрко-татарские государства. Вып. 3. Институт истории им. Ш. Маржани. Казань, 2011.

112. Серия историко-филологическая. СПб., 1897, т. 2. № 2.

113. Социально-политические и этнодемографические процессы на Южном Урале XVIII-XX вв. Уфа, 1992.

114. Социально-экономическое развитие и народные движения на Южном Урале и в Среднем Поволжье (дорев. период). Уфа, 1967.

115. Статистика землевладение. Уфа, 1905.

116. *Садретдинов, Ф. Ф. һ.б.* Безгә насыйп гасыр. Борай районы. Уфа, 1999.

117. *Трепавлев, В.В.* Истоки Золотой Орды. М., 2002.

118. Уфимская губерния. СПб., 1877.

119. Үрләгәндә. Әдәби альманах. 1930.

120. *Фахрутдинов, Р.* Татар углы татармын. Яр-Чаллы, 1993.

121. *Халиков, А. Х.* Происхождение татар Поволжья и Приуралья. Казань, 1978.

122. *Харисов, А.* Литературное наследие башкирского народа. XVIII-XIX вв. Уфа, 1973.

123. *Хазиев, А.Н., Хазиев, Н.М.* Село Верхне-Карышево. Бирск, 1989.

124. *Халиков, А.Х.* Вопросы этногенеза тюркоязычных народов Среднего Поволжья. К. 1971.

125. *Халиков, А.Х.* 500 русских фамилий татарского происхождения. Казань, 1992.

126. Хозяйственно-статистический обзор Уфимской губернии за 1903 г., 1904., 1907 г., 1908 г., г. Уфа.

127. Хрестоматия по Исламу. М., Наука, 1999.

128. *Хусаинов, Г.* Башкирская советская поэзия. М.: Наука, 1983.

129. *Шпицер, С.М.* Из прошлого башкирского народа.

130. *Юсупов, Г.Б.* Введение в булгаро-татарскую эпиграфику. М.-Л. 1960.
131. Этнокультурный и этносоциальный портрет населения Башкортостана в XX — в начале XXI веков. Этностатистический сборник. Уфа, 2014.
132. *Эренҗән Карадауан*. Чыңгыз хан. Казан, 2008.

## Содержание

От составителей........................................................................3
Шигабутдин Марджани...............................................................4
Булгария и принятие ислама......................................................5
О произведениях ученых Булгарии.........................................23
Сулейман Бакыргани. Этот бренный мир...............................66
Ахмад Ясави «Лишь скажу: Аллах»… ……………….........68
Кол Шариф «Хвала ему одному…»…………………….......70
Кол Гали. Сказание о Юсуфе и Зулейхе…..………….........71
Дастан Джумжума…………………………………….......76
Салима, дочь Кунакбая…………………………….......81
Батырша. Доношение императрице Елизавете Петровне…....85
Муллы в жизни края. Очерки из журнала «Шура»…………....95
Шамсутдин Заки. «Душа моя и тело мое»… ……………......108
Ислам для народа и народ о служителях ислама……….......110
Габделжаббар Кандалый. Мулла и абыстай……………......116
Каюм Насыри. Поучительные рассказы……………………..119
Воспоминания о Каюм-хазрате……………………………124
Акмулла. Памяти Марджани…………………………………140
Муса Акъегет Мулла Хисаметдин……………………………144
Риза Фахретдин. Шакирд и студент…………………………..147
Библиография…………………………………………………...164